
PRESSA.RU

1926–1991 ЕЛЛАРДА АЗАТ ХАТЫН



2016 ФЕВРАЛЬ № 2

сөембикә

ISSN 0869-1398

ТАБИГАТЬТӘ ГЕНӘ КАЙТА ЯЗ
ирең моны аңлармы

КАЙГЫДА ДА, ШАТЛЫКТА ДА
батырлык дәресе

ЛӘЙСӘН ХӘМИТОВА СЫЙЛЫЙ:
Гөлтан салаты

Гөлчәчәк НӘҖИПОВА:
«АЛГА ОМТЫЛГАН МИЛЛӘТ ТАРИХКА ТАЯНА»



PRESSA.RU



БЕРГӘ ЧАКТА... БУ МИЗГЕЛЛӘР КҮП ТӘ ТҮГЕЛДЕР, БӘЛКИ — АТНАЛАРНЫ ТЫГЫЗЛАГАН БЕТМӘС-ТӨКӘНМӘС ЭШ, МӘШӘКАТЬ ЫГЫ-ЗЫГЫСЫНДА ГАИЛӘ БЕЛӘН ҮТКӘРГӘН БӘХЕТЛЕ МИНУТЛАР ҺАМАН СИРӘГӘЯ, КЫСКАРА БАРАДЫР. ӘММА АЛАРНЫҢ ҺӘРБЕРСЕ КАДЕРЛЕ, ҺӘРКАЙСЫ БЕЗГӘ ТОРМЫШНЫҢ ЯМЕН-ТӘМЕН ТОЕП ЯШӘРЛЕК КӨЧ, ҖАН ҖЫЛЫСЫ БИРӘДЕР. БУ ТАНСЫК ВАКЫТНЫ ҺӘРКЕМ ҮЗЕНЧӘ ҮТКӘРӘ — АЛАР МӘГЪНӘЛЕ, КҮҢЕЛЛЕ, ОНЫТЫЛМАС ЯКТЫ БУЛСЫН ӨЧЕН ӘЛЛӘ НИ КИРӘКМИ ДӘ КЕБЕК...

23 февраль алдыннан Алсу һәм Фаршат Шакировларның шәһәр читендәге өендә ел саен күңелле ыгы-зыгы башлана. Гаиләләре белән якын дуслары – биш-алты гаилә җыела һәм БЕРГӘ ЧАКТА күп итеп пилмән ясыйлар! Бу күмәк эшкә кызлары Ләйсән, уллары Ансар, аларның дуслары да кушыла... Берсе камыр баса, икенчесе җәя, өченчесе кисә, дүртенчесе итен әзерли, аннары җыйнаулашып пилмән бөгәләр... Кичтән пилмәннәрне катырырга чыгарып куялар. Ә иртән ир-егетләр урманда учак урыны хәстәрли. Гаилә башлыгы Фаршат әфәнде – Татарстан Республикасы буенча федераль миграция хезмәте идарәсенең җитәкче урынбасары, Алсу ханым – «Нефтегеотехнология» ҖЧҖ фәнни-җитештерү предприятиесе хезмәткәре. Гаиләдәге бу матур йоланың башында, әлбәттә, Алсу тора! Бу традиция аңа Казан университетының ВМК факультетында укыган чагында кереп калган. Кичтән күп итеп пилмән ясаганнар, катырганнар, икенче көнне иртән гитаралар асып, компанияләре белән электричкада Займищега юл тотканнар. Кар суын казанда кайнатып, пилмән пешергәннәр, җырлашып утырганнар. Бүген дә Шакировлар БЕРГӘ ЧАКТА урманда учак яна, һавага төтен күтәрелә, казанда пилмән кабара, гармун, гитарага кушылып, тирә-юньгә җыр агыла...
















ШАКИРОВЛАР ГАИЛӘСЕ. КАЗАН

Ә сез БЕРГӘ ЧАКТАниләр эшлисез, сезнең гаиләне нинди эш-гамәлләр, үзенчәлекле бәйрәмнәр, берәүдә дә кабатланмый торган, әмма башкаларга да үрнәк булырдай матур йолалар берләштерә? Яңа фотопроектыбыз шундый мизгелләрне яктыртуга багышланган.

Сөй гомерне, сөй халыкны, сөй халыкның дөньясын!



© «Сөембикә» 2016

1926 елдан башлап «Азат хатын» исеме белән чыкты.
1991 елда «Сөембикә» итеп үзгәртелде.
Хатын-кызларның бөтентатар айлык әдәби-нәфис журналы 1913–1918 елларда чыккан «Сөембикә» журналының дәвамчысы.

Ежемесячное литературно-художественное и культурно-просветительское электроннное периодическое издание на татарском, русском языках для женщин и семьи.

Территория распространения: Российская Федерация, зарубежные страны

Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендәге күзәтчелек буенча Федераль хезмәтендә (Роскомнадзор) 2015 елның 18 маенда «Сююмбике» дип теркәлгән.
Теркәү таныклыгы Эл № ФС 77-61814

Язмалар авторның тулы адресы күрсәтелеп, паспорт мәгълүматлары, пенсия иминияте таныклыгы, ИНН таныклыгының ксерокс күчермәләре белән бергә җибәрелгәндә генә кабул ителә.

Кулъязмаларга бәя бирелми, алар кире кайтарылмый.



Директор-баш мөхәррир
Ләйсән Рафикъ кызы ЮНЫСОВА

Редколлегия:
Зилә Вәлиева, Нәбирә Гыйматдинова, Эльмира Зарипова, Кадрия Идрисова, Сәрия Сабурская, Айрат Сибагатуллин, Иркия Төхвәтуллина, Нурия Һашимова, Гөлназ Шәйхи, Эльвира Әхмәтова.

Редакциянең гомуми телефоны 222-09-77
Директор урынбасары
Рәмзия Кашапова 222-09-78
Баш мөхәррир урынбасары
Гөлнур Хәсәншина 222-09-78
Җаваплы сәркатип
Лариса Маликова

Сайт мөхәррире:
Сөмбел Гаффарова

Автор фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.

Реклама текстлары аны бирүчеләр җаваплылыгында.

Редакциянең язмача рөхсәтеннән башка материалларны «Сөембикә»дән күчереп басу тыела.

Дизайн-макет:
«ASAFIN GROUP»
Верстка:
Лариса Маликова

Тышлыкта:
Гөлчәчәк Нәҗмиева

Бүлек мөхәррирләре:
Мәдинә Авзалова
Лилия Гәрәева
Эльмира Закирова
Асия Юнысова
Фәнзилә Мостафина
Корректор
Фирдәвес Исмәгыйлева
Гамәли хезмәткәрләр:
Нәфисә Әскәрова
Ленар Хәкимов

Формат: 225х290 мм.
Күләме 64 бит.

Басарга кул куелды: 16.02.2016 ел.
Заказ М-350.
Тираж 6126.

Учредитель:
Акционерное общество «ТАТМЕДИА»



ТР Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр республика агентлыгы ярдәме белән чыгарыла.

Редакция адресы: 420066, Казан, Декабристлар урамы, 2 нче йорт.
www.syuyumbike.ru
E-mail: suumbike@tatmedia.com
ssuum@yandex.ru
тел./факс: (843) 222-09-77
Язылу индексы: 73002

Банк реквизитлары:
Филиал АО «ТАТМЕДИА»
«Редакция журнала «Сююмбикэ»
р/с 40702810700000005657
к/с 30101810100000000815
в АИКБ «Татфондбанк» г. Казань
ИНН 1655144950
БИК 049205815
КПП 165802002



PRESSA.RU

МУСА ҖӘЛИЛНЕҢ ТУУЫНА — 110 ЕЛ

Яулык

Аерылганда миңа йөрәк дустым
Бүләк итте ефәк яулыгын;
Мин ярама яптым ул яулыкны
Басар өчен агышын канымның.

Кан табыннан куе кызыл төстә
Яулык минем йөрәк турында,
Сөйли миңа аның җылы назы
Һәм ялкынлы сөюе турында.

Мин чикмәдем, дускай, бер карыш та,
Батырларча алга атладым.
Яулык шаһит: сине һәм илемне
Йөрәк каным белән сакладым.



Фото: Голанар Сагиева



Ышанма

Сиңа миннән хәбәр китерсәләр,
«Ул егылган арып», – дисәләр,
Син ышанма, бәгърем!
Мондый сүзне
Дуслар әйтмәс, якын күрсәләр.

Байрагыма каным белән язган
Антым чакра алга барырга.
Хакым бармы минем абынырга,
Хакым бармы арып калырга?

Сиңа миннән хәбәр китерсәләр,
«Алмаштырган илен», – дисәләр,
Син ышанма, бәгърем!
Мондый сүзне
Дуслар әйтмәс, мине сөйсәләр.

Илдән киттем ил һәм синең өчен,
Автоматым асып аркама.
Илемне һәм сине алмаштыргач,
Җирдә миңа тагын ни кала?

Сиңа миннән хәбәр китерсәләр,
«Муса инде үлгән», – дисәләр,
Син ышанма, бәгърем!
Мондый сүзне
Дуслар әйтмәс, сине сөйсәләр.

Туфрак күмәр тәнне, күмә алмас
Ялкынлы җыр тулы күңелне;
«Үлем» диеп әйтеп буламы соң
Җиңеп үлгән мондый үлемне?

PRESSA.RU







БЕЗНЕҢ ТЫШЛЫКТА





8
МУЗЕЙДА – ТӨН, КӨН... ҺӘМ ГОМЕР
А. Фатыйхова

ЗАМАН ҺӘМ БЕЗ



12
ГАИЛӘ КОРЫР ИДЕМ... КУРКЫТА!
Ф. Мостафина



20
ЯЗЛАР ГЫНА КАБАТЛАНА...
Г. Хәсәншина



16
КИРЕЛЕКМЕ, ҮЗСҮЗЛЕЛЕКМЕ?
Л. Әбүдәрова

ТАТАР ДӨНЬЯСЫ






24
ТӘВӘККӘЛДӘ – ТАУ КӨЧЕ
Г. Сафиуллина



ЭЧТӘЛЕК

МӘДӘНИ ТОРМЫШ 



30 КАР... КАЙНАР ИКӘН
А. Әхмәтгалиева

ЯШӘЕШ 



42 ТАБИГАТЬ БАЛАЛАРЫ
А. Юнысова



46 БЕР ЯВАРМЫН КҮК
К. Гыйззәтуллина

ШУЛАЙ УК: 

36 «УЛ МИНЕ ЙӨРӘГЕНДӘ САКЛАР»
Н. Гыйматдинова

54 БИШЕНЧЕ КЫЗ
А. Сәгыйтова

ХАТЫН-КЫЗ ГАЛӘМЕ 



60 БӘЙРӘМГӘ ОСЕТИН СЫЕ

КИЛӘСЕ САНЫБЫЗДА: 

«КЫЗЫМ, БЕЗ ҖИҢӘРГӘ ТИЕШ!»
Мин язмышны җиңдем.

ТРЕНИНГ БЕЗГӘ НӘРСӘГӘ?
Заман һәм без

ФӘНИЯ ТӘҮБӘСЕ
Хикәя

ЯШЕН КАЙТАВАЗЫ
Булган хәл

3D ЧИГҮ
Мастер-класс



PRESSA.RU

Кадерле «Сөембикә» редакциясе!



Көннәрдән бер көнне Казаннан кунаклар кайтып төште.
Туп кебек тәгәрәп үсүче оныкларымны сөю шатлыгы тормышка әйтеп бетергесез ямь өстәде.

Балалар, әлбәттә, гел көләп кенә тормыйлар, көйсезләнеп тә алалар. Нәни оныгыбыз елый да елый, һич туктатып булмый. Кай җире авыртканын да белдерә алмый: нибары яшь ярымлык кына. Иртәнге сәгатьне көч-хәл җиткереп, якындагы 6 нчы балалар шифаханәсенә алып киттек. Җитмәсә, кызыбыз ашыгычлык белән баланың документларын Казанда онытып калдырган. Регистратурада утыручы ханым:

– Без бит үзебезнекеләрне генә кабул итәбез. Болай да табиблар җитми! – дип шаулап каршы алса да, зарыбызны тыңлауга, йомшарды. «Әйдәгез, Тәнзилә Зыятдиновна янына», – дип, өченче катка ук озатып куйды.

«Югары категорияле педиатр Тәнзилә Зыятдин кызы Фәткулова» дип язылган ишек янында халык инде шактый җыелган. Сабыйның өзгәләнеп елаганын күреп, безне чиратсыз үткәрделәр.

– Баланың берьюлы 4 теше чыгып килә. Менә шушы үләннәрдән төнәтмәләр ясарга кирәк булыр, – дип, рецепт язды табибә.

Аның янына әле без тагын бардык. Дөньяга таралган татарның бик гыйбрәтле язмышлы баласы да икән бит әле ул...

– Минем әби белән бабай, дүрт баласын калдырып, 1931 елгы ачлык елны үлгәннәр. Балаларның өлкәнрәкләре ялланып эшләгән. Әнием Зөләйханы приютка биргәннәр, – дип сөйләп алды Тәнзилә ханым. – Бераз үскәч, туганнары аны кире авылга алып кайткан.

Унҗиде яшендә кулы эшкә ятып торган Зөләйханы авылдашы Мөхәммәтҗан Әбүбәкеровка кияүгә бирәләр. Яшь гаилә бәхет эзләп Мәскәү өлкәсенә чыгып китә. Тик биредә дә аларны көтеп тормыйлар. Ике елдан соң, барлык мөлкәтләрен сатып Төрекмәнстанга, Чарджау шәһәренә килеп чыгалар. Сабы килсә, җәбе килми дигәндәй, гаиләгә никтер бәхет иңми. Туган бер балалары үлә тора. Аптырагач, туган авылларына кайтырга булалар. Биредә сигезенче бала булып кызлары аваз сала. Аңа Разия дип исем кушалар. Кызчык үсә. Аны чирләр дә читләтеп уза, кизүләргә дә бирешми. Аллаһы боерса, Разияга иптәшкә энеләре-сеңелләре дә туар, дип хыяллана Мөхәммәтҗан. Әмма теләкләре тормышка ашмый. 1941 елда аны сугышка алып китәләр. Белоруссия өчен барган сугышларда һәлак була ул.

Бергә-бергә җиңелрәк булыр дип, Мөхәммәтҗанның апасы киленнәрен Чарджауга чакыра. Кызын ияртеп Урта Азиягә юл тота Зөләйха. Торырга урыны да, эшләргә эше дә табыла. Чарджауда тимер юл станциясе бар. Мамык эшкәртү, туку фабрикалары эшләп тора. Милләттәшләребез аралашып, ярдәмләшеп көн күрәләр икән. Тормыш булгач, үлем-китеме дә булып тора. Тумышы белән Ульяныкларыннан булган Зыятдин Биктимеров гаиләсенә көтмәгәндә зур кайгы килә. Җиде баласын калдырып хатыны дөнья куя. Зөләйха шушы балаларга әни булып килә. 1952 елның сентябрендә уртак балалары Тәнзилә дөньяга килә. Ләкин язмыш кабат сыный татар хатынын – Зыятдин да вафат була. Итәк тулы балалар белән утырып кала Зөләйха. Нәни Тәнзиләне дә иркәләп-назлап утырырга җае булмый аның. Шуңа күрә кызчык яшьтән үк кул арасына керә. Сигез классны тәмамлап, медицина көллиятенә укырга керә. Көллиятне кызыл диплом белән тәмамлагач, Ашхабад медицина институтына юл тота.

Дипломлы белгечне Ашхабадтагы республика хастаханәсенә эшкә чакыралар. Озак та үтми, егет солтаны Рамил Фәткулов белән таныша. Рамил политехника институтын тәмамлаган. Аралашуларына бер ел дигәндә, яшьләр гаилә кора. Бәхет өстенә бәхет өстәп, уллары Дамир туа. Эшләре дә, торыр җирләре дә бар. Бер караганда, тагын ни кирәк?!

...70 нче елларда бөтен дөнья Чаллы, КамАЗ турында сөйли. Фәткуловлар гаиләсе дә 1981 елда Чаллыга килеп төпләнә. Рамил «КамАЗ»ның бер идарәсенә, ә Тәнзилә 4 нче балалар шифаханәсенә участок табибәсе булып урнаша. Тик Наил генә... Көчен дә, вакытын да кызганмыйча эшләп йөргән җирдән 41 яшьлек япь-яшь ир якты дөньядан китеп бара.

Тәнзилә Зыятдин кызына да олы йөрәкле, нык рухлы әнисе Зөләйха апаның язмышын кабатларга туры килә. Уллары Дамир белән Наилне бер ялгызы аякка бастыра ул.

Тәнзилә Зыятдин кызы, чыннан да, лаеклы тормыш һәм хезмәт юлы үткән. 1988 елда аны 6 нчы балалар шифаханәсенә бүлек мөдире итеп, аннан соң баш табиб урынбасары итеп билгелиләр. Чаллыда аны

тәҗрибәле остаз, талантлы оештыручы, сабыйларның күңелен аңлый белүче табибә буларак беләләр.

Рахман ШӘФИГУЛЛИН,
Чаллы.

Ахирәт! Ахирәткәем! Нинди матур, тирән мәгънәле сүз бу! Без инде аның мәгънәсен дә онытып барабыз бугай.

Дәү әниемнең дә ахирәт дусты бар. Сезгә шуның хакында сөйлисем килә. Бәлки, яшьләргә бу сүзнең мәгънәсен аңлатырга, дуслык кадерен бәяләргә өйрәтер ул.

«Ахирәтләр булырбыз дип сүз куештык әле», – дип, балкып кайтып керде бер көн дәү әнием. Аның сөенеченнән өй эчләре дә яктырып киткәндәй булды. Миңа 13 яшьләр тирәсе иде кебек. «Дәү әни, кем белән?» – дип сорадым мин. «Вәсимә апаң белән, балакаем, Вәсимә апаң белән!» Шулай диде дә, җилпуч алып, он иләргә кереште. Таба ашларын һәр иртәдә пешерми калмый иде ул. Моңа дәү әти дә, без дә күнегеп беткән. Тик шулай да көн уртасында җырлый-җырлый төче коймак пешерүен күрү кызык та, рәхәт тә иде. Теге сүз һаман эчне кытыклап тора бит, шул сорауны дәү әнигә бирәм: «Кем соң ул ахирәт?» «Ахирәт – бик матур сүз, кызым. Менә син дус кызларыңа подружка дисең. Дустың Гүзәл белән гел бергә уйныйсың. Ахирәт менә шул була инде», – диде ул. «Дәү әни, Вәсимә апа синнән күпкә олы бит. Аннары сез алай ук гел бергә дә түгел идегез...» Дәү әнием кырт кисә: «Вәсимә апаң – әүлия. Аңа сүз тидерергә ярамый!»

«Әүлия» дигән сүз Аксубай яклырында «изге» сүзе урынына йөри. Вәсимә апаның күргәннәрен сөйләсәңме?..

Ул бик яшьли Миңневәли исемле егеткә кияүгә чыга. Бик чибәр, булдыклы егет була Миңневәли. Уллары туа, аннан кызлары аваз сала. Көннәрдән бер көнне Миңневәли үзләреннән егерме чакрым ераклыктагы авылга китә. Бер атна үтә, ике атна – ире юк. Күпмедер вакыттан соң, кияүгә чыкмаган яшь кызны хатын итеп ияртеп кайта ул. Яшь хатын бик чибәр булуы өстенә, бик үткен дә булып чыга. Шулай итеп, Вәсимә апа ике баласы белән көндәш өстендә көн күрә башлый. Чыгып кына китәр иде, барыр урыны юк, балалары кечкенә. Карт, кирәксез хатын булып, тилмереп бер генә ел яшәми әле ул.

Моннан җиде ел элек Вәсимә апалар күрше урамнан йорт сатып алдылар. Улы өйләнде, оныклары туды. Тик мин бер нәрсәне аңламыйм – татар халкының зур йолабәйрәмнәренә, Ураза, Корбан гаетләренә Вәсимә апа ирен яшь хатыны белән кунакка чакырмый калмый. Әле оныклары аңа «бабаем», дип йөри. Бик тәртипле булдылар Вәсимә апаның балалары.

Дәү әнием белән ахирәтләр булгач, Вәсимә апа безгә еш килә иде. Бер килүендә колак очым белән генә сөйләшүләрен ишетеп калдым: «Вәсимә апа, бер дә ачуың килмимени соң? Син бит инде бүтән тормышка да чыкмадың?» – дип кызыксынды дәү әнием. «Юк, ахирәтем. Күптән кичердем инде мин аларны. Балаларымның атасы ла ул», – диде Вәсимә апа. Татар хатын-кызларының күбесенә хас сабырлыкка-түземлеккә ия булган инде ул. Чын әүлия...

Айгөл КОТДУСОВА.
Арча.

«Сөембикә» журналында хатын-кыз проблемаларына багышланган мәкаләләрне укыйм да, озак кына уйланып йөрим.

Кешелек дөньясы егерме беренче гасырны ваклый, әмма әле дә булса ире яки туганнары тарафыннан кыйналып, кимсетелеп яшәүче хатын-кызларны чынлап торып яклаучы оешма да, закон да юк. «Гаиләдә золым күргән хатын-кызның иң зур проблемасы – китәр җире булмау», – дип, чаң сугар заман җитте. Бу бит чынлап та шулай. Христиан динендәге хатын-кыз, һич тә барыр җире булмаса, монастырьга булса да барып сыена ала. Ә бездә??? Әле яшь ханымнар гына түгел, сиксәнгә җиткән аналар да, уллары куып чыгаргач, бер кич кунар урын тапмый, тилмереп йөри. Гомер буе бил бөгеп, үзе эшләп тапкан фатирында тынычлык таба алмаган ана кая барырга тиеш? Мин моннан 10 еллар элек «Ватаным Татарстан» газетасына бу хакта язып караган идем. «Мәчетләр күп төзелә. Шул мәчетнең бер-ике бүлмәсен яклауга мохтаҗлар өчен тәгаенләп булмыймы?» – дигән соравыма каршы, дин әһелләре: «Бездә андый тәҗрибә юк», – дип җавап бирде. Тырышып эшләгән, балалар үстергән, ирен тәрбияләгән, ата-анасына булышып яшәгән хатын-кыз авыр хәлдә калды исә, беркемгә кирәксезгә әверелә. Әйтерсең лә, ул җәмгыятьнең бер әрәм тамагы. Бүгенге көндә күпчелек хатын-кызның хезмәт хакын конверт белән алуы да сер түгел. Ул хатын-кызларның киләчәктә пенсияләре тамагын туйдырырга да җитмәячәк бит! Кемнәр яклар аларны, кемнәр кайгыртыр? Безнең бөтен өмет депутатларда. Гади халыкны борчыган мәсьәләләрне күреп, аларны хәл итү юлларын алар гына таба ала. Элегрәк сыер савучыларны да депутат итеп сайлыйлар, алар үзләренә таныш проблемаларны күтәреп чыгалар иде. Хәзер гади халык депутат түгел, делегат та булып катнаша алмый. Әйтегез әле, без, хатын-кызлар, үзебезне үзебез якламасак, безне кем яклар? Әйдәгез әле, бу проблеманы бергәләп күтәрик! Депутат хатын-кызлардан торган «Мәрхәмәт» берләшмәсе булуын да онытмыйк. Дөрес, хатын-кызлар оешмалары күп анысы. Әмма шулар арасында авыр хәлдәге хатын-кызга чын-чынлап ярдәм итәрдәе бармы? Тәртипле, эшчән, балалар үстерүче, гаилә учагын сакларга тырышучы хатын-кызлар XXI гасырда кагылып-сугылып яшәргә тиеш түгел.

Саимә МОРАТОВА.
Чирмешән районы,
Кара Чишмә авылы.

Хөрмәтле укучыларыбыз!
Сездән хатлар көтеп калабыз.
Безнең адрес: Казан, Декабристлар урамы, 2.
e-mail: ssuum@yandex.ru

PRESSA.RU



МУЗЕЙДА – ТӨН, КӨН... ҺӘМ ГОМЕР

Айсылу ФАТЫЙХОВА

Әбекәй зур сандыгын алып, әйберләрен җиллләтергә утырган көн без – оныклары өчен бәйрәм була. «Менә монысы – әнкәйдән калган кызыл башлы тастымал, монысы – Хәниямнең туена дип чиккән күлмәге, монысы – Мисырдан кайткан дисбе», – дип, һәр әйберсен сыйпап алып куя. Шакмаклап тукылган кызыл башлы сөлге, итәге, түше чигелгән күлмәкләр астында гарәп язулы коңгырт тышлы калын китаплар да ята. «Һәрберсе музейда торырлык шул болар», – дигән сүзләреннән, 4-5 яшьлек бала, музейны зур бер сандык итеп күзаллый идем. Үсә төшкәч, музейның сандыкка гына сыеп бетмәвен белдем. Ләкин бер әйбер – анда иң кадерле, иң кыйммәтле нәрсәләр сакланырга тиешлеге күңелнең иң түренә кереп урнашты.

Татарстан Милли музее директоры, тарих фәннәре докторы Гөлчәчәк НӘҖИПОВА янына шундый тәэссорат белән килеп кердем. 900 мең берәмлек экспонаты, 120 еллык тарихы булган, Казанның мәдәни-тарихи һәйкәле саналган «Кәрван сарай» («Гостиный двор») сәүдә-кунакханә комплексында урнашкан Милли музейда башкача булырга мөмкин дә түгел.

«Музейда эшләрмен дип уйламаган идем, – ди Гөлчәчәк Рәхимҗан кызы, – тарих факультетына килүемә мәктәптәге тарих укытучыларым – мәгариф отличнигы, Никитина Евгения Степановна (үзе дә музей сәхифәләренә кереп калырлык шәхес – Минзәләнең беренче пионеры! – *А. Ф.*), Нелли Сергеевна Быстрова (Ленинград блокадасыннан эвакуацияләнеп килгән) сәбәпче. Икесе дә бик көчле тарихчылар иде».

Мәктәпнең дружина советы председателе, комсомол оешмасы секретаре булган, җәмәгать эшләрендә актив катнашкан кыз булган Гөлчәчәк. Уку, җәмәгать эшләре өстенә, йорт эшләре дә бар бит әле. Әтиләре – Рәхимҗан Сәлахов гомер буе партия кушкан җирдә була: колхоз рәисе дә, партия оешмасы секретаре да – кая җибәрсәләр, шунда эшли. Авыл, район җирендә колхоз-совхоз җитәкләү – өеңә кайтып керә алмау дигән сүз. «Әнкәй – медицина хезмәткәре, ул эштән өчтә кайта иде, бергәләп күмерен дә, утынын да ташыдык, бөтен өй эше үзебездә булды. Әнкәй таләпчән булды, хезмәт белән тәрбияләде. Сиздермәсә дә, гомер буе минем өчен борчылып, һәр эшем белән кызыксынып яшәгән. Үзен югалткач кына белдем: Әнкәй минем хакта матбугатта басылган һәр язманы кисеп, туплап барган икән. Әткәй белән алар 60 ел бергә яшәделәр. Башта Әнкәй китеп барды, аннары – Әткәй. Әнкәйдән соң берничә ай гына яшәп калды...» «Өйдә булмасаң да – өй синдә!» – әнисе сеңдергән шушы хакыйкать гомер буе озата килә аны. Яшьлекләре сугыш чорына туры килгән, эштән башканы белмәгән буынның төчеләнеп, кочаклашып, бала иркәләп утырырга вакыты да булмагандыр, кирәксенмәгәннәрдер дә. Баланы тормышка әзерләү, үзбаш яши башлагач, югалып калмасын өчен үзең белгәнне барын да сеңдереп калу – иң әһәмиятлесе шул. Кычкырып әйтмәсә, күрсәтеп тормаса да, Гөлсинә апаның да, кызы турында чыккан чираттагы газета битендәге фоторәсемен сизелер-сизелмәс кенә сыйпап алганы, йотлыгып кабат-кабат укыган чаклары аз булмагандыр.



■ Татарстан Милли музее – республиканың тарихи-мәдәни мирасы саклана торган иң зур музей. Россиянең региональ музей фондларыннан иң зурысы да ул. Хезмәткәрләре арасында тарихчылар, филологлар, әдәбият белгечләре, этнографлар, нумизматлар, эпиграфика өлкәсендә белгечләр эшли. Биредәге реставрация осталары, рәссам, методист, экспозиция җыючылар республикабызда гына түгел, дөнья күләмендә дә югары бәяләнә.

Татарстанны таныйлар, беләләр! Гөлчәчәк Рәхимҗановнаның бу хакта үз фикере: «Белсеннәр өчен эшләргә, үзеңне күрсәтергә кирәк!»



ГӨЛЧӘЧӘК НӘҖИПОВАДАН ТОРМЫШ САБАКЛАРЫ:

■ Гел алга омтыл!
■ Тик ятма!
■ Баштан сыйпый белергә дә өйрән!
■ Балаңа ышан!
■ Өйдә булмасаң да – өй синеке!



PRESSA.RU



■ Халыкны җәлеп итү өчен төрледән-төрле чаралар уйлап табыла. Әйтик, «Музейда – төн» чарасына утыз меңләп кеше килгән! (Чагыштыру өчен: гадәти көннәрдә музейны көнгә 300 ләп кеше карый.) Әлбәттә, барысы да әзерлекле түгел. Беренче елларны музейга төн уздырырга килгән яшьләрнең үз-үзен тота белмәвенә шаккаткан булсалар, соңрак үзләренчә тәрбияли башлаганнар. Бүген музейда тормыш кайнап тора: календарь даталардан тыш, төрле чаралар, уеннар, квестлар үткәрелә.



«Мәктәпне тәмамлагач, йә чит телләр факультетына, йә тарих бүлегенә бару иде уем. Чит телләр факультеты пединститутта гына. Минем теләгем – университетта уку. Укытучыларыбыз да нинди шәхесләр иде бит! Антик дәвер тарихы белгече, профессор Аркадий Шофман, археолог Альфред Халиков, Григорий Вульфсон».

Экспонатлар арасында – Александр Пушкин каләмен манып язган малахит кара савыты да бар.

Соңгысы турында аерым сөйләргә дә була. Россия тарихын өйрәнгән галим, шәп педагог һәм лектор, 35 ләп фән кандидаты үстергән Остаз Гөлчәчәк Рәхимҗановна тормышында аерым урын алып тора. Диплом җитәкчесе булган Григорий Наумович кызны җитәкләп Милли музейга алып килә. Шәхси коллекциясендә XVII гасырдан алып XX гасыр башы белән билгеләнгән меңнән артык экспонат җыйган коллекционер, Казан университетында китап музее, Лобачевский музее оештыру теләге белән янган (әмма өлгерә алмаган) галимнең кыз алдындагы абруе фәкать бер детальдән дә күренә. Кияүгә чыгарга җыенган Гөлчәчәк, егете Рөстәмне башта остазы белән таныштыра, аның фатихасын ала! Григорий Наумович фанилыктан күчкәч тә ташламый шәкертен: коллекциясе Милли музейда саклана хәзер.

30 елдан артык вакыт узган. Әшен тарих бүлегеннән башлаган Гөлчәчәк, этнография бүлеге башлыгы, директор урынбасары кебек баскычларны узып, вакытлыча музейдан аерылып тора да, кире кайтып, генераль директор Гөлчәчәк Рәхимҗановнага әйләнә. Музей да үзгәргән. Ул бүген – мирас, фән, белем һәм тәрбия йорты, мәдәнилек саклана торган урын. Ул бүген заман чагылышы да! Ишек төбеннән үк каршы алып, штрихкодларны сканер аша уздырып, мәгълүмат туплый торган терминаллар да ул, социаль челтәрләрдә даими бара торган аралашу да, интернет-портал аша видеоэкскурсияләр дә. Әлбәттә, заманчалык гаджетлар куллануга гына кайтып калмый – тере аралашудан кем туктаган!

Музейда туган көн уздырган булды: балаларның яшенә күрә экспозицияләр буйлап квест уздыралар, алар яше өчен кызыклы булган уен-тукталышлар ясыйлар. Экскурсиядән соң, мастер-класс узарга, аннары билгеләнгән урында утырып чәй эчеп, сыйланып алырга мөмкин. Тиз генә чыгасы да килми: карап узган тукталышларны кабаттан кайтып, акрынлап карыйсы килә.

Туган көн генә түгел, туйлар да уздырыла икән бит музейда! Һәр халыкның үз гореф-гадәтләренә нигезләнеп! Татарларда бал-май каптыру йоласы булса, чуашларда кызның сандык тутыру йоласы туй барышына кереп китә. Баксаң, гел чигүдән генә торган киемнәрдәге һәр бизәкнең үз мәгънәсе, үз теле бар икән! Музейда шуларны искә төшереп, кияү белән кәләшне, кунакларны таныштыралар, һәр халыкның гореф-гадәтләрен искә төшерәләр, чын туй ясап озаталар. Ихтыяҗ бар үзе – ай саен 5-6 туй – музей үз миссиясен үти – мирасыбызны яңа буыннарга ирештерә.

«Музей – үзенең генә түгел, гаиләнең суырып ала, – ди Гөлчәчәк Рәхимҗановна. – Балалар да шушында булды безнең. Минекеләр Вячеслав Хабаров лагерьларында эшкә өйрәнеп, мөстәкыйль булып үстеләр. Үзебез дә хезмәткәрләребез белән бәби-кросслар оештырабыз, бәйрәмнәр вакытында бүләкләр әзерлибез, беренче сентябрьгә җыелып озатабыз, яңа елларны әйтәсе дә юк инде. Мәктәпне тәмамлаучыларны аерым игътибарга алу теләге дә бар. Балалар белән аралашу күңелгә рәхәт бит ул. Бүгенгә 348 хезмәткәребезгә йөзләп балабыз бар».

Гаилә ялларының да музейларда башлануын әйтәсеңме тагын! Эрмитаждан алып Ясная Поляна, Владимир–Суздаль, Йошкар-Ола, Ижау, Ульяновск, Красноярскины күреп кайтканнарын... Петрозаводскига, Вешенская станицасындагы Шолохов музеена кадәр барганнарын... «Машинага утырып чыгып китәбез дә үз



■ М. Җәлилнең «Моабит дәфтәрләре» – Халкыбыз горурлыгы – Милли музейда саклана һәм «Төп нөсхә көнендә» халык хозурына чыгарыла.

белән танышу, гимнны өйрәнү, чын гражданнар тәрбияләү омтылышы да. Монысы инде музейның патриотик тәрбия бирүче ролендә чыгыш ясавы.

Хәрби темага багышланмаса да, «Идел буе инешләре» проекты – шулай ук ватанпәрвәр проект. Ни өченме? Балалар Идел буенда яшәүче халыкларның уеннарын уйный, аларча исәнләшергә, биергә-җырларга өйрәнә. Бу – үз туган җиреңне дә яратырга, күршеләрең белән дус-тату яшәргә, аларны хөрмәт итәргә өйрәтү дә. «Мәктәптә – музей», «Беренче сыйныф укучысының мәдәни көндәлеге» проектлары да балаларны музейга тарта.

Тарих кына түгел, табигать белемен дә, әдәбиятны да, җәмгыять белемен дә, технологияне дә музей экспонатлары аша өйрәнергә була.

җаебыз белән урап кайтабыз, – ди Гөлчәчәк Рәхимҗановна. – Тукталыр өчен урыннар бар, куныйм дисәң, кунакханәләр бар, машинада йөрү уңайлы хәзер. Киләчәк – шундый туризм ягында. Машинада сәяхәт итүчеләр күп. Яшь балалы гаиләләр дә шактый очрый. Ерак китәсе түгел, үзебезнең хезмәткәрләр дә машинада, палаткалар алып Кырымга кадәр барып җиттеләр».

«Кызым Зөһрә – аспирант, бу арада Африкада экскурсовод булып эшли. Улым Тимур быел университет тәмамлый, бакалавр булачак. Балаларны бәйләп куеп булмый, аларны җибәрә белергә кирәктер».

«Әни, син безгә ышанырга тиеш», – дигән Зөһрәсе, әнисенең чит телләр өйрәнү турындагы хыялын тормышка ашырган: кытай, инглиз телләрендә иркен сөйләшә. Хәер, студент елларында француз телен өйрәнгән Гөлчәчәк ханымның үзенең дә чит ил туристларына Кремль буйлап, экскурсияләр уздырган чагы кичә генә шикелле! Чит тел белүе ICOM – Халыкара музеология комитетының Россия бүлегенә вице-президент итеп сайланганда да ярдәм иткәндер, чөнки оешманың рәсми телләре – инглиз, француз, испан телләре бит. Тагын шунысы да бар: 700 дән артык дәүләт музееи үз эченә алып торган әлеге оешмадагы 25 президиум әгъзасының икесе (икенчесе Алабуга музей-тыюлыгыннан Гөлзада Руденко – *А. Ф.*) Татарстаннан булу да күп нәрсә сөйли.

Музей хезмәткәрләре ассоциациясе рәисе дә ул, мәдәният хезмәткәрләре иҗади берлегенең Татарстан бүлеге рәисе дә, Россия музейлар берлегендә вәкил дә, Татарстан Республикасының җәмәгать пулаты әгъзасы да. Боларына да җавап бер генә: «Үзең тырышмасаң!..» Әле бит музейда халыкны җәлеп итү өчен уйлап табылып торган чаралар күпме. Шуларның берсе «Мин – Татарстан баласы» («Я – гражданин России»). Миграция хезмәте белән берлектә оештырылган проект. Шәһәрнең, районның күренекле кешеләре белән бергә, тантаналы шартларда балаларга паспорт тапшырудан гыйбарәт ул. Паспорт бирү генә түгел, ә бәлки дәүләт символлары

«Музей иске әйберләр сандыгы гына түгел, ул шундый әйбәт белем бирү урыны да, – ди Гөлчәчәк Нәҗипова. – Шул ук тарих дәресләрен бездә үткәреп, бер көн эчендә берничә теманы колачларлык мәгълүмат алырга мөмкин».

«Мин – музей коллекционеры. Император фарфор заводы экспонатлары да бар бездә – XX гасыр башы эшләнмәләре дә, совет чорыныкы да. Ә хәзерге заманга караганы юк иде. Үземә бүләк иткәч, музейга алып килеп куйдым, чөнки монда кирәгрәк ул».

Ямал-ненец округына баргач, алып кайткан бүләге – болгар кызларының көмеш бизәнү әйберләренең күчермәләре дә, Иҗтимагый палата әгъзасы булганлыкка бирелгән күкрәк билгесе дә Музей фондларына тапшырылган. Музейга бүләк кабул итү көннәре уздырыла. Теләгән һәр кеше үзе истәлекле дип тапкан әйберне музейга алып килә ала. 900 меңнән артык экспонаты булган Милли музейда «Миллионынчы экспонатны алып кил» дип аталган хәрәкәт башланган.

Экспедицияләрдә йөргән чакларыбыз да бар иде, – дип сөйли директор. Табылдыклар арасында – XVIII гасыр кульязмалары, көндәлекләр, шәҗәрәләр, чигү үрнәкләре, киемнәр, калфаклар булган. Әлбәттә, алар фондларда үз урынын тапкан инде. Фондлар... Алардагы байлык – горурлык та, «баш авыртуы» да. «Баш авыртуы», чөнки шул байлыкны күрсәтү мөмкинлекләре чикләнгән. Экспозицияләрне еш алыштырып торып булмый, барысы да финанс мөмкинлекләренә барып терәлә. Инде фондларга эксклюзив экскурсияләр оештыра башлаганнар. Бер яктан, алардагы байлык белән таныштырасы да килә; икенче яктан, аларны бик саклап тотарга да кирәк. Музейны, аның янәшәсендәге биналарны төзекләндерәсе иде дигән хыял да бар.

Музей – алан-йолан каранып чыга торган урын гына түгел. Ул – фәнни ачышлар мәйданы. Ул – белем алу өчен зур бер мәктәп, үткәннәргә тәрәзә! Гөлчәчәк Рәхимҗановна үзе гади генә итеп: «Музей – минем язмышым ул», – ди.

PRESSA.RU

ГАИЛӘ КОРЫР ИДЕМ... КУРКЫТА!



ҺӘР ХАЛЫКНЫҢ ЯШӘЕШЕНДӘ ИҢ ЗУР ВАКЫЙГА – ТУЙ. ЮК, ЮК, БӘЙРӘМ МӘГЪНӘСЕНДӘГЕ ТУЙ ТҮГЕЛ ӘЛЕ.

Кавышу, яңа гаилә кору уңаеннан зурлап уздырыла торган, халыкча әйтсәк, кызыл туй! Һәр кыз бала үзенең никахын көткән. Һәр егет үзенә кәләш булырдай кызны күзләгән. Кайнана – әйбәт килен, ә аның кодагые – мәрхәмәтле кияү, һәр як та игелекле оныклар турында хыялланган. Нәселләр, авыллар, милләтләр туганлашкан. Елдан-елга шушылай дәвам итәр кебек булган да бит... Тик замана җилләре гаилә институтына да кагылмый калмады.



Фәнзилә МОСТАФИНА



«Мин кияүгә чыгарга теләмим!» –
бер дус кызыбызның ярәшелүен бәйрәм итәргә җыелгач, Камиләбез шулай дип ярды да салды...
Сүзсез калдык. Ниһаять, нәрсә әйткәне аңыбызга барып җитте. Кәләш буласы кызны оныттык (хәер, ул үзе дә булачак туен оныттты кебек), кияүгә чыкмаска ниятләп, дустыбызны уратып алып, сорауларга күмдек. Җитди сәбәбен дә әзерләгән икән Камилә: «Үземне кем беләндер яши, аңа яраклаша алырмын дип уйламыйм».
Шаяруга бордык та теманы ябып та куйдык. Шундый күңелле көндә бу хакта сөйләшәләр димени! Инде гаилә корырга өлгергән кызлар Камиләне тынычландырырга тырыштты: «Борчылма, без дә шулай уйлый идек... кияүгә чыкканчы».

Ир кирәк түгел, бала булса ярый

Берничә көн үткәч, әлеге сөйләшү кылт итеп исемә төште дә интернетта хатын-кызлар форумына кереп карарга булдым. Камилә кебекләр тагын бармы икән, янәсе. Булмас, ди, сиңа! Гадәттә, ир-атлар гаилә корырга ашыкмый, дибез. Тик бу фикер искергән, күрәсең. Бүген законлы рәвештә ир хатыны булып теркәлергә теләмәүче кызлар саны да көннән-көн арта бара.

«Кияүгә чыгарга теләмим» дигән темага фикерләшү кайнап тора интернетта. Берәү болай дип яза: «Минем ирекле буласым килә, шуңа күрә кияүгә чыгарга теләмим дә. Юк, мин үз эчемә генә йомылып яшәмим, шау-шулы компанияләрне яратам, дусларым белән еш күрешәм. Яраткан кешем дә бар. Тик кияүгә чыгып, үземне ниндидер кысаларда тотасым килми». Икенче туташның сәбәбе бүтән: «Гаилә кору искиткеч зур җаваплылык бит ул. Мин ирем белән уртак тел таба, аңа яраклаша алырмынмы? Ул мине аңлармы? Балаларымны дөрес тәрбияли белерменме? Мин бу сорауларның берсенә дә уңай җавап бирә алмыйм, шуңа күрә кияүгә чыгарга куркам». Өченчесенең дә сәбәбе саллы күренә: «Миңа 24 яшь. Мөстәкыйль тормышка шулхәтле күнеккәнмен ки, гаилә коруымны күз алдыма да китерә алмыйм. Егетем белән дә аерылыштым – өйләнешик, дип, ашыктыра иде. Ә мин тормышымны ниндидер чит кеше белән (ул яратканым булса да) бүлешергә әзер түгелмен икән». Матди як турында уйлаучылар да күренә. «Хезмәт хакым яхшы. Кияүгә чыгып, һәр тиен акча өчен ирем алдында хисап тотып яшәргә теләмим», – дип яза 25 яшьлек бер туташ.

Бу форумнарда озаграк утырсаң, чыннан да, ни өчен кияүгә чыгарга соң әле, дип уйлана башлыйсың икән! Шуңа күрә интернетны тизрәк ябып куйдым. Туктале, мин әйтәм, әллә кайдагы кешеләрнең фикерен укып утырганчы, үз танышларымны сораштырып карыйм. 24-28 яшьлек ун танышымнан, читләтеп кенә: «Кайчан кияүгә чыгасың инде?» – дип сораштым. Ун кызның өчесе (24-26 яшьләрдә): «Әле ашыкмыйбыз, вакыты җиткәч, әлбәттә, чыгачакбыз», дип җавап бирде. Ике кызның кияүгә чыгарга бөтенләй теләге юк икән. Ә берсе: «Кияүгә чыгасым килми, тик бала алып кайтыр идем», – дип җавап бирде. Дүрт кыз исә кияүгә чыгарга, кочак тутырып бала алып кайтырга һәм гаилә учагын җил-давылдан саклап яшәргә хыяллана булып чыкты.

«Кияүгә чыгасым килми» дигән өч кыздан, ни өчен, дип төпченгән булам. Әлеге дә баягы форумдагы җаваплар яңгырый: «җаваплылыктан куркам», «кешегә яраклаша алмыйм, холкым начар», «иремне бәхетле итә алачагыма ышанмыйм»...

Бүгенге заманда кызларның гаилә корырга ашыкмавы шаккаткыч нәрсә түгел инде анысы. Тик «беренче чиратта – гаилә»,

Психология фәннәре кандидаты, доцент Айсылу Нәгыймова, гаилә корырга теләмәүнең сәбәпләре берничә ди:

«Иң әһәмиятлесе – җәмгыятьтәге әхлак кануннарының үзгәрүе. Бүген Европа илләрендә генә түгел, Россиядә һәм Татарстаныбызда да гаять дәрәҗәдә иркен җенси мөнәсәбәтләр хөкем сөрә: никахсыз гына бергә яшәп яткан ул-кызларыбызны гаеп итү дә юк инде. Янәсе, заманы шундый! Ә бит 25-30 ел элек кенә бу бөтенләй мөмкин булмаган хәл иде. Ирекле мәхәббәт, җенси революция яшьләребезгә формаль йөкләмәләр алмый гына бергә яшәргә мөмкинлек бирә. Нигә гаилә корырга омтылсын икән яшьләр?! Болай бит җиңел – бүген бар да яхшы, иртәгә проблема туды исә, араларны өзү дә кыен түгел. Ә гаилә йөген утыз яшьләргә җиткәндә дә тарта башларга була янәсе.

Икенче сәбәп – тискәре тормыш тәҗрибәсе. Әтисе белән әнисе арасында хөкем сөргән начар мөгамәләне күреп үскән бала, һичшиксез, никахка берникадәр саклык, шикләнү белән карый.

Өченче сәбәп – хатын-кызның гаилә өчен әзер булмавы. Хәзерге заманда кыз бала, ир-ат шикелле үк, эш, уку, карьера мәшәкатьләре белән мәшгуль. Кайчакта аның эш көне 10-15 сәгатькә дә сузылырга мөмкин. Кая инде анда аш-су әзерләү, йорт, хуҗалык эшләре белән мәшгуль булу – кайт та ят, иртәгәсен тагын чыгып йөгер. Билгеле, мондый режимда яшәгән кыз бала өчен гаилә кору, йорт эшләрен башкару, балалар тәрбияләү авыр сынау булырга мөмкин. Ә ул сынауга һәркем әзер түгел...

Билгеле инде, әти-әниләр өчен баланы бәхетле итеп күрү – зур хыял. Яше җитеп тә кияүгә чыкмаган, оныклар белән шатландырмаган кызларын күп кенә әти-әниләр ничек тә гаиләле итәргә омтылалар. Таныш-белешләре яисә яучылар ярдәме белән кызына тиң кияү эзләп, туй хәстәрен күргәннәр. Әлеге тәҗрибәне кыюсыз, басынкы холыклы, кыз балаларның әниләре өчен яраклы. Ә инде көне-төне эштә «югалган», егет сайларга түгел, туйганчы йокларга да вакыты булмаган кызларның димләүгә тискәре мөнәсәбәте күзәтелергә мөмкин. Чөнки алар актив, үз дәрәҗәләрен, бәяләрен белгән кызлар. Әти-әниләренең кияү эзләп аларның азапланууларына ачуы гына чыгарга мөмкин. Мондый кызларның якыннарына сабыр итәргә генә кала – гадәттә, актив, максатчан кызлар, үз вакыты белән, тиң ярларын табалар. Балаларыгызга бу мәсьәләдә басым ясаудан сак булыгыз!»

PRESSA.RU

дип тәрбияләнгән аналар моны кабул итеп бетерә алмый. «Кайчан кияүгә чыгасың, әнә, мәңге кияү күрмәс дигән фәлән дустың да ярәшелде, ә фәлән яшьтәшең инде икенче баласын алып кайта», – дип, кызларын игәүли башлыйлар. Шул рәвешле, колак итен ашаулардан туеп, беренче очраган кеше белән гаилә корган кызлар да бар. Зурдан кубып туен уздыралар, бәхетле булыгыз, дип теләкләр әйтешәләр, бүләкләр бирешәләр. Ана кеше: «Күрдегезме, минем кыз да кияүгә чыкты», – дип, танышбелештән сөенчесен дә алып бетерми, кызы, чемоданын күтәреп, туган йортына кайтып та төшә. Җаны сөймәгән кеше белән тора димени хәзерге заманда кызлар?!

егетләрнең, җирдән аерыласы, «таш капчык» эчендә яшисе килми.

Шушындый вазгыятьтә ялгызакларны кимету эшенә бөтен республика күләмендә алынулары гаҗәп тә түгел. Татарстан Фәннәр академиясенең Гаилә һәм демография үзәге галимнәре ЗАГС идарәсе белән берлектә фәнни-тикшеренү проектын башлап җибәрде. Авылда яшәүче ир-атларның тормышкөнкүрешен өйрәнергә җыеналар. Белгечләр 44 сораудан торган махсус анкета да төзегән. Беренче булып энә күзеннән үткәреләчәк районнар саны 14: Азнакай, Актаныш, Алексеевский, Әлки, Баулы, Бөгелмә, Буа, Кайбыч, Кама Тамагы, Лениногорск, Лаеш, Тукай,

Өйләнергә теләмим

Айратка 34 яшь. Казаннан. Милли җанлы менә дигән татар егете. Үзе тыйнак, сабыр. Йөз-кыяфәте дә төшеп калганнардан түгел: ул буй дисеңме, киң җилкәләр, чем-кара чәчләр... Акчалы эше, яхшы чит ил машинасы бар. Инглиз телен су урынына эчә, сәяхәт итә, теләсә нинди темага әңгәмә алып бара ала. Бер генә килмәгән җире дә юк кебек инде. Менә шушы егет асылы өйләнмәгән, дисәм, ышанырсызмы? Ышанырсыз, чөнки андыйлар буа буарлык бүген. Югыйсә 34 яшь – өйләнергә соң да түгел кебек. Тик Айратның әти-әнисе борчыла башлаган инде. Егет башта эшендә югарырак дәрәҗәгә ирешим дип йөргән, гаилә корырга вакыт тапмаган. Аннары, әтиәнисе белән бергә торасы килмичә, ипотекага фатир алган. Ул фатирны торырлык хәлгә китермичә ничек өйләним инде мин, дип әйтә ди хәзер. Ә торак проблемасы хәл ителеп беткәч, башка сәбәп килеп чыкса?.. Аннан соң... Айратның өйләнү теләге бөтенләй дә сүрелә башлаган инде – шунысы аеруча борчый әти-әнисен.

Авыл саен буйдаклар...

Авылларда хәл тагын да яманрак. Буйдаклар саны артканнан-арта бара. «Без һәр районда 30 дан алып 50 яшькә кадәрге ир-атларның исемлеген төзедек. Бик куркыныч саннар килеп чыкты. Буйдаклар, кияүгә чыкмый калган кызлар кайсы районда да күп. Һәрбер җирлектә 800 әр, хәтта меңнән артык парсыз кеше яшәве ачыкланды», – ди «Ак калфак» хатын-кызлар иҗтимагый оешмасы рәисе Кадрия Идрисова. Бик рәхәтләнеп гаилә корыр иде ул буйдаклар, тик кызлар авылдан китеп бара шул. Ә авыл җанлы

Мөслим һәм Спас. Проект әйбәт кенә эшләп китсә, калган районнарны да җәлеп итәргә җыеналар.

«Ирләр шәһәрдән авылга күченергә риза. Ә менә хатын-кызлар кайтмый. Кайбер районнарда 40 яшькә җиткән ир-атлар гаилә кора алмый. Төп проблема әнә шул», – ди Гаилә һәм демография үзәге җитәкчесе Флера Илдарханова. Аның әйтүенчә, җавапларны өйрәнеп бетерү өчен ярты елга якын вакыт кирәк булачак. Уен эшмени: бөтен ил буенча беренче тапкыр үткәрелә бит әле мондый тикшеренү!

Анкеталарны таратып чыгарга өлгерүчеләр дә бар инде. Мәсәлән, Тукай районында 23 авыл җирлегенә 165 анкета таратылган. «Анкеталар – аноним. Бөтен буйдаклар да аларны мәҗбүри рәвештә тутырсын дигән бурыч куймадык. 18 яшьтән 60 ка кадәргеләрне исәпкә алабыз. 18 яше тулып та өйләнмәсәләр, чаң суга башлыйбыз дигән сүз түгел бу. Без бары тик авыл җирлекләрендә яшәүче ир-атларны демографик яктан өйрәнәбез генә», – ди районның ЗАГС идарәсе җитәкчесе Эльвира Мостафина.

Анкеталарны тикшергәннән соң, буйдаклар санын ничек кимету турында уйлый башлаячаклар. Кимету юлы бер генә – өйләндерү. Тик моның өчен башта кияүгә чыкмаган кызларны да исәпкә алырга, алардан ни өчен авылга кайтмауларын сорарга кирәк булачак.

Фәнни яктан тикшереп тормыйча гына да буйдакларны парлы итү эшенә керешүчеләр бар. «Ак калфак» оешмасы башлангычы белән һәр районда диярлек яучы-димче клублары эшли башлады инде. Әле декабрь аенда гына Азнакай районына димчеләр җыелган иде. Республика районнарыннан гына түгел, Түбән Новгород, Сочи, Ижау, Питер, Магнитогорск, Мәскәү калаларыннан, Башкортстаннан да кунаклар килде анда. Бергәләшеп «буйдаклар санын ничек киметергә» дигән темага баш ваттылар. «Азнакайда димчеләр клубы киң колач алды. Әйтик, Балтач районы егетләре анкеталарын Азнакай кызларына тәкъдим иткәннәр. Тиздән никах ашлары, туйлар гөрләп узар. Түбән Новгород белән Ульян өлкәсе димчеләре дә нәкъ шундый тәртиптә эшли», – дип яхшы хәбәр җиткерде Кадрия Идрисова.

Буйдакларга тагын бер комачауны җиңәсе бар: кеше ни уйлар, дигән фикерне баштан чыгарып, яучылар клубына гариза илтеп бирү. Юкса күбесен «үзе хатын да таба алмаган диярләр тагын» дигән хорафат тыеп тора.



Бер-берсенә юл куймый

Гаилә һәм демография үзәгендә аерылышуларның сәбәбен ачыклау ниятеннән тикшерү уздырганнар. «Ир дә, хатын да үзенчә яшәргә тырыша һәм берсе-берсенә юл куймый – күпчелек очракта аерылышуның сәбәбе шул. Икенчедән – матди як. Яшьләр фатир ала алмый, ипотека түләве бик авырга туры килә. Өченче урында гына хыянәт. Дүртенче сәбәп – яшь гаиләгә туганнарның кысылуы. Өлкәннәр, билгеле, ярдәм итәргә тели, тик бөтенләй киресе килеп чыга», – ди үзәк җитәкчесе Флера Илдарханова.

Аерылганчы – уйлагыз

Күпчелек буйдаклар өйләнергә ашыкмый, чөнки аерылышу артык кыйммәткә төшә, дигән сүз бар. Шаяртып әйтелгән, билгеле. Өйләнешкәндә, киләчәктә аерыласы, мал бүләсе, алимент түлисе булыр, дип уйламыйсың бит инде. Гомер буе тигезлектә бәхетле итеп яшәрбез, дип хыялланасың. Шулай кебек. Тик күптән түгел үткәрелгән сораштыру шуны күрсәткән: озак вакыт очрашып йөргән парлар нәкъ менә аерылышудан курыкканга күрә өйләнешмиләр икән! Мондый куркуларны санап китә башласаң, бөтенләй дә гаиләләр кормаска кирәк алайса: кайнана белән уртак тел табып булырмы, кайда яшәрбез, ипотека алсак, түләп бетерә алырбызмы...

«Мәңгегә бергә!» дип яши башлаганнарның да көннәрдән бер көнне гаилә касәсе чатный. Тик вакытында күреп алып, ябыштырмасаң, саклап тота башламасаң, урталайга ярылганын сизми дә каласың. Бүген Татарстанда гаилә корган һәр биш парның икесе аерылыша икән. 2015 елның гыйнвар-сентябрь айларында (соңгы өч ай буенча әлегә мәгълүматлар юк) Татарстанда 23 701 пар никахлашкан, шуларның 9 856 сы аерылган. Яхшы яңалык та бар: 2014 ел белән чагыштырганда, узган елның шушы 9 аенда аерылышулар 14 процентка кимрәк теркәлгән. Тик бу саннар тынычландырмый.

Статистика буенча, яшьләрнең күпчелеге өйләнешкәч тә 5 ел эчендә аерылыша икән. Ә узган ел бер гаилә бөтенләй рекорд куйган – бергә торуларына бер атна дигәндә үк аерылышырга гариза биргән.

Бүген мөселман гаиләләре арасында да аерылышулар аз түгел. Хатын-кызлар ирләрдән артык күпне өмет итә, кайберләре эшләргә яратмый. Имештер, мөселман гаиләсен ир кеше алып барырга тиеш. Ә икенче очракта, киресенчә, мөслимәнең дә кеше арасында буласы,ниндидер эш башкарасы килә. Тик ире аңа каршы төшә, янәсе синең урының – өйдә. Нәтиҗәдә, гаилә таркала.

Узган ел Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов аерылышу процедурасын катлауландыру тәкъдиме белән чыккан иде. ЗАГС идарәсе гамәлдәге законга үзгәреш кертү турында проект та әзерләп бирергә өлгерде. «Гадәттә, гаиләне таркату ниятен беренче булып хатын-кыз әйтә. Гүзәл затлар хискә тиз бирелүчән бит, шул сәбәпле, тормыш иптәше белән беренче ызгыштан соң ук аерылышу турында судка гариза язучылар бар. Якын чит илләрдә аерылышу гаризасының каралу вакыты Россиядәге кебек үк – бер ай. Ә менә ерак чит илләрдә мондый гаризаны карау еллар буена сузыла. Анда ир белән хатынга, рәсми рәвештә аерылышканчы, аерым яшәп карарга вакыт бирелә. Ялгыз яшәүнең авырлыгын татыган күпләр яңадан кушылу ягын карый. Без дә аерылышу турындагы гаризаның каралу вакытын озайтырга телибез», – ди ЗАГС идарәсе җитәкчесе Альбина Шәвәлиева.

Италиядә, әнә, аерылышу ким дигәндә 3 елга сузылырга мөмкин. Ә милекне бүләсе булса, балаларның кем белән калуы хакында бәхәс чыкса, аерылышу дистә елларга хәтле сузыла. Франциядә исә аерылышу иң кыйммәтлесе санала. Гаиләне рәсми рәвештә таркату өчен якынча 1000–4000 евроны чыгарып салырга туры киләчәк. Французлар, өйләнешкәнче үк «аерылышасы булса, акчам җитәрме», дип уйлап куя торгандыр.


Татарстан ЗАГСы аерылышу турындагы гаризаның каралу вакыты узганчы кул кушырып утырырга җыенмый. Быелның гыйнварыннан идарәнең рәсми сайтында «Гаилә консультациясе» дип аталган интернет хезмәт булдырылды. Психолог белән күзгә-күз очраша алмаучылар сорауларын интернет аша юллый ала. ЗАГС идарәсе җитәкчесе урынбасары Ренат Әхмәтҗанов белдергәнчә, бүгенгә унлап мөрәҗәгать кергән инде. Аларның барысына да тәҗрибәле психологлар җавап әзерләгән.

Ренат Әхмәтҗанов быел башлангыч алган тагын ике проект турында сөйләде. Беренчесе «Гаиләне саклыйк» дип атала. Ул «Ышаныч» социаль хезмәт күрсәтү үзәге һәм коммерцияле булмаган «Наше поколение» оешмасы ярдәмендә гамәлгә куела. «Гыйнвар аенда гына да медиаторлар белән сөйләшүгә 44 пар язылган. Анда катнашкан 25 парның 15 е инде аерылышудан баш тарткан. Бу гаиләләрдә барысы да яхшы булыр», – ди Ренат әфәнде. Киләчәктә ЗАГС идарәсе аерылышырга җыенган һәр парны психолог белән очраштырырга ниятли.

Гаиләгез таркалу алдында торамы? Ирегез белән аңлаша алмыйсызмы? Психологка барырга кыенсынасызмы? Белгечкә үзегезне кызыксындырган сорауны өйдән чыкмый гына да бирергә була. www.zags.tatarstan.ru сайтына кереп, «Гаилә консультациясе» бүлеген табыгыз һәм соравыгызны языгыз. Кыска вакыт эчендә тәҗрибәле психолог сезгә җавап бирер.

ЗАГС идарәсенең «УМАЙ» Идел буе гаилә академиясе белән берлектә башлап җибәргән проекты исә аерылышу алдында калган парларга психологик ярдәм күрсәтүгә юнәлдерелгән. Автономияле коммерцияле булмаган оешманың директоры, ТР Иҗтимагый палатасының социаль сәясәт буенча комиссия җитәкчесе Татьяна Леонтьева белдергәнчә, гыйнвар-февраль айларында «УМАЙ» белгечләре 25 пардан гариза кабул иткән. Күпчелеге – 7-10 ел бергә яшәгән гаиләләр. «Безнең белгечләр элеккеге мөнәсәбәтләрнең ир өчен дә, хатын өчен дә әһәмиятен ачыкларга һәм, әгәр теләкләре булса, яңадан кушылырга ярдәм итә. Гаилә психологы, карар кабул иткәндә, беркайчан да ир белән хатынга басым ясамый. Практикада шундый хәлләр дә була: рәсми рәвештә аерылышканнан соң, җиде ай узгач, мөнәсәбәтләрне җайлауда ярдәм итүебезне сорыйлар. Шуңа күрә гаилә психологы парлар белән бер ел эшләгәннән соң гына ниндидер нәтиҗә турында сөйли ала», – ди Татьяна Леонтьева. Гаилә психологына (843) 245-33-91 номерына шалтыратып язылырга мөмкин. Белгеч белән күзгә-күз очраша алмаучылар сорауларын http://umai.su// сайтында язып калдыра ала.

PRESSA.RU


Автор фотосы

КИРЕЛЕКМЕ, ҮЗСҮЗЛЕЛЕКМЕ?



Ландыш ӘБҮДӘРОВА

КИРЕЛӘНМИ ТОРГАН БАЛА БАРМЫ ИКӘН УЛ? ШУНДЫЙ БАЛАЛАР БУЛА, ӘЙТЕРСЕҢ ЛӘ, АЛАР ӘТИ-ӘНИСЕН ЧЫГЫРЫННАН ЧЫГАРЫР ӨЧЕН МАХСУС КИРЕЛӘНӘ. БАЛАЛАРДА ЕШ ОЧРЫЙ ТОРГАН БУ СЫЙФАТКА КАРШЫ КӨРӘШЕРГӘМЕ? НИЧЕК ИТЕП?

Урамга уйнарга чыгарга җыенабыз. Кызымны мультфильмыннан аерып алу өчен шактый үгетләргә туры килде. Аның, бөдрәләрен уйнаклатып: «Тагын аз гына карыйм да, аһа?» – дигәненә каршы килә алмыйм – шундый матур итеп сорый... Киенә башлагач, озак кына кием сайладык. Җәйге күлмәген табып алган да шуны киеп чыкмакчы була. Урамда декабрь, кыш икәнен ничегрәк итеп аңлаталар соң ул ике яшьлек балага? Урамда салкын, күлмәкчән генә чыксаң, өшисең, аннан соң чирлисең, Маша Аюны кура җиләге белән дәвалаган кебек, сине дә дәвалыйсы була, дим. Бераз гына көйгә килгәндәй була да тагын

үзенекен сөйли башлый. Ятып кына торырга туры киләчәк, «врач апа»ны чакырасы була, ул укол кадый, әле хастаханәгә үк алып китәргә мөмкин, дим. «Врач апа»дан куркабыз анысы, тик бу юлы кирелек көчлерәк булып чыкты. Үтми, үз туксаны – туксан. «Күлмәк өстеннән яңа алган кышкы куртканы киям», – ди.

– Алай гына салкын була. Әнә, ишек төбендә песи көтеп тора, киенеп чыкмасаң, Зөлфия белән уйнамыйм ди.

– Кая? Әйтмәде бит.

– Дәү әтисе, син әле генә урамнан кердең, сиңа әйттеме?

Зөлфияне дәү әтисе белән бергәләп үгетлибез. Артистланырга туры килә. Тырыша торгач, күнә. Җылы кофтаның җиләклесен киеп чыгарга риза була, чөнки күрше кызы Әминә дә шундыен киячәк, имеш... Уф! Тиз генә үзем киенеп куям. Инде аяк киемнәренә чират җитте. Бала тирләгәнче дип, Зөлфиядән алданрак аның ботинкаларын батарея өстеннән алып, алдына куям.

– Тимә минем ботинкаларга, мин үзем ала идем аларны, кире куй!.. – дип, күз яшьләре белән елап җибәрә Зөлфия. Бу юлы еламый калырбызмы әллә, дигән идем?! Тиз генә ботинкаларны урынына куям, ләкин соң инде. Зөлфиянең кәҗәкәе бер килдеме, тиз генә китәр, димә. «Дөрес куймадың, алай тормый иде алар!» – дип, тагын да катырак елый башлады бу. «Ничек тора иде соң? Болаймы?» – дип, турылап куям. «Юк!» – дип, урынында тыпырдый кызым. Тәгәрәп тә китә. Шул вакыт минем дә сабырлыгым төкәнә, шушы кечкенә генә Кирлемәнне тыңлата алмавыма ачуым куба. Буран булып.

...Менә мин дә монстрга әйләндем инде болай булгач. Бераздан без балам белән икәүләп елыйбыз: мин гарьләнеп, балам кыланмышлары өчен үкенепме, куркыпмы – анысын белмим. Бу минутларда бала тәрбияләү турында укыган китаплар да, мәкаләләр дә онытыла. Алар бит беравыздан: «Бала тәрбияләү – беренче чиратта, түземлек, сабырлык. Беркайчан да балага тавыш күтәрмәгез. Бу сезнең көчсезлегегезне генә күрсәтә...» – дип язалар. Әйе, мин Сухомлинский да, Спок та, Соловейчик та түгел, гап-гади әни. Шуңа күрә дә бәләкәй баланың кирелеге мизгел эчендә глобаль масштабтагы хисләр бәрелешенә әйләнә.

Бераздан безнең өйдә давылдан соңгы чалт аяз һава торышы урнаша. Тынычлангач, башка беркайчан да балама тавыш күтәрмәм, дип, эчемнән генә ант итәм, үз-үземне талыйм, көчсезлектә гаеплим, аннан гафу үтенеп, кирәксә дә, кирәкмәсә дә иркәлим. Кызым да иркә песи кебек, ник бер карышсын! Гәрчә болай тиеш түгеллеген белсәм дә, башкача булдыра алмыйм... Күрәсең, мин начар әни, дигән бәя куям үземә.

Без дә үстек анысы. Безне дә әниләр үзләренчә тәрбияләгәннәр. Без дә шулай әни чыгырыннан чыкканчы «тырыша» идекме икән? Ничек инде, шуның кадәр китап укып, шуның кадәр тәрбия ысуллары белән танышыпмы? Шик корты өчен өлгереп җиткән алма үзем, һәр адымымны «дөрес эшлимме?» дип шик астына куям. Әә бит безнең әниләр тәрбия ысулының бусын кулланыйммы, тегесенме, дип тормаганнар. Һәрхәлдә, әнинең «без сине японнарча, йә булмаса Көнбатышча тәрбияләдек», – дигәнен хәтерләмим. Бездә тәртип авылда яши торган чып-чын татар гаиләсендәге кебек иде. Өлкәннәр эштә, зуррак балалар кечкенәләрне караша, үскән саен баштарак әби-бабайның кул арасына керә, аннан соң тыштагы мәшәкатьләрне дә үз өстенә ала башлый. Ай-һай, ул вакытта әнинең ике яшьлек кызын җитәкләп, көпә-көндез урамда һава сулап йөрергә вакыты булдымы икән? Ә без менә башка заманда яшибез, баланы урамга һава суларга махсус алып чыгарга кирәк. Ә анда шундый ук нәниләрен җитәкләп йөрүче әниләр. Алар белән тәҗрибә уртаклашу, мәгълүмат алышу – кем ничек тәрбияли, кем нинди тәрбия ысулын куллана һәм башкалар.

Әллә хәзерге заман балалары гына шушы рәвешле «бозыкмы»? Әллә үзем тәрбияли белмимме?

Мин дә шундый кире идемме, дигән соравыма әни «булгандыр инде», дип кенә җавап бирде. Киреләнгән вакытта әни нишләде икән: юмалаганмы, үгетләп караганмы, ачулангандырмы, көйләгәндерме? Ничек итеп җайга китерде икән? Аларын хәтерләмим, әмма ишек кашагасындагы сыек чыбык хәтердә. Сыек чыбыкны әче төшә, диләр. Әмма арт якның сыек чыбыктан кызышканы истә калмаган. Чыбыкны үсеп беткәч, өй юганда алып ташладык – ничә еллар шунда кыстырылган килеш торды ул кисәтү булып, кирәге чыкмаганлыктан яңасына алыштырылмаган, корып беткән иде. Димәк, истә калырлык дәрәҗәдә киреләнү булмаган – монысы өчен шөкер. Ә менә кызымның кирелеге белән нишләргә? Алга таба болай дәвам итсә... Интернетта укыган бер мәзәк искә төшә: Бер яшь әни баласына ботка ашата. Бала кулларын бутый, бөтен киеме, битекуллары, өстәл җәймәләре боткага буялып беткән. Ә әни кеше баласының ашавыннан канәгать, йөзендә елмаю балкый икән. Моны яшь хатынның ире күзәтеп утырган да: «Син ниндирәк антидепрессантлар кабул итәсең? Һәм күптәнме?» – дип сораган.

Әйе, бу кирелек алга таба да шушы рәвешле дәвам итсә, Ходай биргән сабырлык кына җитәр микән?

Әни оныгының кирелеген артык иркәлектән күрә: «Балага «юк» дип әйтә белергә кирәк», – ди ул. Зөлфия – көтеп алынган бала, әти-әнисенең генә түгел, дәү әтисе белән дәү әнисенең дә иркә кочагында үсә. Кайнанам кызымның бу сыйфатын үзенчә аңлата: «Бала әле ул, иркәләнсен, аңлый башлагач, үз җае табылачак, кирелек түгел, үзсүзлелек, – ди. – Үскәч, аның үзсүзлелеге аңа файдага гына булачак», – дип тә өсти. Ә мин кирелеккә җавапны төрлечә эзләп карыйм: кайчак катырак торам (монысы әти-әниләр ысулы), кайчак юмалыйм (монысы әби-бабайлар, дәү әти-дәү әниләр

PRESSA.RU

ысулы, алар баланың баласы балдан татлы, дип яши, шуңа да үз балаларына биреп бетермәгән иркә-назны оныкларына биреп өлгерергә ашыга, ә үз балалары үскәндә, алар эштә булган), кайчак кызымның теләген берсүзсез үтим (монысы японнарча кыланып карау, тибет ысулы дип тә әйтәләр аны). Әйтик, күн итек белән көзге суны ерып йөреп салкын тидердек тидерүен. Кайчак саңгырау һәм сукыр булып кыланам (бәлки, бусы минем организмның үз-үзен саклау инстинктыдыр), кайчак үзем киреләнә башлыйм, үпкәлим (монысы сабыр төкәнгәч, үз-үземне контрольдә тота алмый башлагач), ләкин боларның берсе дә ниндидер формула итеп кабул итерлә алмый һәм киеренкелекне һич тә җайга салмый.

Әнә шулай итеп, бала тәрбияләү белән үз-үзеңне тәрбияләү арасындагы чик беленер-беленмәс кенә калганда, кызымның кирелегенә ачкыч та таба яздым.

Кирелек өянәге ничек кинәт барлыкка килсә, шулай ук юкка да чыга, кызым үзен берни булмагандай тота башлый. Һәм шул мизгелдә бу кирелекнең үзенә күрә әнилеккә имтихан икәнен аңлыйсың: тынычлан, дим үз-үземә, син әле генә яхшы әни булырга тест үттең, аны иң яхшы психолог – кызың үткәрде! Ә аның бераздан берни булмагандай уйнап йөрүе – үзе бер педагогик могҗиза!

Мин еш кына аңа вариантлар тәкъдим итәм: урамга чыгасыңмы, әллә уенчыкларыңны җыясыңмы? Күлмәкнең бусын киясеңме, әллә монысынмы? Үзең чишенәсеңме, әллә мин булышыйммы? Зөлфия шушы рәвешле сайлау алдында калганда, күбрәк мөстәкыйль башкара алырдай вариантны сайлый, аңа болай күбрәк ошый. Димәк, минем балам чыннан да үзсүзле, үз дигәненә ирешүчән булачак дигән нәтиҗә ясыйм моннан.

Алга таба Зөлфиянең кирелеге йомшарды, ә аңа өч яшь тулганда без аның белән уртак телне тизрәк табарга өйрәндек. Иң мөһиме – мин аның бу сыйфатына каршы көрәшергә кирәк түгеллеген аңладым. Бу сыйфат аның табигатендә. Димәк, аны тыңлаучан итәргә тырышу – баланың шәхесенә, мин-минлегенә тиячәк, алга таба аны йомыкыйлыкка этәрәчәк. Беренчедән, мондый балага тавыш күтәрә, борын төбендә йодрык уйната торган ата-ана берничек тә абруй, дәрәҗә казана алмаячак. Гомумән, баланы кычкырып җиңеп булмый (бәлки, берәр тапкыр куркытып буладыр). Бала, андый кешегә якынаймаска тырышачак. Димәк, үсә-үсә ул үзе өчен абруйны читтән эзләячәк. Икенчедән, ишетмәмешкә-күрмәмешкә салышу кадәресе дә дөрес алым түгел. Балага битараф булып кылану аны зур психологик кичерешләргә этәрү булыр иде. Ул үзен кирәксез итеп хис итә һәм моның киресен исбатлау өчен бала, ничек булдыра ала, шулай игътибар даулый башлый. Кечкенә бала моны инстинктив рәвештә эшли, аңлый башлагач, нәтиҗәләре төрле булырга мөмкин. Ә бит ул игътибарның инде бөтенләй кирәкми башлавы да бар. Әлбәттә, моңа юл куярга ярамый. Шуңа да бала киреләнә икән, аның бу сыйфатын киләчәктә үзенә ярдәм итәрдәй юнәлешкә борып җибәрергә кирәк. Ярату, түземлек һәм тагын бер тапкыр түземлек аша.


Үпкәчел балалар турында сайтыбызның «Әни көндәлеге» сәхифәсеннән укый аласыз.

киңәш

Мондый киребеткәнлеккә нәрсә китерә?

■ Бәләкәчегез гадәти көннәрдә сезне сирәк күрә, үзенә игътибар җитмәүдән тилмерә. Шуңа яллар җитүгә үзенең канәгатьсезлеген шулай чыгара. Гаиләгезгә күбрәк вакыт бирергә тырышыгыз, бергәләп табигатькә чыгыгыз – бу хәлдән шулай гына котылып була. Менә шундый аралашулардан ул бик канәгать кала, әти-әни яратуын тоеп үсә, үзе дә инсафлы, аңлый белә торган бала булып үсә.

■ Моңарчы нарасыегызның көен көйләп, бер көнне моны туктатсагыз, ул аптырап калачак. Һаман үз сүзен сүз итеп, кәҗәли башлаячак.

■ Кирәгеннән тыш кайгырту, тыюлар балада ризасызлык тудырып, көннәрдән бер көнне ул: «Мин үзем!» – ди киреләнә башлаячак.

■ Әтисе юл куя, әнисе – юк. Менә шуннан баланың үз-үзен тотышында каршылыклар килеп чыга инде. Гаиләдә бөтенесе бер сүздә булсын.

■ Балаларның барысын да тигез күрергә кирәк, берәү дә читтә ала карга булып калмасын.

Тыныч хәл итү юллары:

■ Балагыз сораган курчакны сатып алалмаганга еласа, аңа өйдә төрле материаллардан бергәләп ясарга тәкъдим итегез. Бергәләп өй җыештыру, ашарга әзерләү ошар аңа. Үзенең кирәклеген аңлар. Олы кеше булуыгызны читкә куеп, үзегез дә балачага кебек берәр уенга катнашып китегез. Мәсәлән, «өйле» уйнагыз. Сез – бала, ә ул әти йә әни булып уйнасын. (Уенда ул һәрчак – баш, әти-әни укучы хәлендә генә.) Сездән алган тәрбия дә чагылып китәчәк. Үзегезгә читтән карый аласыз.

■ Өзми-куймый елап-бәлаләп торган баланы үзен генә калдырыгыз. Берәү дә игътибар итмәгәнен аңлап, туктаячак. Баланың игътибарын башкага юнәлтү дә истерикалардан арындырачак. Мәсәлән, «Кара, нинди күз яшьләре әрәм була! Әйдә, аны бер савытка җыйыйк әле!» яки «Күр, җилкәңә Кирлемән менеп утырган бит! Куып җибәрик тизрәк!» – дип елауны «оныттырып» була. Әкиятләр укуга, мультфильм карауга күчеп тә тынычландырып була.

■ Сүз тыңламыйча тискәреләнгән чагын балагызга кабатлап күрсәтегез. Үзенә читтән карап, башка алай эшләмәячәк. Сабыр булыгыз! Җәза кулланмыйча гына, балагызга үтемле һәм аңлаешлы итеп аңлатыгыз! Иң элек үзегезне матур тотыгыз. Килешә алмыйча, туктаусыз талашып торган әти-әни нинди үрнәк булсын инде!

ҖӘМГЫЯТЬ



■ Россия Президенты Владимир Путин Чаллыга эшлекле визит белән килеп, Кама автомобиль заводы конвейерыннан беренче КамАЗ йөк машинасы чыга башлауга 40 ел тулу уңаеннан оештырылган тантанада катнашты. Аннары ул видеоконференция режимында Менделеевскидагы аммиак, метанол һәм гранулаланган карбамид җитештерү буенча «Аммоний» комплексын эшләтеп җибәрде. Чарада Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм Миңнеханов катнашты.

■ ТР Дәүләт Советы һәм җирле депутатлар гомуми белем бирү мәктәпләрендә «Парламент дәресләре» үткәрә. Традициягә әйләнгән бу чараның быелгы темасы — «Гражданин, җәмгыять, дәүләт». «Парламент дәресе» барышында игълан ителәчәк конкурсларга апрель аенда, Парламентаризм көне алдыннан йомгак ясалачак.

■ ТР Президенты Рөстәм Миңнеханов Мәскәүгә эшлекле визит вакытында яшь татар кинематографистлары башкаланың татар милли һәм дини җәмәгатьчелеге вәкилләре ярдәме белән төшергән «Вера» («Иман») дигән документаль фильмны карады. Эпизодларның берсе Татарстан Республикасы Дәүләт киңәшчесе Минтимер Шәймиевкә багышланган. Татарстанның беренче Президенты республикада гамәлдә булган диннәрне саклау турында сөйли.

МӘДӘНИЯТ

■ Казанның «Хәзинә» Милли сәнгать галереясында герой-шагыйрь Муса Җәлилнең тууына 110 ел тулуга багышланган күргәзмә ачылды. Сынлы сәнгатьтә Җәлил образын сурәтләгән күргәзмәдә Татарстан рәссамнарының утыздан артык хезмәте урын алган. Сәнгать сөючеләр Х. Якупов, И. Язынин, И. Рәфыйков, В. Куделькин, В. Аршинов картиналары, С. Ахунов һәм В. Маликов иҗат иткән сыннар белән таныша ала.

■ С. Сәйдәшев исемендәге Зур концерт залында беренче тапкыр атаклы татар композиторы Нәҗип Җиһанов исемендәге «Мирас» татар музыкасы фестивале узды. Анда Н. Җиһанов, З. Яруллин, А. Монасыйпов, Л. Любовский, Р. Яхин, Р. Ахиярова, Ш. Шәрифуллин әсәрләре яңгырады.

КОТЛЫЙБЫЗ



■ «Татарстан гүзәле-2016» республика бәйгесендә 18 яшьлек Лениногорск кызы Диләрә Ялалетдинова җиңүче булды. Ул Идел буе физкультура, спорт һәм туризм академиясендә I курста укый. Нәфис гимнастика буенча Россия спорт мастеры. «Татарстан студентлары чибәре-2015» конкурсы җиңүчесе.

МӘГАРИФ

■ Бөтенроссия М. Җәлил укулары каһарман шагыйрьнең тууына 110 ел тулуга багышланды. Анда «Муса Җәлил XXI гасыр кыйммәтләре призмасы аша һәм иҗат» темасы яктыртыла. Фикер алышу мәйданнарында Муса Җәлилнең тормышы, иҗаты, әсәрләренең теле турында сөйләшәләр.

■ Казанда төрле милләт вәкилләренең үзара дус һәм тату яшәве, толерантлык проблемаларына багышланган халыкара гуманитар форум узды. Республикабыз 173 милләт кешесенең Ватаны исәпләнә. 2014—2020 елларга каралган милли сәясәт программасы тормышка ашырыла.

СПОРТ



■ Казанда Бадминтон үзәге ачылды. Чарада ТР Президенты Рөстәм Миңнеханов, Бөтендөнья бадминтон федерациясе президенты Поуль-Эрик Хейер Ларсен, Россия Илкүләм бадминтон федерациясе президенты Сергей Шахрай, ТР яшьләр эшләре һәм спорт министры Владимир Леонов һәм башкалар катнашты.

■ Зәйдә «Яшьлек» боз сараенда герой-шагыйрь М. Җәлил истәлегенә татар-башкорт милли көрәше буенча республика турниры узды. Аны гамәлгә куючы «Ватаным Татарстан» газетасы. Турнирны Милли көрәш федерациясе җитәкчесе, ТР Премьер-министр урынбасары — ТР авыл хуҗа-лыгы һәм азык-төлек министры Марат Әхмәтов җитәкли.

АВЫЛ ХУҖАЛЫГЫ

■ ТР селекционерлары беренче тапкыр Татарстандагы климат шартлары өчен яраклы «Кортни» һәм «Регги» бәрәңге сортларын уйлап тапканнар. Аның уңышы башка сортларныкыннан 15-18 процентка артык. Су сипмәсәң дә, бу сортлар гектарыннан 300 центнер уңыш бирә, йогышлы авыруларга да чыдам.

СӘЛАМӘТЛЕК

■ Татарстан Дәүләт Советының Социаль сәясәт комитеты һәм сәламәтлек өлкәсендә дәүләт программасын гамәлгә ашыру Комиссиясе белән берлектә Балалар хосписында утырыш булып узды. Утырышта өметсез авыруларга соңгы көннәренәчә ярдәм итү, бөтен уңайлыклар тудыру, физик һәм рухи ярдәм күрсәтү мәсьәләсе күтәрелде.

PRESSA.RU



Фото интернеттан алынды

ЯЗЛАР ГЫНА КАБАТЛАНА...

Гөлнур ХӘСӘНШИНА

«УРТА ЯШЬТӘГЕЛӘР КРИЗИСЫ» ДИГӘНЕБЕЗ «ЯШЬ ХАТЫН ЯНЫНА ЧЫГЫП КИТТЕ», ДИГӘН СҮЗ ТҮГЕЛ ӘЛЕ УЛ. РАМИЛӘ ДӘ, БЕЗ ДӘ АҢЛЫЙБЫЗ: ӘЛЕГӘ «ТҮГЕЛ». КИНӘТ КЕНӘ ЯШЬЛЕГЕНӘ КАЙТЫРГА УЙЛАГАН ИРДӘН ТЕЛӘСӘ НИНДИ АДЫМ КӨТӘРГӘ БУЛА.

Рамиләнең ире өйдән чыгып китте... Гел дус-тату гына яшәмәсәләр дә (сүзгә бер дә килми торган гаиләләр булмыйдыр инде ул!), аларның аерылышуына барыбыз да шаккаттык. Мондый адымга барыр өчен шактый җитди сәбәп кирәк бит! Читтән караганда бар дөньялары җитеш кебек иде: иркен фатир, икесендә ике машина, уллары үсеп килә... Тагын ни кирәк?! Без генә түгел, Рамилә үзе дә аптырап калган иде шикелле. «Очрашып йөри торган кешесе булса, сизәр идем. Үзем белми калсам, бу хакта кайнанам барыбер берәр ничек белгертер иде. Сөйләшеп торабыз: «Өйгә кунарга кайтмыйча калганы юк», – дип әйтми». Уллары әтиләре янына барып тора, аралашалар. Рамиләнең әйтүенчә, соңгы вакыт дәү әниләреннән кайткач, гел бер сүзне сөйлиләр икән: «Әни, безнең әтигә нидер булган. Үзгәргән ул. Кич унбердән дә калмыйча йокларга ята. Спортзалга йөри. Кыздырган, майлы ризыклар ашамый, дәү әнигә боткалар гына пешерергә куша».

– Димәк, анда кризис... – дип нәтиҗә ясый Рамилә.

Менә шулай... Балаларның башта өч яшьтә, аннан алтыда, соңрак яшүсмер чорда кичергән кризисларыннан, ниһаять, чыгып, «Аллага шөкер!» – дип, җиңел суларга өлгермисең, иреңнең кризис вакыты килеп җитә. Телевизор бүген бертуктаусыз сөйләп торган кризис кына түгел инде бу (анысы ил белән күтәргәне: кагылса – кагыла синә, кагылмаса – читләтеп уза). Яшүсмер улыңның яки кызыңның әледән-әле өйдә давыл куптаруы белән генә дә чагыштырып булмыйдыр. Утыз биш-кырык яшьлек ир-ат бит бу! Монысы – җир тетрәү, өермә, туфан, янартау атуы! Мондый цейтнотка эләккәннәргә Ходай сабырлык бирсен: уйлар өчен вакыт юк дигән сүз, ә менә ниндидер адым ясарга кирәк.

Ирләрдә «урта яшьтәгеләр кризисы» кайчан башлануын төрлечә гоманлыйлар: 35-40 яшьләр арасында дип тә язалар, 37-42 яшьләр тирәсендә дә, диләр. 50 гә кадәр дәвам итә дип тә куркыталар. Көнен-сәгатен, әлбәттә, берәү дә белми. Аннан бер көнне эчтә «будильник» шалтырый. Нигәдер шимбә иртәсендә буладыр кебек тоела бу хәл. Ир иртән уяна. Беркая ашыгасы юк. «Миңа бит инде кырык тула, – дип уйлана башлый ул. – Кырык! Илле ягына чыктыңмы, картлыкка инде бер генә адым кала дигән сүз... Яшәп тә бетердемме икәнни?! Чынлап та, бөтенесе инде артта калдымы?!»

Иртәне мондый уйлар белән башлаган ирнең көндез кәефе ничек буласын күз алдына китерү кыен түгел инде... Алга таба хәлләр тагын да катлаулана. Ир үз эченә бикләнә, өйдәгеләрнең берсе белән дә ачылып сөйләшми башлый: дәшсәләр, ишетмәмешкә салыша яки усал, төксе итеп кенә җавап кайтара. Ә башында бертуктаусыз уй кайный!

«Ярый, фатир алдым (йорт салдым). Машинам бар. Җәй саен кайдадыр ял итә алам. Хатын да чибәр генә. Балалар да үсә. Эшем дә начар түгел шикелле. Барысына да ирешкәнмен бит инде. Ә алга таба нишләргә? Яшәүнең, бу җиргә килүнең мәгънәсе, гомумән, нәрсәдә икән соң? Мин дөрес яшимме, юкмы?»

Хәтта барысы да әйбәт булганда да аның кәефен төшерерлек мең сәбәп «табыла». Ул бернәрсәдән дә кызык тапмый башлый. Кырык яшь – егерме дә түгел, утыз да. Ир-ат бу яшьтә үткән елларына карап нәтиҗә ясый. Аның өчен тормыш кыйммәтләре үзгәрергә дә мөмкин.

«Әйе, хатын ярыйсы әле... Тик ул бит әллә кайчан үз кешегә әйләнде. Якын бер туган кебек. Әйтик, әни кебек... Яшьлектәге икебезне бәйләп торган хисләр күптән сүнде, без фәкать бер-беребез каршында бурычлы гына. Ә бурыч кешене берничек тә бәхетле итә алмый... Уртак түшәк күптән суынды. Аның белән якынлык егерме ел элеккеге кебек рәхәтлек, ләззәт бирми инде... Бернинди яңалык, бернинди сер юк... Һәм барысына да ул – хатын гаепле!»

Өстәвенә, ирнең сәламәтлеге белән бәйле ниндидер проблемалар туса – кай ара йөрәге чәнчеп куйса, бавыры борчыса, канында холестерины артып киткәне күренсә... Өйдәгеләргә каравыл кычкырасы гына кала! Ә инде аның күңеленә ирлек көче җәһәтеннән шик керсә – дөнья бөтенләй бетә. Монысын ун баллы җир тетрәү белән генә чагыштырырга буладыр. Хатын-кызның целлюлит, җыерчыклар дип борчылуы моның янында чүп кенә...

Гаилә бу шаукымнан исән-имин чыгамы, юкмы – хатын-кыздан тора.

Ярый, гаепле табылды... Аңа хәзер дөньяның бөтен гаебен өяргә була!

Ирнең әледән-әле кабатлап торган кайбер җөмләләрен, исемлек итеп төзеп, суыткычка магнит белән ябыштыра аласыз. Ачуы купкан саен, яңа «гаеп» уйлап чыгарып азапланмасын әйдә:

- Җүләр сораулар бирмә! Минем белән ни булганын барыбер аңламыйсың!
- Синең белән бернәрсә хакында сөйләшеп булмый! Бар белгәнең – өй, балалар, дус кызларың...
- Гомер буе эштән башканы белмәдем. Миңа да үзем өчен яшәргә ярыйдыр бит?!
- Нәрсә дип түзәмдер?! Мин дә бит бер генә тапкыр яшим!
- Син мине бөтенләй аңламыйсың! Мин бу йортта берәүгә дә кирәкмим!
- Хәлеңнән килсә, һава да сулатмас идең! Ни дип бертуктаусыз артымнан күзәтәсең?
- Проблемадан гына торган нинди йорт бу?! Балаларны син шулай тәрбияләдең! Мин гел эштә булдым, акча эшләдем, ә син менә ни белән шөгыльләндең икән, белмим...
- Сезнең бөтенегезгә дә миннән гел нәрсәдер кирәк!
- Спорт белән шөгыльләнер идең, ичмасам, тәмам җәелдең бит инде!
- Итәк кигән ир-ат кебек син. Яныңа ятасы килми!
- Телеңдә – эш тә, яңа күлмәк кенә. Гаиләң барын оныттың!

PRESSA.RU

Карашы үзенең көзгедәге сурәтенә төшкәндә генә азрак тынычланып кала ул: «Кыяфәт ярыйсы бит әле! Бәлки, юкка хафаланамдыр?! Чынлап та, әле кич җитмәгән бит! Нәрсәнедер үзгәртергә дә мөмкин! Өлгерәм!»

Берәүләре, яшьлеккә кире кайтыр өчен, Рамиләнең ире кебек, сәламәтлеген ныгытырга керешә, спорт белән шөгыльләнә башлый. Диета саклый, спортзалга йөри. Яшьләрчә киенүгә күчә.

Аның поезды әле китмәгән, аның соңгы вагонына бик җиңел генә сикереп утыра алачак ул!

Икенчеләре кинәт кенә эшен алыштыра. Бер танышымның җитәкче булып эшләгән ире (кризис бер ир-атны да урап узмый!) кинәт шундый фикергә килде. Районда алдынгы җитәкчеләрдән санала, бөтен эше көйләнгән, даны-дәрәҗәсе бар иде. «Барысын да ак кәгазьдән башларга телим!» – дип, ерак бер районга ук күчеп китте ул. Хатынын үзе белән чакырмады. («Синен беркайчан да кичтән аяк киемемне сөртеп куйганың юк!» – гомер иткән кешесенә карата иң зур «гаеп» шул булды. Хәер, тагын берсе бар әле: «Машинаңа үзең бензин да сала белмисең!») Ярый, китте... Яңа урында шактый таркалган хуҗалык бирделәр. Аны аякка бастырыр өчен еллар кирәк булачак. Яшьлектәге көч-дәрт кабатланмый, мөмкинлекләр чикле булганда тәҗрибә дә бик ярдәм итми. Монда ике катлы йорты калды, ә анда – кеше почмагында тора. Терсәк якын да бит, тешләп булмый – ничек кенә үкенсәң дә, кирегә инде юл юк.

Өченчеләре... Статистика мәгълүматлары буенча, иң күп аерылышулар шушы чорга туры килә. Әйе, ир-ат, тәвәккәлләп, шундый адым ясарга да мөмкин... Үзенә сокланып, яратып, горурланып карый торган карашларга мохтаҗ ул бу чорда. Яшьлектә кавышкан хатынга нәрсә: «Әйе, булдырдың! – дияргә мөмкин ул. – Ләкин әле менә монысын да эшлисең бар...» Ире ирешкәннәр аңа табигый булып күренүе гаҗәп түгел.

Убырлы карчык... Хатыны бер көн ирнең күзенә шулай күренә башлый. Аның белән бер йортта яшәү төрмәдә яшәү кебек тоела. Ә кем инде үзе теләп тоткында көн итсен?! Кырык яшьлек хатынын егермешәр яшьлек ике чибәргә алыштыра алганда!

Сөяркәсе барлыгын бу чорда кайбер ир-атлар яшерми дә. Сере ачылган очракта: «Нәрсә дип дөнья беткәндәй кыланасың?! – дияргә мөмкин ул хатынына. – Мин бит аңа өйләнергә җыенмыйм! Гаиләдән китәм димим. Аңардан көн саен «смс» килсә, ни булган, шигырь генә яза бит ул!» Уналты-унҗидедә болай сөйләшү килешәдер дә, ә менә кырыкта... Аннан хатын да бит әниең түгел... Ул, әлбәттә, ир турында: «Әллә бераз җиңеләйде, әллә тәмам оятын җуйды», – дип уйлаячак.

«Өр-яңадан башларга» теләп, яшь хатынга китеп баручыларның тормышы беренче мәлдә бал да май кебек тоелырга мөмкин. Беренче мәлдә... Карт хатының белгән кимчелекләреңне ул белергә өлгергәнче. Балалардан «аерылышырга» җыенмаганыңны аңлаганчы. Бу урында картлар йортында ишеткән бер язмыш кинәт искә төште. Сөйлим әле. Хатынын берсеннән-берсе бәләкәй биш (!) бала белән ташлап чыгып китә ул. Яңа мәхәббәте күзен дә, аңын да томалый. Әйе, үзеннән нәкъ егерме яшькә яшьрәк була. Әмма ирдән инде аерылган, ике кечкенә улы бар. Ул малайларны ир үзенекеләрдән артык күреп ярата, бар аталык хисен, җылысын аларга сала. Әллә салып бетерә алмыймы? Чөнки яшь хатыны яман чирдән кинәт үлеп киткәч, үзе тәрбияләп үстергән шушы малайлар аны картлар йортына илтеп куя. Үги әтиләренең икесенә дә йорт салырга булышканы да, машиналы иткәне дә – барысы да онытыла. Инде пенсиягә чыккан, кинәт килгән шушы югалтудан соң сәламәтлеге дә какшаган ирнең берәүгә дә кирәге калмый. Дөрес, беренче хатыны бу хәлне ишеткәч, үткәннәрне онытып, аны кабул итәргә әзер дә була. Әмма әтиле килеш әтисез үскән биш бала биш яктан каршы төшә: ана аларны тыңламый булдыра алмый.

«Урта яшьләр кризисы»н кичергәндә, дөнья тормышыннан тәмам ваз кичеп, баш-аягы белән дингә киткән ир-атлар бар. Шушы яшькә җитеп тә, уңышларга ирешә алмаганнарның канатлары бөтенләй салынырга мөмкин – андыйлар шешә белән дуслаша. Өйдә бикләнеп, компьютерга, виртуаль дөньяга чума. Кемдер үз-үзенә кул сала. Ә кемдер өйдәгеләре өчен чын «тиран»га әйләнә: хатынын, балаларын үз кубызына биетүдән тәм таба...

Бу чорда гаиләнең бөтенлеге хатын-кыз кулында, диләр. Нишләргә тиеш соң без? Бернәрсә дә эшләмәскә, диләр белгечләр. Сабыр булырга! (Анысы бездә җитәрлек!) Артык сораулар биреп аптыратмаска, киңәшләр белән ялыктырмаска. Янында булырга. Аны һаман да ятратканыңны, якын иткәнеңне, кадерен белгәнеңне сиздереп торырга. Сүзләр белән түгел, гамәлләрең белән: аның һәр уңышын зур итеп кабул итәргә, мактарга, сокланырга. Горурланганыңны яшермәскә. Көндәлек тормышка гел яңалыклар кертеп торырга: икәү бергә кинога, театрга, йә концертка барырга, бассейнга язылырга, чаңгыда йөрергә... Кырык яшьтә әле дөнья бетмәгәненә инандырырга!

Күз яшьләрен аңа ялгыш та күрсәтергә ярамый, киресенчә, өегездә бар да тәртиптә икәненә ышандырыгыз. «Үзгәрмисең икән, мин синнән китәм» ише сүзләр ялгыш та авызыгыздан чыкмасын: ул, чынлап та, аерылышу турында уйлый башларга мөмкин. Ирегез сезгә дөньяның бар гаебен якса да, үзегезне гаепле санамагыз – аның бүген үзен шулай хис итүендә сезнең гаеп юк.

«Өр-яңадан кирәк башларга», – дип, / Мин кычкырдым кыя-ташларга. / «Табигатьтә генә кайта яз», – дип / Җавап бирде миңа кайтаваз», – дип язган шагыйрь мең кат хаклы. Ирегез моңа бераздан үзе дә ышаныр.

МЕНӘ ШУЛАЙ ЯШИБЕЗ...



Бервакыт кулыма мәхәббәт хатлары килеп керде. Журналист буларак, бәлки, файдалана алырсың, дип, төргәге белән китереп тоттыргач, караштырдым да... исем китте. Хатларга түгел әле, үземә...

Минем беркайчан да, беркемгә дә наз-сөю тулы хатлар язганым булмаган икән бит. «Син киткәннән бирле үземә урын таба алмыйм, бөтен кешедә синең чалымнарны күрәм», кебек сүзләр белән берәүне дә сөендергәнем булмаган...

Ярата белмәгәнгә түгел, бу турыда әйтергә кыймаганга: әллә мәхәббәтнең җавапсыз булып чыгуыннан, әллә көндәлектәге чик-чамасыз горурлык хисенә зыян килүдән курыкканга... Һәм шулай итеп, әйтсәң-әйтмәсәң, яшәлгән дә яшәлгән. Иң кызыгы: кияүгә чыгып, дистә еллар бергә гомер иткәч тә, көндәлектәге бу «кызларча горурлык плюс матур сүзгә саранлык» әллә нәрсә кимемәгән, көне буе кухняда бөтерелеп, ир кайтуына аның иң яраткан ризыкларын өстәлгә тезсәк тә, тел очында гына торган матур сүзләр күп вакыт шул тел очында эленеп калган.

Бәлки, бу безнең хатадыр? Ә бәлки, хата да түгелдер. Ир-ат белән хатын-кыз арасындагы мөнәсәбәт шул башлангыч чорда ук ничектер үзенчә формалашып куя да, тора-бара аны инде үзгәртеп тә булмый, үзгәртсәң дә килми башлый бит. Ике арада әйтелмәгән сүзләр дә калырга, дистанция дә сакланырга тиеш дип уйлыйм мин үзем. Психологлар телендә әйтсәк – «шәхси пространство». Күп парларда шушы пространствоны җимерергә тырышу бар. «Мин синсез яши алмыйм» дигән иң гадәти мәхәббәт аңлатуларга игътибар итегез әле. Без сүзләрнең психологик эчтәлеге турында уйлап та карамыйбыз. Әмма уйлап карасаң – бу бит... шантаж. Һәм ул сөенеч кенә түгел, көнчелнең эчкәрге бер почмагында, сагаю, читләшергә тырышу да уятырга мөмкиндер. Миңа калса, ир белән хатын арасындагы мөнәсәбәтләрдә яратудан да мөһимрәк нәрсәләр бар. Ул ирек һәм хөрмәт.

Ирек, дигәннән, ирек хәтта гаиләдә дә көрәшсез генә бирелми ул. Бездә, мисал өчен, мондый көрәш мин авылга кайтырга җыенганда кузгалып ала. «Бу атнада кайтып йөрмә, – дип каршы төшә ирем, – юллар начар, авылда пычрак». Мин исә аны ярты сүздән бүлдерәм: «Ник аны әйтеп торасың инде, җаныкаем, – дим. – Син бит мине беләсең! Мин ике атнага – бер, таш яуса да, кайтам!»

Гаиләдә ирек дигән сүзне, кызганычка каршы, бер-береңә тугрылыкның мәҗбүри шарт булмавы мәгънәсендәрәк аңлыйлар. Тузга язмаган фикер! Тугрылык булмаса, гаилә буламыни ул? Миңа калса, монда сүз кешенең кайбер шәхси мәсьәләләрдә үзе теләгәнчә эшләү, үзенчә хәл итү мөмкинлеге турында барырга тиеш. Әйтик, эш мәсьәләсендә. Хатын-кызлар арасында ире шулай теләгәнгә генә хуҗабикә булып өйдә утыручылар җитәрлек. Туганнар белән элемтә тотуда. «Мин синең ул туганыңны яратмыйм, аралашма!» – кебек сүзләр ир авызыннан да, хатын авызыннан да чыгарга мөмкин. Сүз уңаеннан, туганнар мәсьәләсендә без үзебез алдан ук килешеп куйдык. «Син алар турында теләсә нәрсә уйлый аласың, – дидем мин, – ләкин бу турыда миңа әйтәсе түгел. Мин дә шулай ук». Бу очракта шуны истә тотарга кирәктер: син кешегә никадәрле ирек бирәсең, үзең дә шулкадәр үк аласың.

Минем өчен икенче мөһим нәрсә – әйткәнемчә, хөрмәт. Әлбәттә, бер-береңә, әмма беренче чиратта – үзеңә. Психологларның яратып сөйли торган сүзе бар: «Син үзеңне яратмыйсың икән, сине башкалар да яратмаячак». Мин монда һич икеләнмичә ярату сүзен хөрмәт белән алыштырыр идем. Чөнки үзен шулкадәр яраткан, әмма бер тамчы да хөрмәт итмәгән кешеләрне дә күргәнем бар.

Ә без икенче – үз мәнфәгатьләрен соңгы урынга куеп, үзләре турында югары фикердә торучылар төркеменнән. Безнең әтиебез мисал өчен гаилә хакына үзен күп нәрсәдән (әйтик, ялдан – ул елына 365 көн юлда) мәхрүм итәргә, сәламәтлек буенча борчулары булса да, хастаханәгә бару вакытын еллар буе кичектерергә мөмкин. Әмма ләкин аның эштән кайтып керү мизгелен күрсәгез икән! Ишекне гомердә үз ачкычы белән ачып кермәс. Башта домофонга басып, подъезд ишеген ачтырыр. Аннары ишек кыңгыравына басар. Ә бусагадан узгач, каршы алучы мин булсам: «Адель кая?» – дип, улыбызны, киресенчә Адель каршы алса: «Әниең кая?» – дип мине сорар.

Менә шулай яшибез. Гап-гади, тып-тыныч, бер-беребезгә күпсанлы таләпләр куймыйча, бәйләнмичә, чытырдатып тотынмыйча... Без бергә дә һәм шул ук вакытта рәттән генә дә кебек. Башкалар башкача яшидер һәм, мөгаен, алар да үзләренчә бәхетледер. Шуңа кемне кем белән очраштырасын Ходай, күрәсең, бездән яхшырак беләдер...

Ризидә ГАСЫЙМОВА

PRESSA.RU

Келәнчедә аның булышлыгы белән төзелгән мәктәпне авылдашларының «Илдар мәктәбе» дип йөрткәннәрен беләм. Бу сүзгә рәхмәт тә, хөрмәт тә, горурлык та сыйган...
Хәер, Татарстанның бик күп районнары соңгы вакытта үзләрендә «Бердәм Россия» фиркасе ярдәме белән төзелгән корылмаларны нәкъ шулай дип – «Илдарныкы» дип атый алыр иде.
Тәвәккәлдә – тау көче ди халык. Тәвәккәлләмичә, үзеңнең көчеңне сынап карамыйча, ни-нәрсәләргә сәләтле икәнеңне кайдан беләсең?! Үзалдыңа максатларның югарыларын кую да тәвәккәллек сорый. Ә ул – шундыйлардан.
Илдар Ирек улы ГЫЙЛЬМЕТДИНОВ. Россия Федерациясе Дәүләт Думасының дүртенче, бишенче, алтынчы чакырылышлары депутаты, Татар федераль милли-мәдәни мохтарияте рәисе. Россия Федерациясенең яшьләр сәясәте буенча атказанган хезмәткәре, Татарстанның атказанган физик культура хезмәткәре.





Гөлнур САФИУЛЛИНА

ТӘВӘККӘЛДӘ – ТАУ КӨЧЕ



ТАМЫРЛАР Кама Тамагы районы Келәнче авылында, укытучылар гаиләсендә үстем мин. Әни – татар теле һәм әдәбиятын, әти тарих фәнен укытты, мәктәп директоры булып та эшләде. Укытучылар күп безнең нәселдә: әтинең апасы, җизни, әнинең абыйсы, әтисе... Әни – Актаныш районының Түбән Гәрәй авылыннан. Алар әти белән Алабуга педагогика институтында укыганда танышалар. Татарстанның икенче ягына килен булып төшә ул. Тик туган авылын сагынып утырырга вакыты булдымы икән безнең әнинең? Биш бала, кайнана, хуҗалык... Мәктәптә дәресләр тәмамлангач та, тиз генә өйгә кайту юк иде аларга: әле чөгендер басуында, әле бәрәңгедә. Көн саен ниндидер чара... Ярый әле өйдә, безнең янда Фәхриҗамал дәү әниебез булды.

Әни бик матур җырлый – авылда узган бөтен концертта аның җырлавын сорыйлар иде. Кирәк булса, гармунда да уйный иде. Түбән Гәрәйдәге бабай да җырларга ярата иде безнең. Әйткәнемчә, ул да укытучы иде, мәктәп директоры да булып эшләгән. Әни «инәкәй, ипекәй, нәмәкәй» дип сөйләшә. Чиләкне «бидрә» ди. Актанышка кайтуга бөтенләй аларча сөйләшүгә күчә иде ул. «Ничек шулай ике төрле сөйләшеп була икән?» – дип, кечкенә чакта моңа бик аптырый идем.



БАЛАЧАК Балачакның иң зур хатирәсе – пароход белән Актанышка бару. Ул вакытта пароходлар бик иске иде, озак баралар – юлда ике-өч көн вакытыбыз уза. Пароход берничә класска бүленә, безнең урыннар, әлбәттә, иң түбәндәге класста була торган иде. Өскә менеп, бөтен җирне карап йөрибез. Халык күп: биюләр, җырлыйлар – пароход гөр килеп тора. Зур-зур пристаньнарга туктыйбыз. Кызык! Ямал авылы пристанендә төшеп калгач та, Түбән Гәрәйгә кадәр тагын 7-8 чакрым атлыйсы әле...

Гаиләдә олы бала булгач, су юлы белән Актанышка барулар миңа, башкаларга караганда, күбрәк эләкте. Малик бабай белән Гөлсайра әбине дә яхшы белеп калдым. Елга бер тапкыр, әнинең җәйге ялында барабыз, кайчак икешәр атна торып кайтабыз. Өй артында гына Шәбез елгасы ага – дуслар белән балыкка йөрим. Актаныштa безнең якта булмаган көнбагыш үсә. Бакчаларында үстереп саталар да иде. Бер елны безгә дә китереп куйдылар әле. Дәү әни ул көнбагышны сатып та ятты.



МӘКТӘП Укытучыларыма мәшәкать тудырмаганмындыр, тыныч бала идем, әмма гел «бишле»гә генә укыдым дия алмыйм. Әти белән әни ни өчендер мине Суворов училищесына бирергә теләде. Без хәтта Казанга барып та кайттык. Ләкин бездә чит тел өйрәтелмәгәнлектән, училищега эләгә алмадым. Үзебездә сигезьеллык мәктәпне тәмамлаганнан соң, ун чакрымдагы Олы Карилегә, урта мәктәпкә киттек. Интернатта торып укыдык. Зур мәктәп иде анда, унынчы класслар гына да дүртәү иде. Ә нинди көчле укытучылар коллективы иде! Таләпләр шундый югары иде безгә. Аттестатка ике «дүртле»м чыкты. Аның берсе физкультурадан иде (физкультура укытучысы Тәлгать абый безнең беребезгә дә «бишле» куймады). Икенчесе – геометриядән. Фәния апа да кемгә генә куйды икән ул «бишле»не, белмим?!

Үз фәннәрен яраттыра белә торган укытучылар белем бирде безгә. Әллә ничә сыйныфташым киләчәкләрен химия белән бәйләде – химия укытучыбыз Азат абый уңышы! Физиканы Бәһрам абый укытмаса, мин дә физика-математика факультетына барып кермәс идем, мөгаен. Үземне күбрәк гуманитар фәннәр кызыксындыра дип саный идем.



УҢЫШ Республикага укытучылар җитми иде – бишьеллык программаны без дүрт елда укыдык. Татар мәктәбеннән соң русча математика терминнарына күчү читенрәк булды анысы. Әмма Казан дәүләт педагогика институтын кызыл дипломга тәмамладым. I курста ук группаның старостасы итеп куйдылар. (Курсташлар өчен хәзер дә староста мин!) Спортка тартылдым – чаңгыга бастым. Буш вакыт булмады да шикелле. III курстан соң консерватория каршындагы музыка мәктәбенә физика укытырга чакырдылар. Директорлары сорагач, декан рөхсәт бирде. Бик талантлы балалар белем ала иде анда, әмма аларга физика кирәкми! Укучыларым үзем белән бер яшьтә: «Физикасыз лампочка да бора алмассыз!» – диюемә елмаялар гына... «Менә сез дә музыканы безнең кебек аңламыйсыз бит!» – дип әйтер өчен, «Бүген Шостаковичның фәлән симфониясе», – дип, кайчак мине консерваториягә концертка чакыралар. Дәресләрне кызыграк итәр өчен күпме лаборатор эшләр үткәрдем. Диплом алганчы, шактый тәҗрибә тупларга өлгердем.

Эшкә үзебезнең районга кайттым. Мине шунда ук Олы Бортас мәктәбенә директор итеп куйдылар. Егерме яшьтә! Мәктәп әле төзелеп тә бетмәгән иде.

Җәй буе колхоз рәисе кабинетыннан чыкмадым. Иртәнге биштә үк барып утырам – соңарсаң, машина калмый. Ә безнең мәктәп түбәсен ябасы бар, ишек-тәрәзәләр куясы, җиһазлар алып кайтасы. Әле кадак юк, әле пыяла... Ике көннең берендә Казанга чыгып китәм... 1 сентябрьгә мәктәпне өлгерттек! Иң мөһиме – мин Олы Бортаска тагын дүрт ир-ат укытучы алып бардым! Бер группадашым авылга кайтырга ризалашкач, үзем хәтта физика дәресләреннән баш тартып, тарих сәгатьләрен алдым.

Аннан, белгәнегезчә, комсомол эшенә кереп чумдым...

Дәүләт Думасына депутат итеп сайланганда, Татарстан спорт һәм яшьләр министрының беренче урынбасары идем. Миңа ул чакта Минтимер Шәрип улы Шәймиевнең мандаты күчте – Дәүләт Думасына аның урынына эшкә киттем. Сигез ел Думада яшьләр һәм спорт комитеты рәисе урынбасары булып эшләдем. Казанда Универсиада уздыру уе Татарстанның ул чактагы Яшьләр эшләре, спорт һәм туризм министры Марат Мансур улы Бариев белән минем уртак хыял иде. «Казан – студентлар шәһәре, нигә ул бездә үтмәскә тиеш?!» – дип башлаган идек без аны. Ә ул әнә нинди зур чарага әверелде! Универсиаданы үткәрүне җиңеләйтерлек шактый законнар кабул итүгә ирештек без ул чакта. Мәскәү ягыннан берниндитоткарлык булмады.

«Бердәм Россия» партиясенең спорт корылмалары төзү буенча махсус проекты бар. Соңгы ике елда мин – шуның җитәкчесе. Россия буйлап төзелгән 630 объектның утызын Татарстанга алып кайттык. Федераль бюджеттан миллиард ярым сумлык ярдәм бу республикага! Кама Тамагында – бассейн, Арчада,

PRESSA.RU

Кукмарада – Боз сарае, Балтачта – комплекс... Бу эш хәзер дә дәвам итә. Апанай мәчетен яңартуга федераль бюджеттан 20 миллионнан артык акча алуга ирештек. Әҗем мәчетенә 52 миллионлык ремонт ясалырга тиеш. «Бердәм Россия» партиясенең авыл спортзалларын, мәктәпләрне ремонтлау буенча программасы бар (анда 40 регион гына катнаша). Узган ел шуның буенча республикада 35 мәктәп ремонтланды. Артка борылып карасаң, сөенергә, горурланырга сәбәпләр шактый.

Хәзерге мин – Думаның мәгариф комитетында. Туган телне өйрәнү буенча үз позицияләребезне сакларга тырышабыз. Туган телне өйрәнүне тыйган канун юк. Күп нәрсә үзебездән дә тора, чөнки мәктәп укыту программасын үзе төзи, үзе кабул итә.

Мин әле бүген дә Татарстанның яшьләр советы рәисе. Татар яшьләре, татар балалары белән шактый күп эшләр башкарабыз. «Идел» яшьләр үзәген оештыруда кайчандыр башлап йөргән идем. Елына 7-8 зур чара уза анда: татар, мөселман, төрки яшьләр көннәре, телләр лагере... Читтә гомер итүче яшьләребезгә татар рухы сеңдереп җибәрергә тырышабыз.

Татар федераль милли-мәдәни мохтарияте рәисенең күп гомере, әлбәттә, юлда уза. Төбәкләрдә яшәүче милләттәшләребез белән еш очрашам: кайда нинди проблемалар, нинди ярдәм кирәк, урыннардагы җитәкчеләр белән ничек элемтәләр урнаштырырга... Күп мәсьәләне күзгә-күз карап сөйләшүләр хәл итә.



ДУСЛАР Бар андый дуслар! Җиде төн уртасында шалтыратырга мөмкин булган, кирәк икән, ярдәм дә, киңәш тә сорый ала торган... Бер генә дә түгел! Күбесе белән студент чакта дуслашкан идек. Саша Абакумов бар менә. Ул Алексеевскийда яши. Башта мәктәптә укытты, хәзер район үзәгендә эшли. Аның белән гел аралашып торабыз. Тагын – Вильсор Камильянов. Ул Чаллыда иде, аннары Казанга күченде. Шәһит дигән гомерлек дустым бар. Армиягә районнан бергә чыгып киттек без аның белән, бергә кайттык, бер частьта хезмәт иттек. Тормышта төрле хәлләр була, дуслар гел кирәк.



МӘХӘББӘТ Мин мәктәптә ел ярым гына эшләп калдым – комсомолның икенче секретаре итеп куйдылар. «Комсомолга – партия җитәкчелеге» дигән лозунг тормышка үтеп кергән чак: районның комсомол оешмасын көчәйтергә кирәк, диделәр. (Мин бу вакыт коммунист идем инде.) Комсомол секретаре ул, беренче чиратта, идеолог иде бит. Тик үзең армиядә булмагач, ничек яшьләр арасында хәрби-патроитик тәрбия белән шөгыльләнәсең?! «Мине армиягә җибәрегез», – дип үзем сорап бардым. Берничә тапкыр кире борсалар да, аннан алдылар. Германиядә хезмәт итеп кайттым. Кайтуга өлкә комсомол комитетына инструктор итеп чакырдылар. Отчет-сайлау җыелышларын үткәрергә районнарга җибәрәләр иде безне. Актанышка баргач, беренче секретарь урынын тәкъдим иттеләр. Әниемнең туган ягы бит, ерак булса да, бу район миңа берничек тә ят түгел иде. Кайттым. Мәхәббәтемне шунда очратасымны, әлбәттә, белми идем әле... «Сельхозтехника»ның кунак йортыннан бер бүлмә бирделәр – шунда торам. Күршедә генә оешманың баш инженеры яши. Аның озын толымлы чибәр кызына күз шунда ук төште инде... Алабуга педагогика институтын тәмамлап кайтуы, укытучы булып эшләве турында да белергә өлгердем. Таныштык... Өч елдан миңа яңадан Казанга әйләнеп кайтырга туры килде – өлкә комсомол секретаре итеп сайландым. Казанда, беренче эш итеп, телефоннан шалтыратып Гүзәлнең ризалыгын алдым. Аңардан башка яшәүнең яшәү түгел икәнен Актаныштан киткәнче үк аңлаган идем инде. «Кызыгызга өйләнергә телим, хәер-фатиха бирегез», – дигән сүзне дә булачак әби белән бабайга телефоннан әйтергә туры килде. Ике якта да туй уздырдык. Гүзәл, яшь килен булып, «Яшьләр үзәге»ндәге кунакханәгә килде. Фатир алганчы, ике-өч ел шундагы кечкенә генә бер бүлмәдә яшәдек әле без. Улым да беренче адымнарын шунда атлады.



КУРКУ Якыннарым – туганнар, әти-әни, балам белән бер-бер нәрсә булса дигән уй куркыта. Сихәте табылмаган чирләр бар... Бернәрсә белән дә, берничек тә ярдәм итә алмасаң, нишләргә? Яки үзем авырып китеп, аларга борчу китерсәм дип тә куркам. Берберебезнең сәламәтлеге өчен беркайчан да кайгырырга туры килмәсен иде! Ә калган кыенлыкларны җиңәрбез.



АКЧА Кинәт каяндыр көтелмәгән зур акчалар өскә ишелеп төшсәме? Акчага һәрвакыт урын күп анысы... Мәскәүдә гаилә белән яшибез – моның кадәр кыйммәт шәһәрне күргән юк әле: акчаны эшли торасың, шунда ук туздыра да торасың. Әлбәттә, әти-әнигә, туганнарга ярдәм итәргә тырышам. Хезмәт хакымның җыелып барганын бик сизмим, тарала да бетә. Депутат буларак, ярдәм сорап килүчеләр дә күп. Мөмкинлекләр табарга тырышасың. Әмма гел сорап кына йөрүчеләр дә бар...




БАЛАЛАР Бер ул үстердек. Күчеп йөреп, бер бала белән генә калынды шул... Марат Мәскәү Физкультура институтын тәмамлады. Татарча, әлбәттә, белә, сөйләшә. Әле өйләнмәгән. Башлы-күзле булырга вакыт инде, көтәбез...



ҮЗЕМ ТУРЫНДА Гап-гади авыл егете мин... Үзеңне мактау да кыен, хурлау да... Дәшми калыйм әле...

ОСТАЗЫБЫЗ



Бу көннәрдә Флорид абыйга 80 яшь тулган булыр иде... Безнең өчен ул һаман яшь, һаман студентлар арасындадыр кебек. Флорид Имамәхмәт улы Әгъзамовны — журналистика факультеты деканын без Флорид абый дип йөртә идек. Якын итү, ярату, тирән хөрмәтебез ярылып ята иде шул «абый» сүзендә. Казан федераль университетының Н. И. Лобачевский исемендәге фәнни китапханәсендәге конференц-залда Флорид Әгъзамовның тууына 80 ел тулуга багышланган халыкара фәнни-гамәли конференция узды.
Конференция алдыннан Флорид абыйга багышланган видеофильмны кат-кат әйләндерделәр. Аның шәкертләре сөйли. «Российская газета»ның баш редакторы Владислав Фронин, Татарстан Дәүләт Советы Рәисе урынбасары, Татарстан Журналистлар берлеге рәисе Римма Ратникова... Кайчандыр Флорид Әгъзамов лекцияләрен тыңлаган, аның белән якыннан аралашкан газета-журнал мөхәррирләре...

Сәламләү сүзе белән чыккан Казан федераль университеты проректоры Денис Нургалиев, әнә, Флорид абыйны якташым иде дип сөйли. (Флорид абый Башкортстанның Чакмагыш районы Бикмәт авылында туган. – *Э. З.*) Ул ярдәмчел, ипле-җайлы якташының татар журналистикасына нигез салуы турында кабат искәртә. Республикабызда журналистлар әзерли торган институтның директоры Щелкунов Михаил Дмитриевич үз чыгышында гуманлылыкның Россия җәмгыяте үсешендә мөһим фактор уйнавына тукталып, тагын Флорид Әхмәтович турында сөйли башлый... Елена Дорощук, Сөмбел Таишева, Роман Баканов... Һәркайсы олы остазның журналистика теориясе өлкәсендәге фәнни-тикшеренү эшләренә югары бәя бирә. «Игътибар үзәгендә – Кеше!» Флорид Әгъзамовның бер китабы әнә шундый исемдә. Миңа калса, бу сүзләр аның тормыш шигаре дә булып киткән. Без, журналистлар, язмаларыбызда, мәкаләләребездә Кешене үзәккә куеп, Кешеләрне яратып язабыз икән, димәк, ул безгә Флорид абыйдан бирелгән!

Флорид абыйны студентларының «әтисе» дип йөрттеләр. Хәзер ул исем Флорид абыйның шәкерте, татар журналистикасы кафедрасы мөдире Васил Гарифуллинга күчте. Ул да студентлары өчен җан атып, аларны кайгыртып тора, үстерә, юл күрсәтә... Кешелеклелек, хәлгә керә белү, дустанә җылы мөнәсәбәт кебек сыйфатлар аңа һичшиксез Флорид абыйдан йоккандыр.

Мин конференциядә Флорид абыйга бәйле хатирәләремне яңартып утырдым. Төрле детальләр, кызыклы истәлекләр күз алдыннан узды.

Мин журналистика бүлегенә дип җыенып килеп тә, «Яшь ленинчы»дагылар киңәшен тотып, татар теле һәм әдәбияты бүлегенә укырга кердем. Күп дуслар, танышлар журналистикада укый. КПСС тарихы, философияише фәннәрдән лекцияләрне «журналистлар» белән бергә бер аудиториядә тыңлыйбыз. Тулай торакта бер бүлмәләрдә яшибез. Алар, «безнең Флорид абый мондый, ул шундый!..» – дия-дия, кафедра җитәкчесе Әгъзамовны мактыйлар. Флорид абый стипендияләрен дә кайгырта, тулай торакта бүлмә алуда да ярдәм итә, хәтта редакцияләргә эшкә урнашырга да булыша икән. Шундый җайлы абыйны үзебезнең химкорпуста да әллә ничә күргәнем бар. Студентлары белән бик тә үз итеп аралаша, тамчы да тәкәбберлек юк үзендә. Мин берара журналистика бүлегенә күчәргә дә хыялланана башладым. Анда нәкъ менә шул шәп кафедра мөдире Флорид абый, аңлый белә торган укытучы булганга иде...

Язмыш барыбер Флорид абый белән бер сукмаклардан йөртте безне. Яшь журналистларның «Алтын каләм» республика фестивален әле башлап кына җибәргән чакларда журналистика факультеты деканы Флорид абый да, мин дә жюри әгъзалары идек. Аннары безнең гаилә дусты да иде әле ул. (ирем Илдар журналистиканы тәмамлаган, Флорид Әгъзамовның шәкерте. – *Э. З.*) Җитмәсә, без Чистай урамында бер йортта, күрше подъездларда яшибез... Флорид абый берничә тапкыр безнең өйдә кунакта да булды. Мәскәүдән танылган журналист, Флорид абыйның беренче студентларыннан берсе, Татарстанның Вәкаләтле вәкиллегендә матбугат үзәге җитәкчесе булып эшләүче Рафис абый Измайлов Казанга кайткан иде. Егетләр, әлбәттә инде, Флорид абыйны да чакырдылар. Мин үземнең фирменный чүлмәкләремне пешергән идем. Флорид абый мактап та куйды инде үземне! «Бәлеш кебек тәмле булган», – ди. «Минем бәлеш кунаклар өчен никтер бик үк оста килеп чыкмый», – дип акланган булам. Шунда Флорид абый: «Ял көне безгә бәлеш ашарга керегез әле, Рая апаң атна саен пешерә, сине дә өйрәтер», – дигән иде.

Ә берсендә безнең өйдә чакта радиодан татарча концерт бара иде. «Әйтмә син авыр сүз»не җырлыйлар. Флорид абый җырга кушылды. «Нинди тирән мәгънәле җыр!» – ди. Шунда аның матур җырлавын да ишеттем.

Тагын бер кадр күңелгә уелып калган: Васил Гарифуллин баянда уйный, Флорид абый җырлый. Фотолар, фотолар.... Һәркайсыннан якты, ягымлы, кешелекле, гади Флорид абый елмая. Сагыналар аны. Сагынабыз...

Эльмира ЗАКИРОВА

PRESSA.RU

Илсөяр Иксанова... Аның шигырьләре шигъриятебезнең йөзек кашы сыман – бик затлы, нәфис, кабатланмас! Һәркайсы тирән фәлсәфә, җылылык, наз белән мөлдерәмә. Зәңгәр күзләреннән моң бөркеп: «Умырзая булсаң икән кабат! Йөрәк инде милəш булып яна...» – дип, рәссамның зәңгәр, кызыл буяуларына үз төсләрен куша. «Мин әлегә ап-ак күбәләк» – дип, ап-ак сөенечкә күмә. Аның ихласлыгыннан рәхәт һәм җиңел булып кала. Зәңгәр әңгер, сары моң, күкләрендә алтын ай йөрер... Кырык кыллы күңел, кырык кыллы язмыш... Болары да – Илсөярдә. Укыган саен укыйсы, тыңлаган саен тыңлыйсы килеп торган шигырьләр. Безнең җаннарга тансык, кадерле алар! Гомер бәйрәмең белән котлыйбыз! Яңа шигырьләреңне көтәбез!


Илсөяр ИКСАНОВА

БЕЗНЕҢ ГОМЕРЛӘРГӘ АЛКЫШЛАР...

Мин – хатын-кыз

Каурый болыт булып күккә аштым,
Тамчы булып тамдым гөлләргә, –
Йә, кемнәрнең җаны кипкән иде,
Җылы яңгыр кирәк кемнәргә?

Язгы үлән булып күтәрелдем,
Яфрак булып шыттым бөредән, –
Йә, кемнәрнең ачылмаган язын
Ак кыраулар сугып өлгергән?

Ал таң булып кундым офыкларга
Һәм көн булып төштем өзелеп.
Шагыйрь, диеп сокландылар бар да, –
Мин хатын-кыз идем иң элек!

Җәй белән хушлашу

1
Җәй уртасы.
Чикерткәләр җырлый.
Авыл тулган печән исенә.
Мин таң калып җәйне тоеп йөрим, –
Сүзләр таба алмый хисемә.

Шундый рәхәт,
Шундый моңсу миңа...
Бу хисләрне ничек кушасы!
Офыкларда болыт кабарына.
Килсен әйдә,
Яусын,
Бушансын!

Минем күңелем дә шул халәттә:
Кабарына хисләр,
Тулыша.
Җанны өтеп алыр җәй уртасы.
Кайнар тыны каба сулышка!

2
Җәй уртасы.
Пркупида йөрим.
Билдән печән. Беркем чапмаган.
Аксыл рәшә төсле ромашкалар
Кайтавазмы балачаклардан?!.

Безнең пай җире бу.
Тырма белән
Печән җыеп йөргән урыннар.
Пакус-пакус кипкән печәннәрне
Мин әле дә күрәм уемда.

Әти тапкан зәңгәр утраулар –
Мәтрүшкәләр кайда?
Югалган?..
Үләннәрне ярып эзләп барам
Балачагым үткән юллардан.

Рәхмәт, җәем!
Сабый чакларымның
Саклагансың икән эзләрен.
Кул яссуы җирдә – мәтрүшкәләр...
Иелеп иснәдем дә...
Өзмәдем.

Әни белән икәү килгән идек
Бик сагынган җәйдә әтине.
Инде әни дә юк...
Мәтрүшкәләр,
Юатыгыз мине... ятимне.

«Мәтрүшкәңне таптың мәллә,
әни?» –
Кызым килә үлән аралап.
И дөнья!
Үзең яралыйсың...
Һәм бирәсең дәва ярага.

3
Кызым белән Пркупида йөрдек,
Мүкле күлгә төшеп су кердек.
Балачакка, яшьлек елларыма
Бу сәяхәт иде... бер көнлек.

Урап кайттык Карташ болыннарын,
Үбәтелнең яшел аланын.
Җәйләремнең сутлы җиләкләрен
Учларына салдым баламның.

Сайлап кына өздем җиләкләрнең
Өлгергәнен– алын, кызылын.
Җиләкләрнең тулып пешкән чагы,
Җиләк кебек чагы кызымның.

Бер җиләккә, бер кызыма карыйм:
Күз тимәсен,
Сүз дә тимәсен!
Өзелмичә калган җиләк кебек
Моңсуланып башын имәсен!

Күңеленә күчсен минем илем –
Мүкле күлем, урман, болыннар...
Күбәләкле җәйдә
Миннән соң да
Чакрып торсын аны бу юллар!

...Хатирәләр тулы җәйдә йөрим
Кызым белән.
Хисләр ташыган...
Хисләремә төреп мин кызыма
Яшел җәйләремне тапшырам!

Әбиләр чуагы

I
Җирдә әбиләр чуагы –
Очалар пәрәвезләр.
Имәннәрнең яфраклары –
Утлы карашлы күзләр.

Толымнар алтын чулпылы
Талларда, юкәләрдә.
Миләшләрнең хисе яна –
Гашыйклар микән әллә?

Каеннар моңлы җыр суза
Мәхәббәт исеменнән.
Ак толымлы иртәләрдә
Җәй кызы яшеренгән...

II
Һаваларда җилбер яфрак исе,
Һаваларда дымлы җир исе.
Соңлап килгән бу җылыга сөенеп
Озак-озак килә яшисе.

Үрмәкүчләр пәрәвездән үрә
Ефәк шәлләрнең бизәген.
Миләшләр ут дөрли,
әбиләрнең
Җылытырга теләп соң җәен.

Кояш нурын эчә күбәләкләр –
Әйтерсең лә алда – мең гомер.
Бу яктылык җирдә мәңгелектер,
Бу җылылык җирдә мәңгедер!

Кошлар белә ләкин:
әбиләрнең
Җәе кыска, озын кышлары.
Җылы җәйне эзләп китеп бара
Төркем-төркем урман кошлары.

Безнең җәйләр инде артта калды
Бөресенә посып талларның.
Чит якларның җылы җәйләре дә
Җылыта алмас сезне җаннарым.

Мин бу кадәр асыл көзне ташлап
Китә алмас идем, кош булсам.
Әбиләрнең җәе озын булсын! –
Килми торыр идем, кыш булсам!..

Авылдан китү

Каерылып карыйм артка:
Бик эленгән зәңгәр капка,
Буп-буш калган капка төбе.
...Кем озатсын мин ятимне.

Каерылып карыйм артка...
Хәтеремдә – зәңгәр капка,
Әни тора өй каршында, –
Сагышлы моң карашында...

Каерылып карыйм артка...
Туган нигез.
Зәңгәр капка.
Әти-әни озатып кала.
...Балаларны кала ала.

Каерылып карыйм артка:
Өй дә шул ук.
Шул ук капка.
Тик озатмый беркем,
Беркем.
...Килә икән шулай бер көн.

Безнең гомерләргә алкышлар

Дустым Гөлсинәгә

Урамда көз яна.
Көзләр яна.
Яфрак булып еллар өзелә.
Гомер агачыңнан илле яфрак
Өз(е)леп төште үткән эзеңә.

Яфракларның кайсын җилләр ала,
Яфракларның кайсын җир ала.
Җиргә сеңгәненнән гөлләр шыта,
Җилләр алганыннан җыр кала.

Гомер агачыңда күпме яфрак? –
Төгәл белә анысын Күк кенә.
Күккә баккан күң(е)лем тоя бары:
Шаулар яфракларың күп кенә.

Шаулап яшә,
Яшьнәп яшә җирдә! –
Дөнья фани,
Хисләр– үлемсез!
Яфрак булып еллар өзелгәндә,
Юк, булмасын безгә күңелсез!

Ялкынланып яна әнә көзләр, –
Бу көзләрдә күпме балкыш бар!
Яфрак шавы,
Яфрак кыштырдавы –
Безнең гомерләргә алкышлар!

Буран

Ялгыз җанны юатырга теләп,
Тәрәзәмә бизәк төшергән
Бу кышларым синнән
мең кат җылы –
Бураннарында да өшемәм.

Аһ, синең дә туңган күңеленне
Җылыта алса икән бу буран!
Дөньяларын агартырдай булып
Ак буранда басып мин торам.

Күкләр белән җирләр тоташкан чак,
Күкләр белән җирләр тоташ ак.
Син бүген дә мине ишетмәсәң,
Сөюемне буран йотачак.

Ялгыз калгач, син дә өшенерсең,
Күңелләрең мине төшенер.
Миннән мең кат җылы
тоелыр буран,
Тәрәзәңә бизәк төшерер...

Гомер сурәте

Киңәйгән саен офыклар,
Юллар тарая-тарая.

Әверелеп бер ноктага
Офык читендә туктала.

Пркупи– туган авылым Сараландагы коры елгалы болынлык. Прокофьев атлы алпавытның җирләре булырга тиеш.
Үбәтел– авылдан ерак булмаган урманлык.
Карташ– болынлык.

PRESSA.RU



Айгөл
ӘХМӘТГАЛИЕВА

КАР... КАЙНАР ИКӘН

(Хикәя)

Нәрсә дигән булалар бит, ә, сүзләреннән гарьләнеп үләрсең, билләһи. «Картаеп киткәнсең», имеш. «Сыер», имеш... Йә инде, ир-ат була торып, йөзгә бәреп шулай димәсәләр, башка сүз табылмас идеме? Бүгенге кичне бер генә минутка да исеннән чыгара алмаган Фәнзилә кулындагы китабын диван почмагына томырды. Күзләре китап битендә булса да, уйлары әллә кайда адашып йөри бит – кара инде, кайчаннан бирле үзалдына оеп, ирәвенләп утыра... Түзмәде, сап-сары башмакларын аягына элеп, җәлт кенә сикереп торды да почмактагы кием шкафының ишеген ачты, аннан, бөтен буена күрсәтә торган көзгедә үз чагылышына карап торгач, кинәт көлеп җибәрде. Һай, авызың кыек булса, көзгегә үпкәләмә, дип, хак та әйтәләр шул. Өстендәге соры спорт костюмы, иңсәсенә салган калын мамык шәле, баш түбәсенә ничек эләкте шулай җыеп куелган чәч толымы, ярты битен томалаган калын кысалы, калын пыялалы күзлеге Фәнзиләгә ким дигәндә тагын ун-унбиш ел өстәгән шикелле.

Әлегә кадәр салмак кына аккан тормышы бүгенге очрашудан соң кырт үзгәрергә охшаган... Яңа ачылган балалар бакчасына Фәнзилә әле көз ахырында гына урнашкан иде. Тәмле телле, ачык йөзле булып, балаларны бик яратып эшләгәч, элекке урынында да, монысында да берсе дә «картайгансың» дип чырай сытмады әле, «Фәнзилә Гариповна» дип өзелеп торалар. Каян килеп чыкты бу Фаил... Үч иткәндәй, малае шушы бакчага йөри икән, шуны алырга килгән җиреннән Фәнзиләгә тап булды да инде.

– Ха-а-а, Фәнзилә, әллә син инде?

Ике смена эшләп, җеп өзәр хәле калмаган кыяфәттә баскычтан төшеп килгән Фәнзилә, таныш тавышны ишеткәч, егылып китә язды. Ишек төбендә, кулына уенчык көрәк тотып, кайчандыр бер парта артында утырган сабакташы Фаил басып тора иде. Күрешмәгәннәренә ун гына ел бардыр, үзгәрепме-үзгәргән егет! Калын җилкәле, үгез муенлы ир затына әверелгән! Бер кулын затлы күн курткасы кесәсенә тыгып, аякларын аерып басып торуын күр. Келәм уртасына чыккан көрәшчемени.

– Фаил, син дисәм... – Фәнзилә, каршысында нәкъ менә Фаил басып торуын бик яхшы белсә дә, күзлек астыннан күзләрен кысып, аның йөзенә текәлеп карады.

– Кит инде, Фәнзилә, мәктәптә «бишле»гә генә укып, әллә шушында ыбыр-чыбыр арасында эшләп йөрисеңме? Копейкалар санап... – Фаилнең тук, таза йөзеннән мыскыллы елмаю йөгереп үтте. – «Икеле» капчыгы булуымнан көлә торган идегез, аның каруы, бүген мин дөньяның артына тибеп яшим. Үз эшем, үз ашым, ха-ха-ха... Син че-то картаеп киткәнсең әле, ябыгып та калгансың. Элек кызлар арасында чибәр генә кебек күренә идең...

Фәнзилә, аның боргаланмый-сыргаланмый шулай диюеннән гарьләнүен яшерергә тырышып, ясалма елмайды:

– Арытты бүген, иртәдән бирле аяк өстендә... Син ничек, тормышларың?

– Зарланырлык түгел. Әнә, бу айда гына машинаны алыштырдым, хатынга да яңаны алып бирдем. Фатирны зурайттык, шәһәр читендә ике катлы йорт салып ятам. Акчага интеккән юк, чит илләргә йөреп торабыз.

Ул арада баскыч төбендә еламсыраулы тавыш яңгырады:

– Па-па! Па-па!

– Давай, тизрәк, сынуля!

Дүрт-биш яшьләрдәге таза малай, туп кебек түгәрәк гәүдәсен авыр кыймылдатып, тәбәнәк эскәмиягә лапылдап утырды. Көчкә иелеп, ботинкасының сулын уңга, уңын сулга киеп маташкан җиреннән:

– Па-па! Я кушать хочу! – дип авыз турсайтты.

– Малаең белән татарча сөйләшмисеңме әллә? – диде Фәнзилә, ана телендә сөйләшә белмәгән татар балаларын татарчага өйрәтү мәшәкатьләрен башыннан кичереп.

– Аңлавын аңлый ул, – дип, эре тешләрен күрсәтеп елмайды Фаил, аннан улының ботинкаларын дөресләп куйды. – Да ведь, улым? Ты же все понимаешь, шулаймы?.. Сөйләшә генә белми. Эт шикелле.

«Эт шикелле». Әти кеше үз баласы турында авыз ерып шулай дип торсын инде...

Кыз туры сукмактан – аллы-гөлле төсләрдә балкып утырган бакча уртасыннан гына кайтырга юнәлде. Иртәгә искечә Яңа ел бәйрәмен үткәреп җибәрсәләр, шәмәхә утларга төренгән чыршыны да, боздан ясалган менә бу сыннарны да, лабиринтларны да сүтеп ташларлар инде, бакча тагын ялангач агачлары, кар сарган эскәмияләре, хот-дог, кайнар кофе, пицца сатучы ларекләры белән утырып калыр. Ә бүген матур монда! Чатнама салкын дип тормыйлар, яшь-җилкенчәк бакча тутырып күңел ача: берәүләр чырык-чырык килеп, сабыйлар күк, боз тавыннан шуып рәхәтләнә; икенчеләр, кулларына телефон тотып, әле чыршы янында, әле маймыл сыны янында сурәткә төшеп мәш килә. Фаилнең баягы сүзләреннән тәмам кәефе кырылган Фәнзилә, уңга-сулга каранып атлаган мәлендә, таеп егылуын абайламый да калды. Кыз, җәйрәп яткан җиреннән, иң беренче эш итеп, янына тәгәрәгән күзлеген барлады: ул ватылса, эш харап.

– Сыер кебек ятма инде, апа, тор әйдә. – Каршысына иелеп кул сузган егетнең шул сүзеннән Фәнзилә кычкырып елап җибәрердәй булды. Бер көнгә күбрәккә китмәдеме? Берсе «картайгансың» дип, икенчесе «сыер» дип мыскыл итә. «Апа» ди, җитмәсә; үзен белми – аның да унсигез яшьлек түгеллеге күзләренә чыккан. Абау ла, шундый да зур, кап-кара күзләр була микәнни? Керфекләре дә, кызларныкы шикелле өскә кайтарылып, дугаланып тормаса...

– Оп-па... Күзеңә йолдыз төшкән бит... – Егет аның йөзенә карап, сәер генә шулай диде дә Фәнзиләнең йон бияләй кигән кулына үрелде. Кыз шул мәлдә генә айнып китте, ярдәмгә сузылган кулны ачу белән читкә этәрде дә, аягына торып басты.

– Сыер, сыер... Ә син... ә син – дөя! – диде ул, егетнең аркасына асылган спорт рюкзагына күз төшерүгә. Теленә усал сүзләр килүгә үзенчә сөенеп, итәгендәге карны кага-кага, ашыгып китеп барды.

– Рәхмәтеңә рәхмәт, апасы! – Егетнең, шаркылдап, шулай дип көлеп калуы колак яфрагын яндырды, күзләренә кинәт кенә кайнар яшь тамчысы килеп бөялде. Апа, имеш... беләсең килсә, егерме сигез яшь кенә әле Фәнзиләгә, утыз да тулмаган! Мондый салкында өстенә нәзек билле кыска пәлтәсен кия алмый бит инде, унҗиде яшьлек кызлар гына ул, ыспай туңмас – калтырар дигәндәй, әтәч тиресеннән тегелгән куртка, капрон оек киеп, чәч туздырып, яланбаш йөри ала. Йөрәкләренең дә кайнар чагы. Ә менә Фәнзиләнең йөрәген яндырыр кешесе дә, көтәр, өметләнер мәхәббәте дә, исеменнән үк учак ялкыны бөркелеп торган яшьлеге дә юк. Әллә ничек кенә узып бара гомере, үзенә тиешлесе яшәешеннән чаптар атларда гына елдырып үтеп киткәнме, күрми-сизми калганмы... Шушы бертөсле тормышы инде беркайчан да үзгәрмәс, мөгаен, чөнки өмет кояшын әллә кайчан ук сүндереп куйды. Бу яшьтә аңа дигән юньле-рәтле егет калган дисеңме әллә? Юньле дигәнен әллә кайчан чүпләп бетергәннәр инде... Менә шуңа күрә дә Фәнзилә кысыр хыяллар белән үзен ымсындырып яшәми хәзер, менә шуңа күрә дә аның өстендә киң итәкле, калын башлыклы озын кара пәлтә. Булсын, тегелеше бераз гына олыгайтып күрсәтсен, аның каруы, җылы! Аягында да төз гәүдәсен тагын да зифаландырып күрсәтүче без үкчәле, тар кунычлы ыспай итек түгел – «Спартак»та тегелгән калын, тигез табанлысы. Ыспай булмаса да, җылы! Бозда таеп егылмаска да әйбәт... иде. Былтыр алган затлы бүреге шкаф шүрлегендә тузан җыеп утыра – шушы җылы, калын мамык шәлгә җитәме соң?!. Бертуган апасы очрашкан саен тукый Фәнзиләгә: «Кием алганда берәрсе белән сайла, яшьләрчәрәк киен, апаем. Җылы ди-ди, җылы мич башына менеп утырырга картайгач та өлгерерсең. Булган матурлыгыңны томалап йөрисең», – ди. «Әбиләр кия торган калын күзлегеңне затлыраккa алыштырсаң соң... Йә булмаса линза алып кисәң...» – дип күзлегенә дә бәйләнә. Бер ияләшкәч, йөри инде Фәнзилә, үзенә уңайлы булгач, тора салып күзлек алыштырырга ни... Шулай да менә бүгеннән нидер үзгәрер

PRESSA.RU

кебек. Үзенә үч итеп, Фаилгә үч итеп... Көн саен, улын алырга килгән саен шулай «картайгансың» дип ярага тоз сибә башласа... Фәнзиләнең – коңгырт күлмәк өстеннән ак алъяпкыч япкан кызыкайның шушы ир-егетне, ул чагында әле борын астына мыек кына төртеп килгән егет-малайны уйлап үткәргән йокысыз төннәре әллә ни еракта да калмаган калуын. Усал телле, орчык урынына бөтерелүчән егет кисәге мәктәптә бер генә ягы белән – үзе әйтмешли, икеле капчыгы булуы белән генә аерылып торды. Укырга теләге юк иде, ә менә йөгерергә, чабарга дисәң – аңа куш. Спорт ярышларында мәктәпне алдынгы урыннарга ул чыгарды, шуңа күрә укытучылар аның үзен дә ничек кирәк алай сөйрәргә тырыштылар. Көннәрнең берендә менә шушы җәлпәк битле, озын буйлы, кысынкырак зәңгәр күзле Фаил бөтен барлыгы белән Фәнзиләнең йөрәк түренә керде дә урнашты бит. Көн саен, сәгать саен күрәсе генә килеп тора. Егетнең бүтән кызлар колагына шаян сүзләр әйтүе, тәкәллефсез генә итеп берәрсенең биленнән кочып китүе, берәр кызның иңбашына кулын салып басып торуы күзенә чалынса, Фәнзиләнең көне көн, төне төн булмый, йокы качкан күзләреннән тамган гөнаһсыз күз яшьләре кечкенә мендәрен сыгып алмалыга әверелдерә. Үзе генә белгән гыйшык хәсрәтеннән, яшерен сереннән кыз әле елады, әле көлде. Аны вакыт-вакыт бер генә нәрсә сагайта иде: Фаилнең эчке дөньясы артык гади, хәтта буш булып тоела. Ул бу дөньяда бер нәрсә белән дә кызыксынмый шикелле, спортчы саналса да, ул өлкәдә дә авыз ачып әйтер сүзе юк. Җыр, бию, рәсем, театр, тарих дип кыймылдатасы да юк. Ә менә Фәнзилә күкләрдә очып йөрергә ярата: үзен йә укытучы, йә тәрбияче ролендә күз алдына китереп, балалар алдында канатлана-канатлана дәрес бирүен, аларны җитәкләп табигать кочагына алып баруын, үләннәр, бөҗәкләр, кояш, йолдызлар турында онытылып сөйләвен хыялында кырык кат тергезгәндер...

Фаил турында «беренче мәхәббәтем, җавапсыз сөюем» дип уфтанган кыз башта уку, аннан эш дип мавыктымы, яшьтәшләре кебек каударланмады, егет-җилән дип башын авырттырмады, балалар янында үзе дә сабыйга әйләнеп, үз көенә иплэп кенә яши бирде. Егерме бише тулып, инде арьягында аяк салындырып утыра башлагач кына күзен күтәреп караса, аның тиңдәшләре гаилә корып, үз нәниләрен үстереп ята икән лә!..

Бүген көтмәгән-уйламаганда Фаилне очрату, аның тавышын ишетү Фәнзиләне әллә нишләтте. «Тиле!» дип сүкте ул үзен күңеленнән генә. Шыр тиле! Шушы буш куыкны уйлап үткәргән төннәрең әрәм... Кара, бер тамчы үзгәрмәгән: һаман да шул буш кеше... «Машина алыштырдым, әй салам»... телендәге бөтен сүзе шул. «Ә синең хәлең ничек, Фәнзилә?» дип ник бер сорап куйсын. Йөзен генә түгел, күңелен дә, хәтта... күзләрен дә май баскан шикелле. Болай да кысынкырак күзләре таза битендә бөтенләй кысылып беткән бит. Йә Алла, шушы кешене, аның мыскыллы елмаюын хәзер ике көннең берендә күрергә туры килерме?.. Аның алдында сер бирeп торырга тагы...

Фәнзилә ярсу хәрәкәт белән шкафның ишеген шапылдатып япты да шундый ук ярсулык белән кире ачты. Көзгегә тагын да якынрак килеп, борын өстеннән күзлеген йолкып алды. Бармаклары белән генә чәчен күпертеп, иңбашына таратты. «Соры тычкан», дип, үзалдына ачусыз гына елмайды кыз, өстендәге соры костюмына, аксыл-соры чәчләренә тагын бер күз салып. Кич чыгарга җыена диярсең – элгечтәге күлмәгенә үрелде. Гәүдәсенә шул тиклем килешле булып яткан, сөтле чәй төсендәге бу күлмәкне бик ошатып алган иде, яңадан киеп-киеп карады да, артык купшы күреп, шкафына элде дә куйды. Янәсе, сабыйлар янына, театрга баргандай, кылтыкланып бару килешмәс... Күлмәк матур иде, тукымасы да кызның тулы күкрәкләрен, уймакка сыярдай нечкә билен, төз аякларын ассызыклап тора, төсенә иш килгән, биек үкчәле туфлиен дә киеп алса...


Күңеле күтәрелеп киткән Фәнзилә инде үзен Фаил каршысына үкчәле туфлиләре белән тек-тек басып, башын югары күтәреп атлаган кыяфәттә күзалдына китерә иде. Күзлеген томырып, линза да киеп куйса, керфекләренә сөрмә тигереп алырга мөмкин. Апасы дөрес әйтә икән, күзлеге тупасрак шул, бөтен матурлыгын яшерә дә куя. Күзләрендә карлыгын каралыгы Фәнзиләнең, томраеп карап торалар. Һи, аларны кара дип йөри тагын, менә бая күргән күзләр соң... Андый да төс була икән! Үзләре кап-кара, уртасында яшел төс тә бар шикелле... Фәнзилә, үзенә апа дип эндәшкән егетнең күзләрен кинәт кенә исенә төшереп, ирен читен тешләп куйды. Матур иде, матурдан да битәр, җылы иде алар...

– Исәнмесез, Фәнзилә Гариповна???

– Фәнзилә Гариповна???

– Фәнзилә Гариповна, сез бүген карап кына тормалы! – Хәтта мөдирә дә – мактауга саран олы яшьтәге ханым да елмаеп, башын чайкап китте.

Иртәдән бирле баласын җитәкләп килгән һәр әнидән, күрешеп үтеп киткән һәр тәрбиячедән үз исемен гаҗәпләнүле, сокланулы, аптыраулы тонда ишетеп, Фәнзилә башта бакчадан чыгып качардай булды. Тора-бара колагы күнекте тагын, кирәксә-кирәкмәсә музыка залындагы биек көзгеләр яныннан үтеп йөрүләре дә сирәгәйде. Көзгегә караса, үзен-үзе танымагандай, кашларын дугаландырып җыера да, кызу адымнар белән чыгып китә. Кичәге соры тычкан төн эчендә әкияттәгедәй аккошка әйләнгән диярсең. Кызның өстендә элек киеп йөри торган шакмаклы җылы блузка урынына – изүе, озын җиң очлары шоколад төсендәге җепләр белән чигелгән «сөтле чәй» күлмәк, элекке калын киң чалбарны коңгырт төстәге капрон оек алыштырган, балалар артыннан йөгереп йөрергә җиңел дип киеп йөргән сандали да әллә кая китеп югалган – кадак үкчәле туфлиләрнең текелдәве ярты чакрымнан ишетелә! Җилкәсенә таратып салган эре бөдрәләре, линза киеп, сөрмә тартып куйган карлыган күзләре, калын кыса астыннан котылып, көн яктысына чыккан кашлары-керфекләре, бүген ни өчендер гел елмаерга гына торган иреннәре – барысы, барысы Фәнзиләне яңадан тугандай итеп күрсәтә иде. Ярый әле бүген кич ата-аналар җыелышы буласы, матурланып



Рәсем: Наталья Васильева

килүенең сәбәбе шуңа бәйләнде дә калды, алайса, төбенә тоз коеп кызыксынырга яраткан кызлардан тиз генә котыласы юк иде.

...Фәнзилә үз төркеменә йөрүче балаларның әти-әниләре алдында кыска гына чыгыш ясарга тиеш иде. Яңа эш урынында җыелышны әле икенче тапкыр гына уздыруы булса да, каушамады, гадәттәгечә, төгәл, матур итеп сөйләп чыкты. Чыршы бәйрәмен уздырганда, бакча ишегалдында кардан төрле җәнлек сыннары ясаганда булышкан ата-аналарга зурлап рәхмәт әйтте.

– Сорауларыгыз булса, рәхим итегез, – дип ата-аналарга төбәлде дә аяк астындагы идәннең әкрен генә шуыша башлаганын тоеп, үзе дә сизмәстән, янындагы урындык аркасына тотынды. Эскәмияләргә ярымтүгәрәк ясап тезелеп утырган әниләр арасында нибары ике бөртек әти заты булып, берсе... кичә генә Фәнзиләгә «апа» дип эндәшкән ир заты иде. Җыелыш башланганнан бирле башын иеп, кулындагы телефоны белән уйнап утырган шомырт күз, менә хәзер, нәкъ кичәге кебек, җылы караш белән аңа текәлгән иде. Кайсы баланың әтисе булды инде бу? Моңарчы кемне дә булса китергәне, каршы алганы күренмәде...

– Фәнзилә Гариповна, минем минем соравым бар иде: ә сез үзегез нинди җәнлек-хайваннарны яратасыз? – дип капылт кына сорады ир, укучы баладай кулын күтәреп.

– Сыртына рюкзак аскан дөядән кала, бөтен хайванны да яратам, – диде Фәнзилә, үзен ары табан да мыскыллаган очракта, тагын да усалрак җавап бирергә әзерләнеп.

Әниләр тыенкы гына елмаештылар, гөжләп алдылар. Ир исә, берни аңламаган төсле, сораулы төбәлде дә, иңбашын сикертеп, тагын телефонына иелде.

Бала-чага, чыр-чу килеп, киемнәрен күтәреп, әниләре янына чабышканда, Фәнзилә күз чите белән генә күреп калды: бөдрә чәчле кечкенә Ләйләгөл, ике җиңеннән ике бияләе күренеп торган кызыл курткасын идәннән сөйрәп, әлеге ирнең кочагына атылды.

Кызның күңеле әллә нишләп китте. Инде ничә еллар көн саен күз алдыннан уза торган күренешләр – нәниләрнең, үзләрен китергән яки каршылаган әти-әниләренең кочагына сарылып, өйгә кайтам яки кайтмыйм дип еламсыраулары, аларга җавап итеп, әни кешеләрнең җилтерәтүләре, назлап кочаклаулары, «бер оегың кая, чәч тасмасын кая куйдың, итегеңне алыштыргансың бит, бүген нәрсә ашаттылар?» дип, көннең-көненә кабатланган сораулары гадәти һәм табигый нәрсәгә әверелгән бит инде. Тормыш тәгәрмәче гел шушы көйгә тәгәрәр шикелле. Әгәр... Фәнзилә үзе дә әни кешегә әйләнеп, менә шушындый нәни генә, йомшак кына, юка толымлы, почык борынлы кызчыгын – үзенекен! – кочагына алып сөйсә, ул кызчыкны бер кулыннан үзе, икенче кулыннан менә шушы... Ләйләгөлнең әтисе шикелле... җылы карашлы, төз буйлы ир-егет җитәкләп алса... Тик аның өлешенә андый татлы мизгелләр язылмас шул...

PRESSA.RU

Кайтырга җыенып, пәлтәсен кигәндә, хат килгәнен хәбәр итеп, телефоны чыңлап куйды. Ят номердан килгән хатта – «Ә син – үзе усал, үзе сөйкемле...» дигән баш-аягы булмаган бер генә җөмлә язылган иде. Сәерсенеп киткән Фәнзилә ни уйларга да белмәде. Кем шаярта, ни өчен, телефонын каян табып?.. Фаил дияр идең, аның теленә гомердә дә мондый сүзләр киләсе юк. «Мин сиңа гашыйк булырга өлгердем». Икенче хәбәр бөтенләй өнсез калдырды. Кемдер рәхәтләнеп шаярта инде, иптәш кызларының берәрседер, мөгаен. «Җавап язарга бер сүз кызганасыңмы?» Фәнзилә түзмәде, кызыксынуын җиңә алмыйча: «Сез кем?» дигән сорау ыргытты. «Дөя». Җавапны укыгач, күзләреннән яшь тибеп чыкканчы рәхәтләнеп көлде, аннан... кисәк кенә еларга тотынды. Күзләрендә линза икәне исенә төшкәч кенә, елаудан кырт туктады. Ни өчен соң әле кичә-бүген аны мыскыл итәргә генә торалар? Нәрсә, бу ир, үзенең бала атасы икәнен онытып, аңа тәти сүзләр яудырырга маташамы? Янәсе, син, карт кыз, үзеңә бераз гына игътибар булса, сары май урынына эреп төшәрсең... Бармаклары ашыга-кабалана ике генә сүз җыйды: «Сез оятсыз!» Әлеге сүзләр очып китүгә, тиз генә телефонын сүндереп атты, дөньяның тагын бер мәнсезе язганны укып вакыт әрәм итәргә генә калган, ди...

Бакча аша кайтып барганда үзен битәрләүдән арына алмады кыз: нигә дип киде инде менә бу үкчәле итекләрен? Бер җылысы булмаган нәзек билле пәлтәсен? Кем өчен матурлануы? Кемгә кирәк ул?.. Аңа насыйп яр булса, менә болай бизәнгән-ясанган мәлендә түгел, җылы шәленә, җылы пәлтәсенә төренеп атлаган чагында юлына чыксын иде дә, әкияттәге кебек, Фәнзиләгә бер күрүдә гашыйк булып, кадакланып калсын иде... Аны ничек бар – шулай, җылы яраткан җанының чисталыгын, җанының матурлыгын күреп гашыйк булсын иде... Тилемсә уйларыннан күңеле күтәрелеп киткән кыз, үзалдына көлемсерәп, кичке күккә карады. Шәһәрдә йолдыз күрергә тилмерәсең шул, багана башындагы ясалма утлар табигатьнең кыргый матурлыгын томалый да куя.

– Шә-әп! Якыннанрак алынса, тагын да шәбрәк чыгасы иде!

Фәнзилә дертләп китте. Кулындагы телефонына черт тә черт сурәт төшерергә өлгергән ир заты кош тоткандай сөенә-сөенә аның каршысына атлады.

– Башыңны менә әз генә бу якка борсаң, бөтенләй шәп буласы иде...

– Сез... тилерәкме әллә дисәм... – Фәнзилә, бөтен йөзен балкытып елмайган ир-егеттән читкәрәк тайпылырга теләп, бер адым атларга өлгермәде, аягы таеп китте дә алга сөрлекте. Тик бу юлы егылмады. Көчле куллар аны шул мизгелдә терсәгеннән эләктереп алды.

– Чү-чү, гел егылырга гына торасың икән син, апасы. Күренә, йолдыз санарга яратасың... Нишләптер матур сүзләрне генә өйрәтмәгәннәр үзеңә, кайда оятсыз, кайда тиле... Тәрбияче кешегә бер дә килешми инде...

– Андый сүзләрне мин кешесенә карап кына әйтәм. – Фәнзилә, иренеп кенә төшкән кар бөртекләренең чәч бөдрәсенә килеп кунганын сокланып карап торды да тавышын кырыслатып: – Сезнең кебекләр белән тәтәйләнеп торасым килми, – дип өстәде.

– Безнең кебекләр? Һм... Нинди була инде ул, безнең кебекләр? – Бу юлы ирнең дә тавышы кырыслана төшкәндәй тоелды.

– Хатыны, баласы бар килеш, төче телләнеп, башкаларга хат язарга маташучыларны, кайберәүләрнең юлына аркылы чыгып, фотога төшерәм дип маймыллanучыларны... Сезнең кебекләр аркасында күпме гаиләләр җимерелә, күпме бала ятим кала, аны уйлап тору юк, әйдә, тасма телләнә дә маҗара эзлә, шулаймы? Ә сабыйларның ни гаебе бар, әйтегез әле? – Фәнзилә, бөтенләй таныш түгел кеше алдында кызып киткәнен абайлап, уңайсызланып калды, тавышы өзелде.

Ир-егет, әле һаман кулында тоткан телефонын әкрен генә курткасының түш кесәсенә шудырды, ни өчендер кара башлыгын салып, сумаладай чәчләрен бармаклары белән тарап алды да башлыгын кире киеп куйды, аннан кисәк кенә тирә-якны яңгыратып көлеп җибәрде. Рәхәтләнеп, кытыгы килгәндәй туйганчы көлде-көлде дә, җитдиләнеп, Фәнзиләнең кулыннан җитәкләде.

– Әле өйләнмәгән дә килеш син миннән әти кеше ясап куйма инде, Фәнзилә. Анысына икәүләп өлгерербез. – Кызның күзләре маңгаена сикергәнне күрмәдеме, күрмәмешкә салыштымы, тагын көлә-көлә сүзен дәвам итте. – Ләйләгөл – минем абыйның кызы ул, үзләре кайтып җитә алмыйбыз дигәч, кереп алдым, шул гына. Миңа инде сине күптәннән димлиләр, яңа килгән тәрбияченең үзе акыллы, үзе матур, үзе әкәмәт әйбәт икәнен сөйли-сөйли, җиңги дә, Ләйләгөл дә колак итемне ашап бетерде. Җай чыкканга гына җыелышыгызга керсәм, каршымда – күзләренә йолдыз төшкән кыз басып тора...

– Әй, көлмәгез сана... – Әллә оялудан, әллә билгесез бер кайнар тойгыдан, Фәнзиләнең бит очлары ут капкандай яна башлады.

– Көлмим, Фәнзилә. Мин ул күзләрне бик озак эзләдем. Иясенең юлымда егылып ятасын алданрак белсәмме...

Егетнең карашына тулган җылылык, күзгә күренмәгән йолдызлар нурына кушылып, тәннең һәм җанның һәр күзәнәгенә тарала иде. Фәнзиләнең уң кулын үз учына алган да, гаҗәеп бер җылы елмаю белән кызга борылган.

...Күр әле, нәзек билле пәлтәсен юка, салкын дип йөреп, ни гомер үзен алдаган түгелме? Каян килеп салкын булсын, күкрәгеn пешерә, аркасын яндыра; төймәләрен чишеп ташла да, кышкы кичнең матурлыгына, сихрилегенә, аклыгына соклана-соклана, чәчләреңне җилгә таратып, карлы сукмакта бөтерелә-бөтерелә йөгер... Туңудан да, таеп егылудан да курыкмыйча, үкчәле итекләрең белән тыпырдап бии-бии кайнар кар бөртекләренә кушылып әйлән – җитәкләшеп, пар булып атлаганда, янәшәдәге боз тауларыннан да җылылык кына агыла икән лә...

КҮП ГАИЛӘЛӘРДӘ ОЧРЫЙ ТОРГАН КҮРЕНЕШ БУ – ХАТЫН-КЫЗ ИРЕН БАЛА УРЫНЫНА КҮРЕП ТӘРБИЯЛИ...



Алсу ИСМӘГЫЙЛЕВА

ИРЕМ БАЛА ТҮГЕЛ ИКӘН!

Безнең гаиләдә хәл шулайрак иде: иртән эшкә чыгып киткән иремә йөз сорау биреп («Телефоныңны алдыңмы? Перчаткаң кесәңдәме? Шарфыңны тыгызрак итеп бәйлә. Ишекне бикләргә онытма!»), аның әзерлеген тикшерү дисеңме, һәрдаим шалтыраткалап, кушылган йомышларның чыннан да эшләнүенә инану дисеңме – кыскасы, мин үземне иремнең әнисе урынына күрә башлавымны сизми дә калганмын.

Ә беркөнне... Беркөнне минем сәяхәткә чыгып китәсем килде. Интернетта Истанбул турында видео күзгә чалынды! Йә Аллам, мин бу шәһәрне шундый сагынганмын!

Кич иремә сүз каттым: «Әтием (без өйдә бер-беребезгә шулай дәшәбез, балалар үстергәндә кереп калган гадәт), мин Истанбулга барып кайтыйм әле! Шундый сагындым! Сеңлем дә минем белән барырга риза. Барыйм инде! 3 кенә көнгә!»

– Бик сагынгач барасың инде, – димәсенме бу!

– Әтием, ә син балаларны алып кала аласыңмы соң? Киендерә, ашата, мәктәпкә йөртә алырсыңмы?

– Нишләп карамаска инде?! Тырышырбыз. Бар, әнием.

Үзем шатланам, үзем уйлыйм: «Кызның чәчләрен үрә белмәс инде. Нәрсә генә ашап торырлар инде. Иртән соңга калырлар инде. Балаларның киемнәре пычранып бетәр инде, аларны алыштырырга кирәген күрә белер микән әтиләре. Ничекләр оешырлар инде...»

Әй, ярар! Өч көндә әллә ни булмас әле! Балалар бәбәй яшеннән күптән чыккан, шактый мөстәкыйль булып үстеләр, исләренә төшермәсәң дә



кайчан нәрсә эшлисен беләләр. Тәвәккәллим!

Кыбырсуым киткәнче, Казан аэропортында ук башланды. Очу тәнгә туры килде. Юл буе: «Иртән соңга калырлар инде, тора алмаслар инде», дигән уй башымнан китмәде. Гүзәл Истанбулга төшү белән смс яздым: «Тордыгызмы? Соңга калмадыгызмы?» «Все нормально, соңга калмадык. Яратабыз сине», – дигән җавап килде. Күңелемә шатлык иңде.

Әмма бераздан тагын башта уйлар этешә башлады: «Балаларны түгәрәкләргә илтә алды микән? Ашарларына акча бирде микән? Вакытында килеп җитте микән? Балалар әтиләрен көтеп урамда тормыйлар микән?»

Тагын смс яздым. Тагын тынычландыра торган җавап килде.

Өч көн буе сәяхәтем шундый уйлар белән үрелеп барды. Төрек ризыкларыннан авыз иткәндә: «Балаларга нәрсә ашатты икән?», Гөлханә паркында йөргәндә: «Балаларга нинди курткаларын кидерде икән?», кибеттә ирләр күлмәге күргәч: «Мәктәпкә йөри торган ак күлмәкләрен алыштырды микән?»... Һәм шулай бертуктаусыз!

Әле киткәндә инструкция язып киткәнемне әйтергә онытып торам. Ике зур бит кәгазь тутырып, кайсы очракта нәрсә эшләргә тиешлеген аңлатып күрсәтмәләр яздым да, суыткыч ишегенә элеп калдырдым. Кыскасы, полный комплект! Әйтерсең лә, балалар да, ирем үзе дә уйлый белми, мин генә бөтен нәрсәне беләм.

Шулай йөреп кайттым. Очкыч төшкәндә Казанда инде көн башланган иде. Балаларның мәктәптә, иремнең эштә чагы. Өй ишеген ачып, иң куркыныч күренешләрне күрергә әзерләнеп керәм (куркыныч күренеш дигәнем юылмаган савыт-саба, кәрзин тулы кер, тузган өй). Керсәм – өй ялт иткән, савыт-саба юылган, урыннар җыелган, ә суыткыч ишегендә записка – «Әнием, суыткычта сиңа аш бар, кичә кич пешердем».

Күңелләр бер тулды, бер күтәрелде. Ике балам һәм ирем мине ял иттерделәр бит, рәхмәт төшкерләре! Өчесе дә маладислар икән! Өчесе дә үскән икән. Ә иремне бала урынына күреп бик ялгышканмын бит!

Кич җитте. Ирем эштән кайтты. Кулында кызымның курткасы. «Замогы ватылган иде, ательеда рәтләттем», – ди бу.

Кит аннан! Шуны да эшли алган! Ә бит замок ватылса ательега барасы дигән инструкция язмаган идем!

Уены-чыны бергә, кызлар. Ләкин ирләргә әни булырга кирәкми икән.

Бу сәяхәт минем уйларымны дөрес якка борды дисәм, һич ялгышмам. Мин дөнья тоткасы түгел, ә хатын-кыз. Балаларыма – әни, иремә – хатын.

PRESSA.RU



Быел Советлар Союзы Герое Муса Җәлилнең – татарның йөз аклыгы Җәлилнең, дөньякүләм танылган патриот шагыйрьнең тууына 110 ел. Татар халкы аны йөрәгендә саклый. Без аның хакында бөтенесен дә беләбез кебек. Инде күпме романнар язылды, драма әсәрләре сәхнәгә куелды, кинофильмнар төшерелде.
Шагыйрьнең хатыны Әминә ханым, кызы Чулпан Җәлиловалар... Укучыларыбызга алар да шулай ук үз, якын. Халкыбыз күңелендә аларга карата никадәр җылы хисләр саклана!
Шулай да кыска, ләкин мәгънәле, иҗатка, хисләргә бай гомернең халыкка бик үк мәгълүм булмаган сәхифәләре дә бар. Алар әле һаман ачыла тора... «Мин тормышта тирән һәм ялкынлы сөя беләм. Мин табигатьне дә, кошны да, чәчәкне дә, музыканы да һәм намуслы хезмәтне дә, ялкынлы иҗатны да, тиңдәшсез илемне дә шулай ук янып, кайнарланып сөям. Бу минем эчке тирән бер сыйфатым инде. Мин хатын-кызга да шундый ук саф, кайнар сөю бүләк иттем», – дип яза Шагыйрь җырчы Зәйтүнә Илбаевага юллаган бер хатында. «Сөюнең үзен акыл белән эшләп булмый. Сөю – йөрәк эше», – ди ул. Шулай булгач, аның юлында очраган хатын-кызларның берсен дә без ялгыш дия алмыйбыз, аларның һәрберсе – аның язмышы...

«УЛ МИНЕ ЙӨРӘГЕНДӘ САКЛАР»



Нәбирә ГЫЙМАТДИНОВА

Әкрен генә кыңгырау төймәсенә басам. Күңелдә икеләнү: бу очрашуның нәтиҗәсе булырмы? Нишләп ул тора салып миңа серен ачарга тиеш әле? «Ярамый!» Аларны бу хакта бик күп кисәткәннәрдер. Гәрчә тыю-тыелулар заманы узган: 1995 елның соңгы ае. Илдә демократия «чәчәк аткан» чор. Ә бәгъзе адәмнәр чынбарлыкны гайбәткә генә әйләндереп калдырмакчы, әмма «изге ниятләре» барып чыкмый шул. Без капчыкта ятмый, диләр – көннәрдән бер көнне шагыйрь Муса Җәлилнең Чулпаннан башка тагын Альберт белән Люция исемле балалары бар дигән хәбәр тарала. Альбертның әнисе – Рауза, Люциянеке – Зәкия. Мин нәкъ менә икенче ояның «кошлар»ын эзләп киләм... Кемнәр алар, кемнәр?

Әлеге күрешүдән соң 20 елдан артык вакыт үткән икән. Бүген дә күз алдымда тора: 82 яшьлек хуҗабикә кыстый-кыстый чәй эчәргә утырткан иде. Табын янында сөйләшеп туймадык без. Ак кәгазьгә төрелгән язмышлар кызыклы да, гыйбрәтле дә иде. Бүген ул хатирәләр кабат күңелдә яңарды.

«Ул беребездән дә баш тартмады...»

Зәкия 1913 елда Казанда туа. 13 яшендә чакта әтиәнисе белән Донбасска күчә һәм җидееллык мәктәпне тәмамлагач, Кузнецк шәһәрендәге укытучылар әзерли торган техникумга укырга керә. Шигырьләр язу белән шунда мавыга башлый, чөнки монда Латыйф Җәләй әдәби түгәрәк оештыра, кызның язганнары ошый җитәкчегә. Шигырьләрен туплап Муса Җәлилгә – «Октябрь баласы»на җибәрергә киңәш итә. Муса Җәлилдән җавап хаты килә: «Акыллым, – дип яза шагыйрь. – Поэмаңны укыдым, тиздән басарбыз. Фотосурәтеңне сал». Ике арада хатлар йөри башлый.

Зәкиянең әти-әнисе кире Казанга кайта. Кыз Казанда өйрәнчек сыйфатында телеграфка эшкә урнаша. Беркөнне аңа: «Сине аста бер ир-егет көтә», – дип әйтәләр. Зәкиянең аппарат көйләп яткан чагы, кулы майга буялган, шул килеш кенә ул аскы катка йөгереп төшә. Һәм аптырап китә. Бәрәч, Муса Җәлил! Шагыйрь, кыздан көлеп: «И акыллым, син бигрәк кечкенә икән!» – ди. «Абый, сез үзегез дә бик зур түгел икән бит», – дип җавап бирә чая кыз.

Бу аларның беренче мәртәбә күзгә-күз очрашуы була. «Нишләп йөрисез, абый? Ни йомыш?» – ди Зәкия, дулкынлануын яшереп. Шундый мәртәбәле шагыйрь аны эзләп килсен әле! «Яшьләрне кечкә редакциягә җыябыз, син дә кил, Казанда «Октябрь баласы»н чыгарабыз», – ди Җәлил. Яшь язучылар бертавыштан журналның мөхәррире итеп Галимҗан Мөммәтшинны, ә сәркатип итеп Зәкия Садыйкованы сайлыйлар. Тик алар «Октябрь баласы»ның ике генә санын әзерләп өлгерәләр, журнал ябыла. Әмма очрашу-күрешүләр өзелми. Шагыйрьнең йөрәгендә гыйшык уты кабына. 1935 елда Муса, кызга мәхәббәтен белгертеп, кушылырга тәкъдим ясый, әнисеннән дә кулын сорый.

Өйләнешик дигән көнне Муса тугыз тапкыр Зәкия янына килә, ә кыз гел качып кала. Телеграфтагы кизү хатынга өенә китте дип алдашырга куша, ә өйдәгеләргә эштә дип әйтегез ди. Ә кичен егет Зәкияләрдә кала... Әнисе: «Теләсәгез нишләгез», – ди. Ул Мусаны өнәп бетерми, кызына гел: «Шуның нәрсәсен яратасың», – дип тирги. Ярату булган шул инде. «Мин сезгә никах укытам», – дип, әнисе өйгә бер бабайны дәштерә. Ә Зәкия белән Муса шырык-шырык көлеп, такта белән бүленгән бүлмәдә тыңлап утыра. Ул вакытларда дингә караш тискәре була бит. Шулай яңа тормыш башлаган көннәрдә Муса хатынына серен тишә. «Зәкия, синең алда гаепле мин», – ди. «Ничек гаепле?» – ди хатын. «Минем Раузада малаем бар», – ди бу. Әлеге хәбәр Зәкияне һуштан яздыра. Раузалар белән бергәләшеп театрларга йөргәч, аны-моны сизми бит ул.

Хатын яңа хәбәрне бик авыр кичерә, җитмәсә, балага да узган була бит инде. Муса: «Мәскәүгә китәбез, җыен», – ди, ә Зәкия кабаланмаска өнди. Ник дигәндә, укып кайтып, телеграфта местком рәисе вазыйфасын башкарган чагы. Декрет акчасы да шактый гына тиясе. «Бала акчасын алгач барырмын, син китә тор», – дигәч, Муса: «Дөрес әйтәсең, Зәкия, тик үпкәләмә генә», – ди.

Ул арада Мәскәүдән төрле сүзләр ишеттерә башлыйлар. «Ник монда көмәнеңне күтәреп йөрисең, бар, ирең янына кит», – ди бермәлне Фатыйма Ильская. Зәкия: «Вакыты җиткәч китәрмен», – генә ди. Менә ул Мәскәүгә җыена. Әнисе яңа юрганнар сыра, күчтәнәчләр төйни. Вокзалда Муса машина белән каршы ала. Зәкия: «Кая барабыз?» – дип сорагач: «Өйгә кайтабыз», – ди. Хатынның күңеле тартмый гына бит, ул өйгә берәүнең килеп йөргәнен ишеттергәннәр чөнки. «Бу синең икенче алдашуың инде, башка җиргә илт», – ди. Ә берничә көннән ул Ташкентка – дус кызы янына китәргә карар кыла. Муса юлына әйберләр сатып алып бирә. Соңыннан хат яза: «Син мине җәзалый аласың», – ди. Тик хатын алай ямьсезләнеп йөрми. Кызлары Люция Ташкентта туа. Җәлил аңа акча салып тора. Берсендә: «Зәкия, һич акчаны арттырып булмый, син судка бир инде», – ди. Үзе кушкач, үзе үтенгәч, Зәкия аны алиментка бирә. Берьюлы Раузага да түли ир.

Казан сагындыргач, Зәкия тота да туган җиренә кайта. Беркөнне Язучылар берлегенә килгәндә, урамда аңа китап нәшрияты управляющие Закир Тинчурин очрый. «Кая барасың? – ди. – Эш эзләпме? Әйдә, безгә. Аптыраган менә, бөтенесен дә утыртып бетерделәр, китап чыгарырга кеше юк».

Зәкия апа миңа моңарчы беркемгә дә күрсәтмәгән хатларны да укыткан иде. Латин хәрефләре белән язылган Җәлил хатлары...

1939 елда Зәкияне хатыны үлеп ике баласы белән тол калган иргә ярәшәләр.

Муса Казанга килсә, Люцияне күрергә ашкына. Зәкия, ире көнләшкәнгә күрә, аларны читтәрәк күрештергән. Берсендә ул сөткә барырга җыенганда, бу хакта алдан ук Мусага әйтеп куйган, Люция белән икәү барабыз, фәлән тыкрыкта көт, дигән. Аларга үги кызлары да иярмәкче була. Аны көчкә көйләп-җайлап калдыралар. Люцияне Муса сөя, иркәли, конфетлар бирә һәм юл буе күтәреп бара. «Әллә кемгә охшап бармаклары зур», – дигәч, «Минеке кебек», – ди.

Җәлил хатларын мин тыныч кына укый алмадым...

«Зәкия!.. Люцияне бик күрәсем килә. Ул үсеп зур булыр. Мине белмәс тә. Минем менә шундый авырлыклар белән ярты гомерем кыскарганны аңламас та. Сез аңа мине начар итеп сөйләрсез. Ул үзенең бәхетсез әтисе өчен йөрәгеннән сызланса да, бернәрсә дә әйтә алмас. Ул, бәлки, үскәч, аңы ачылгач, минем язуларны табып, укып, яшерен генә җылар. Күп усал сүзләргә карамастан, ул үскәч, минем шигырьләрем белән танышыр, үзендә миңа карата бик тирән якынлык сизәр. Ул мине йөрәгендә саклар: ник сакламасын?! Мин әти бит аңа!.. Ул ялкынлы шигырьләремдә минем тормышымны күрмәсмени?! Ул минем бер идиот булмаганымны, ә йөрәк белән янып яшәгән, зур кичерүләр белән гомер иткән

PRESSA.RU

шагыйрь икәнемне белмәсмени?! Кызларның йөрәге йомшак була. Ул минем көндәлекләремдә үзе һәм үзем турында укыганда: «И бер генә күрсәм иде», – дип җыламасмыни?!

...Мин бик теләр идем Люцияне үземә алырга!.. Син бир миңа Люцияне! Сездә болай да өч бала. Сезгә авырдыр. Мин Люцияне синнән ким тәрбияләмәм. Аннан соң Зәйнәп (сеңлем) Казанга күчә бит! Ул – инженер. Ирсез, баласыз. Ә бала бик ярата. Ул карар. (Миңа да якын булыр.)

...Дусларча килешенгәч, семьяда да татулык туар, балалар белән очрашу күңелле булыр.

Тәкъдимемне кире каксагыз – миңа үлем белән бер. Аны аңлагыз.

Мин озын яздым. Ләкин сүзем әле тагын бик күп иде. Йөрәктән, чын күңелдән язам. Аңлашасым килә. Аңлашып яшисем, иҗат итәсем килә.

Хуш, акыллым! Теләсәң нишлә, ихтыяр синдә!

Сәлам белән, Муса».

Язмыш аны ник болай газаплаган, баласыннан аерган икән, әгәр аермаса...

– Муса гына гаепле түгел, – диде Зәкия апа. – Минем горурлыгым комачаулады Мәскәүдә калырга. Кит димәде бит ул. Кал, диде, күз яше түкте. Миндә дә гаеп. Кайбер кешеләр Мусаның өч хатыны булган, дип, гайбәт саталар. Мин аларның авызын тиз ябам. Булса ни! Ул беребездән дә баш тартмады.

Муса белән бергә үткәргән көннәрдән нинди вакыйгалар Зәкия апаның хәтерендә ныграк уелган соң?

Сугышка киткәндә дуслары Мусага озату кичәсе оештыралар. Зәкия апа моны ишетеп, кызын да алып бара. Муса чыга да, Люцияне үбеп-кочаклап, хушлашып кереп китә...

Язмыш Зәкиягә сынауларны өя генә. Төпчек улы салкын тиеп үлә, соңрак бик яраткан үги кызы вафат була, сугыш башланганда эшсез дә кала яшь хатын. Ләкин уңган, җитез, чая Зәкия кайда да югалмый, хәрби госпитальдә идән юа, китапханәче булып эшли, яралы солдатларга китаплар ташый. Госпитальнең местком рәисе итеп сайлангач, Чуашстаннан кадәр орлык юнәтеп, бәрәңге чәчтерә, шул бәрәңгене урламасыннар дип, кырда төнге каравылда да тора. Район партия комитеты булдыклы хатынны, партия мәктәбендә укытып чыгаргач, Г. Камал театрына әдәби бүлек мөдире һәм партоешма секретаре итеп җибәрергә ниятли. Тик Зәкия театрга барырга теләми, радиокомитетка – балалар редакциясенә урнаша. Биредә дә аңа местком рәисе камытын кигерәләр.

Эш белән кайнап яшәгән хатын беркайчан да йөрәгеннән Мусаның исемен сызып ташламый. «Сатлыкҗан» дигән сүзгә ышанмый ул, кызында атасына карата олы мәхәббәт тәрбияли: «Синең әтиең – Җәлил!» – дип тәкрарлап үстерә.

1954 елда СССР Югары суды Люция белән Альбертның М. Җәлил мирасына хаклары бар, дигән карар чыгара. Шагыйрьнең: «Татарча язу танучы һәм бу дәфтәрне укучы дуска» дип аталган васыятендәге (1943 ел, декабрь ае) «Моны язды татарның билгеле шагыйре Муса Җәлил. Аның тарихы болай: ул 1906 елда туган. Гаиләсе Казанда һәм Мәскәүдә», – дигән юлларны укысаң, бөтенесе дә аңлашыла кебек.

Мусаның җәзалап үтерелүе турындагы белешмә закон нигезендә аларга да тапшырыла.

Зәкия апа Ә. Ерикәйнең «Әти безнең кайтмас инде» шигыренә сценарий яза. Шуны шагыйрьгә күрсәтергә дип, Язучылар берлегенә китә. Барса, аңа әдәби фонд сәркатибе Халикъ Садри очрый. «Зәкия, – ди бу, – йөзләрегез тәмам агара хәзер», – ди. Хатын берни аңламый. «Минем йөземнең каралганы да юк», – ди. «Мусаның икенче дәфтәре килде, син аның почеркын таныйсыңмы?» – ди. «Ничек танымыйм, без хат алышкан кешеләр бит», – ди. «Дәфтәрне райкомга укырга алып киттеләр әле», – ди Садри.

Закир Тинчурин китап нәшриятының партоешма секретаре була, аңа дәфтәр хакында белгертәләр, ул Зөбәйдә атлы сәркатип кызны чакырта да, дәфтәрне бастырып, бер данәсен Зәкиягә бирерсең, ди. Зәкия төн ката елый-елый Мусаның язмаларын укый. Ул дәфтәрнең берсен Зәкия апа гомере буе архивында саклый.

Муса кызы – Люция

Мәктәптә укыганда ук Люциянең бик сәләтле бала икәне беленә. Ул музыка мәктәбен дә тәмамлый һәм, музыка училищесына имтихан тотып, хор дирижеры белән вокаль бүлеге студентына әйләнә. Училище директоры Ильяс Әүхәдиев бу кызның талантын югары бәяли, аңа һәрвакыт ярдәм итәргә тырыша, 2 нче курс студенты хәтта тамашачыны сихри тавышы белән таң калдырып, Опера һәм балет театрында, зур концертта, хорда башлап җырлый. Бик дулкынландыргыч минутлар белән хәтергә уелып кала ул көн. Ничек дулкынланмасын Люция! Әтисе исемен йөрткән изге бинада җырлый лабаса! Җитмәсә, концерттан соң сәхнә артына атылып Җәүдәт Фәйзи килеп керә һәм, кызны котлаганнан соң, бер серен чишә. «Беләсеңме, «Кызыма» дигән җырны 1936 елда минем көйгә әтиең син тугач, сиңа багышлап язган иде», – ди. (Соңыннан моны Фәхри Насретдинов та раслый.)

Укытучылары аңа зур өметләр баглый, киләчәктә кыз җыр-музыка сәнгате дөньясына чумар, дип уйлыйлар. Ә Люциянең күңелендә нинди сер яшеренгәнен берәү дә белми... Әтисе турында фильм төшерергә хыяллана ул. Шушы хыял аны 1958 елда Мәскәүгә алып китә. Берьюлы ике абруйлы уку йортына – Дәүләт театр сәнгате һәм Бөтенсоюз дәүләт кинематография институтларына имтихан бирә, анда да, монда да уза һәм икенчесен сайлый.

Люция иң абруйлы уку йортының ишеген шакый. Сайлаган һөнәре дә җитди: кино режиссеры. Аны укыткан С. Герасимов, Е. Дзюган, Т. Макарова кебек

СССРның халык артистлары, кино сәнгатенең классиклары – үзләре бер тарихи шәхесләр.

Кыз Сергей Герасимов курсына килә. Герасимовның бөтен курс белән «Люди и звери» исемле фильм эшләгән чагына эләгә. Бу аның өчен иң әйбәт режиссура мәктәбе була, остазының үзенә аерым бер игътибарын тоя ул. Шул чакларда әтисе турында фильм эшләү идеясе тагын да көчәя. Аның хыялы – әтисенең шагыйрь буларак батырлыгын күрсәтү. Сценарийның биш битен укыган Герасимов, икенче очрашуда, түземсезләнеп: «Җәлилова, кая дәвамы?» – дип сорый. «Синдә киноның яңа жанры туа», – ди ул берсендә. Кызганыч, бу фильмны тәки тормышка ашырып булмый.

– Бер көнне Казаннан чакыру алам. – Люция ханым хәтерен яңарта, – Муса турында фильм яса, сценарий әзер, – диләр. Кайтам, сценарий юк. Үзем язарга утырам. Архивларда казынам, әтинең барлык документларын өйрәнәм, юбилееннан өзекләр, җәлилчеләрнең очрашу мизгелләрен төшерәм. Мәскәүгә барып, язучыларның I корылтаенда Җәлил сөйләгән чыгыштан кадрлар эзләп карыйм. Нәтиҗәдә, ике сценарий төзим. «Революция тудырган» дигәнен сәнгать советы «ура» кычкырып кабул итә дә... кино төркеме башлыгы: «Безгә бу фильм кирәкми инде», – дип белдерү ясый.

Казан телестудиясендә бер генә әйберем дә куелмагач, эшләүнең кызыгы бетте, кире Мәскәүгә киттем. «Ленфильм»ның «Моабит дәфтәре»н төшерергә җыенган көннәре иде. С. Герасимов бит инде минем сценарий белән таныш, аны ошаткан иде. Шуны истә тотып, ул «Ленфильм» директоры И. Киселевка мине «Дәфтәр»нең автордашы итеп алырга дигән тәкъдим кертә. Директор ризалаша, ләкин Казанга бара да, мәгълүм агайлар аны миңа каршы котырта, фикер үзгәрә, ул Җәлиловадан баш тарта. Мине нибарысы ассистент итеп кенә билгелиләр.

Гази абый Кашшаф «Моабит»ның өлкән консультанты иде, ул минем фамилиямне титрдан сызып атуны таләп иткән. Директор нишләсен, аңа бу фильмны Татарстанга тапшырырга кирәк, консультант белән бәхәскә керергә теләми ул.

1972 елда ул үзешчән сәнгать йортына методист булып урнашу «бәхетенә» ирешә. Спектакльләргә, концертларга, кинофильмнарга төрле рецензияләр яза, күп басыла. Күрәсең, аның иҗади активлыгы Югары Совет рәисе Салих Батыевның игътибарын җәлеп иткәндер. Батыев 1966 елда Люцияне, абыйсы Альберт белән үзенә чакыртып, хәл-әхвәлләрен сораша.

Сирәк белгеч – курчак театрында музыка көйләүче техник, склад мөдире (!), кинопрокатта рекламалар буенча мөхәррир, тик кино режиссеры гына түгел. Мәскәүдәге укытучылары мондый хаксызлыкка борчыла. Менә бер хаттан өзек:

«Советская культура» газетасы үз корреспондентына сезнең иҗади язмышыгыз белән кызыксынырга кушты, аңа ни өчен җаныгызны ашаулары турында яшермичә сөйләгез. Ниләр булып узганын миңа да җентекләп язарсыз. Белегез, кадерлем, мин көчемнән килгәннең барсын да эшләрмен. Без сезне яратабыз, Люциякәй, сезне сагынып искә алабыз.

Сезнең Дзюган Е. Л. 5 июнь, 1981 ел.»

Әти, әти кеше... Гәрчә ата җылысыннан мәхрүм булып үссә дә, йөрәктә аның исеме тирән уела. Менә ул хатирәләр:

– Әни күңелемдә әтинең илаһи образын тудырды. Ул әти хыянәтче саналган иң яман көннәрдә дә аның турында әйбәт итеп кенә сөйли, ялгыш та әтиең алай, әтиең болай дип шик белгертми, Җәлилнең сатлыкҗан түгеллегенә ышана һәм мине дә ышандыра иде. Әни бит 1946 елда Әхмәт Ерикәйгә: «Балта белән кулымны кисterәм, Муса хыянәтче түгел», – дип кычкыра. Моңа бит бик зур батырлык кирәк. Эчтән генә мин әтием Муса белән горурлана идем. Әни белән безне уртак сер – әти берләштерә иде. Качып-качып, ул миңа аның хатларын укый иде. Әтинең фаҗигасе икебезгә дә кучкән, без – ике ятимә, кыйналган җаннар идек. Әтинең туган көне җитте исә, үзебезчә, гаиләдән яшеренеп кенә бәйрәм итәбез, икәү әни белән әти очрашкан урыннарны урыйбыз.

70 нче еллар... Казан... Эшсезлек. Люция өчен гап-гади клубларның ишеге бикле. Гүя кара күләгә аны сытарга-изәргә җыена.

...Өйдә фортепьяно уйнап утыра идем, каты гына тәрәзә шакыдылар. 1953 ел иде бу. Шагыйрә Гөлшат Зәйнашева атылып килеп керде. Ул дулкынлана, елый иде. «Люция, – ди Гөлшат апа. – Әтиең бер дә хыянәтче түгел, ул – герой, илгә аның данлы исеме кайтты!» Аңа әйткән сүзем дә исемдә: «Мин әтиемне беркайчан да хыянәтче дип санамадым». Ә мәктәптә директор бүлмәсенә чакыртып Язучылар берлегенә барырга куштылар. Тукай клубына йөгердем. Клуб шыгрым тулы, әнине эзлим, ул күренми. Кемдер: «Мусаның кызы керде», – диде дә, халык кул чабарга кереште. Миңа президиумда утыручы абый кул изәде. Сәхнәгә мендем, сүз бирделәр, «рәхмәт, рәхмәт» дияdiя, сөйләп төштем.

...1957 елның августында Җәлилнең шигырьләрен коткарган бельгияле Андре Тиммерманс хатыны Мария Жан белән Мәскәүгә килде. Алар «Ленинградская» кунакханәсенә тукталган иде. Андре абыйны күргәч, фикерем чуалды, йөрәк тибешем әкренәйде. Әтиемнең соңгы сулышын китергән кеше иде бит бу. Еллар буе әлеге очрашу хакында хыяллана идем мин. «Тагын Мусаның кара күзләрен күрәм!» – дип, Тиммерманс үзе сүз башлады, ә хатыны, аны җөпләгәндәй: «Җәлилне фотодан гына күреп беләм, ләкин бу кызның йөзе миңа шулхәтле аны хәтерләтә», – диде.


Язманы тулысы белән сайтыбызда укый аласыз.

PRESSA.RU

ГОД РОССИЙСКОГО КИНО 2016

ФИЛЬМОГРАФИЯ

1994 «Утомленные солнцем» – танкист
1998 «Сибирский цирюльник» – Полиевский
1999 «Ворошиловский стрелок» – Игорь Зворыгин
2000 «Свадьба» – Мишка Крапивин
2000 «Тихие омуты» – гаишник
2000 «Идеальная пара» – Андрей
2001 «Кобра» – Кирилл Гриднев
2001 «Граница. Таежный роман» – лейтенант Иван Столбов
2002 «Ледниковый период» – Саша Каплевич
2002 «Олигарх» – Кошкин
2002 «Шукшинские рассказы» («Гена Пройдисвет») – Гена Пройдисвет
2003 «Спас под березами» – мотоциклы хулиган
2004 «Гибель империи» – Штольц
2004 «72 метра» – капитан-лейтенант Петр Орлов
2004 «Холостяки» – Гоша Кюрдзидис
2005 «Турецкий гамбит» – Фандорин
2007 «Ленинград» – Юра Краско
2008 «На краю света» – подполковник Власов
2009 «Пассажирка» – матрос Чижиков
2010 «Бриллиантовая рука-2» – Козодоев
2012 «Ржевский против Наполеона» – Багратион



МАРАТ БӘШӘРОВ



КАСТИНГ

Россия Дәүләт премиясе лауреаты, Татарстанның атказанган артисты Марат Бәшәров бөтенләй дә артистларныкы булмаган гаиләдә Мәскәүдә туа. Әтисе – слесарь, әнисе – аш-су остасы. Марат мәктәптә башкисәр бер малай була. Иң яхшы тугрылыклы дусларын да мәктәптә таба ул. МГУның юрфагына укырга керә. Абыйсы, театр тәнкыйтьчесе «Современник»ка Никита Михалков спектакленә кастингка барырга киңәш итә. Бара да, уза да Марат! Аннары юрист буласы килмәгәнен аңлап, документларын Щепкин исемендәге театр училищесына тапшыра. Башкалардан аерылып торыр өчен иҗади конкурска балалайка күтәреп килә. Җырлап, биеп, бөтенесен шаккаттыра. Уку дәверендә рекламаларда төшеп, төнлә каравылда торып акча эшли. Шул чорда Михалковның «Утомленные солнцем» фильмында танкист ролен уйный.



ЧЫП-ЧЫН ХӘРБИ!

Училищены тәмамлауга ук Никита Михалков аны «Сибирский цирюльник» фильмына чакыра. Марат аны «киноәти» дип йөртә башлый. Беренче җитди роле шушы фильмда. Юнкерлар ролен уйнаучылар өч ай буена чын хәрби казармада яшәп алалар! Партнеры Олег Меньшиков белән дә шушы фильмга төшкәндә дуслаша. «Граница. Таежный роман» телесериалында лейтенант Иван Столбовны уйнап та тамашачы күңелен яулый. Бу фильмда Маратның балачак хыялы тормышка аша: чын урманда, чын корал белән, чын хәрби киемнән чын-чынлап «сугышлы» уйныйлар.




МАРАТ... ЕВА РОЛЕНДӘ

«Думай как женщина» сериалында Маратны тамашачы аны тездән түбән итәктән, биек үкчәле туфлиләрдән, муенына төрледән-төрле яулыклар бәйләгән итеп күрә. Көненә икешәр мәртәбә кырыну, каш йолку, маникюр, макияж, эпиляция... Итәктән йөрер өчен Марат... аяк төкләрен дә кыра хәтта! «Шуны аңладым, хатын-кызның серләре күп була икән! – ди Марат. – Һәм ул серне бөтен кеше белә!.. Сезгә кызыкмыйм, кызлар, итәк астына гел җил өрә. Озын тырнаклар белән ничек йөрисездер! Коточкыч! Аякны кашып та булмый, шундук оекның күзе китә!..»



ШӘХСИ ТОРМЫШ

Марат – аралашучан, үзсүзле. Спорт белән мавыга, хоккей, футбол, теннис уйный. Спорт стилендә киенә, үзен аңлардай хатын-кызларны хөрмәт итә. Акчага табынмый, ялгыз калудан курка. Сериалларда төшергә яратмавын яшерми. «Бу ир-ат эше түгел. Акчасы юк икән, ширпотребта уйнаганчы, вагон бушатсын», – ди. Элеккеге киноларны ярата. «Летят журавли»ны кайта-кайта карый. Беренче хатыны Елизавета Круцко белән никахлашып өйләнешәләр. Елизавета ислам динен кабул итә. Кызлары Амелига 15 яшь. 2014 елда актриса Екатерина Архаровага өйләнә. Озак тормый, аерылышалар.



БОЗЛЫК ДӘВЕРЕ

«Йолдызлар бозда» ТВ проектында фигуристка Татьяна Навка белән җиңеп чыгалар. Ә кадрильне ничек бииләр! «Бозлык дәвере-3»не исегезгә төшерегез! Татьяна Навка белән Марат Бәшәров иң матур, иң романтик пар дип табыла!

«Бозлык дәвере-2»не, «Боз һәм ялкын»ны Анастасия Заворотнюк белән бергә алып бара. «Йолдызлар белән бию-2012»дә биюче Кристина Асмаловская белән парлап чыгыш ясап, III урынны алалар.



МАРАТ ТАТАРЧА ҖЫРЛЫЙ

Россия каналында барган халык биюләре тамашасында түбәтәй, чигелгән камзулдан жюрида утырды. «Бозлык дәвере»н алып баручы Бәшәров биергә чыккан Чулпан Хаматова белән дә татарча сөйләшеп алган иде. Марат татар булуы белән горурлана. Машинасында татарча җырлар тыңлый. Наилә Фатехова белән яздырган «Кара күземә генә», «Мең яшик!» дигән җырлары бар. «Казанны яратам, монда туган телемдә сөйләшәм!» – ди ул. Казандагы Мәүлид бәйрәменә багышланган «Җан белән сөйләшү» дигән театрлаштырылган музыкаль тамашада Марат Бәшәров төп рольне башкарды.

Мәгълумат һәм фотолар төрле матбугат чараларыннан алынды

PRESSA.RU

ТАБИГАТЬ БАЛАЛАРЫ

БЫЕЛ ТАТАР ТЕАТРЫНА – 110 ЯШЬ! БИЮЛӘР ТЕАТР ТАРИХЫНЫҢ НЕОСӘХИФӘСЕ УЛ ДИЯР ИДЕМ.

Данлы-шанлы юлын драмалар, музыкаль мелодрамалар белән башлаган милли театрыбыз сәхнәсендә хәзер ритмлы музыка, ритмлы һәм лирик биюләр, җыр һәм музыка кебек үк, табигый тоела. Бу яңа агымның татар сәхнәсен биләп алуында Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе балетмейстер Сәлимә ӘМИНОВА белән Татарстанның халык артисты Илдус ГАБДРАХМАНОВның өлеше зур.

«Бәхетең авылда синең»

Багучы карчык янына Сәлимә кызларга ияреп кенә, юри генә барган иде. Ә ул, әнә, берочтан аңа да киләчәген юрап җибәрде. Авылга кунакка гына кайткан Уфа кызына: «Авыл егетенә кияүгә чыгасың», – диде. Хәзер менә! Чыкты, ди! Сәлимәнең бөтен хыялы биюче булу. Мәшһүр Фәйзи Гаскәров җитәкләгән ансамбль концертларының берсен дә калдырмый кыз. Бию түгәрәгенә, аннары ансамбль каршындагы студиягә йөри. Башкорт дәүләт бию ансамбленең очышка тиң дәртле биюләрен караганда әсәрләнгән кызның күзләренә хәтта яшь бәреп чыга. Авыл, ди, менә хәзер!

Хәер, авыл да бик ошый аңа. Зыянчура тиягендәге Байдәүләт авылын, Сүрәм елгасын сагынып кайтканда кызыкай, авыл баласы булып, бер кинәнеп яшәп ала. Авыл

аны очышка якынайта, ашкынулы канатларына җил егәре бирә кебек. Анда кешеләр табигать белән берегеп яши. Хәтерли әле, унике яшьләрдә булыр. Күрше агай, кызның алмачуар тулпар янында ымсынып торганын күреп, Сәлимәне учына гына бастырды да ат сыртына атландырып та куйды. Далаларга очарга әзер торган малкай җилдереп тә китте. Үсмер кызыкай, күрәсең, атның ялына чытырдатып ябышырга кирәклеген белгәндер инде, ни курыкса да, ат сыртыннан мәтәлми. Бахбай да, миһербаны килепме, җайдагы тәҗрибәсез бала булуын аңларлык акыллы ат булгангамы, дәртен басып бер җилдереп алгач, ипле юртып кына Сәлимәне исән-имин алып кайтып җиткерә. Авыл кешеләренең генә кала кызының бу батырлыгына исләре китми. Нәмә булган? Ат менеп чабучы бер ул гынамыни? Әле алай гына да түгел. «Син булдырасың икән», – дип, икенче көнне ат белән чүмәлә тарттырырга куялар. Арт шәрифләре суелып беткәнче аттан төшми кыз. Менә шундый ул авыл тәрбиясе – анда назлануга, зарлануга урын юк.

Сәлимәгә «бәхет» буласы егет әле бу вакытта, чыннан да, авылда – Апаста үсеп ята. Укытучы гаиләсендә үссә дә, ул да иркә бала түгел. Утын яру, печән чабу өше мәшәкать малайлар җилкәсендә инде ул. Ләкин Илдус та үз күңелен күрү җаен таба – Зөягә балыкка йөри. Бу дәрте гомерлек хобби булып калыр әле аның. Ә икенче дәрте – әни-әти уларын музыка мәктәбенә йөртергә бик тырышып караганнан соң, Илдус ул мәктәпне өч мәртәбә ташлаганнан соң тормышына килеп кергәне, ягъни биергә яратуы театрга китерер. Бию дигән бу шаукым тормышына Сәлимәне дә алып керер.

Мин бу урында вакыйгаларны ашыктырып, аларны тиз генә кавыштырып, теге Байдәүләт авылына алып кайтасым килә. Урал итәгендә җәйрәгән табигать тынлыгыннан Илдусның колаклары зеңләгән мәлне алар белән бергә кичерәсем, әле һаман җәйләү рәхәте онытылмаган табигый яшәеш ләззәтеннән алар белән бергә кинәнәсем, биектә-биектә очкан шоңкарларның канат җилпеме генә киңлекләр яулавын күзәтәсем килә. Ә менә Сәлимә белән Илдус янәшәсенә басып, әкияти Икар кебек, тау якасыннан Кояшка таба ыргылу кадәресе миннән булмастыр. Күптән түгел Камал театрының кече залында уйналган «Хафалы биюләр» дигән спектакльдә (Салават Юзеев, режиссер Рамил Гәрәев) Илдус Габдрахманов шундый очышны сынап карады. Сатирик спектакльне җанландырган бу очышлы биюләрне куючы хатыны Сәлимә Әминова булгангадыр, хафалы биюләрне хыялый, илаһи – яшьлектәге, төштәге биюләр кебек сыман башкарды (бу очракта биеде түгел) бугай ул.

Әле бу көннәргә, бу кичәгә кадәр яшисе бар. Сәлимәнең биюче булу турындагы хыялына канатны Казан куя. Башкорт дәүләт ансамбленә артистлар сайлап алу комиссиясе әгъзаларына кыз бик ошый. Зифа буйлы, пар толымлы, кара кашлы, кара күзле үтә дә чибәр кызыкай – бөгелә-сыгыла башкорт биюләрен биер өчен кем кирәк тә, ни кирәк тагын? Кирәк икән шул. Махсус белем кирәк! Андый белемне Казанда бирәләр. Мәдәният һәм сәнгать академиясендә якташы Нинель Давыт кызы Юлтыева – профессор! Дөньякүләм танылган балетмейстер! Шунда – Казанга бара Сәлимә! Уналты яшьлек кызның белем эстәү юлындагы беренче сәфәре уңышсыз төгәлләнә. Әмма ике елдан соң кыз дигәненә ирешә. Кыю йөрәкле очучы кызы лабаса ул!

Нинель ханым аны теге юлы ук хәтерләп калган икән. Һәм классик, һәм халыкчан биюләр биергә генә түгел, композиция кую серләренә дә өйрәнә ул Нинель ханымнан. Дәрестән буш вакытларда Сәлимә Җәлил исемендәге Татар опера һәм балет академия театрына йөри. Татар театрларын бар дип тә белми әле.

Укып бетергәнен Уфа көтә, диләр. Казаннан китәсе дә килми кебек кызның. Фатир хуҗасының – кырыс, әмма гадел табибә Рабига апаның тәрбиясеннән, ул пешергән ләззәтле татар ашларыннан һич аерыласы килми аның. Көннәрдән бер көнне остазы Фирдания ханым Садриева (Камал театрында ул үз кеше) кызга бер язу тоттыра. «Син Камал театрына барып, шушы кешеләрне күр әле. Сиңа анда әйбәт эш бар».

Кәгазьгә исемнәр язылган: Сәлимҗанов, Бикчәнтәев... Кемнәр алар?

«Бәхетең авылда синең», – дигән була Сәлимәгә багучы карчык.

Биетергә килгән кыз

Сәлимә Әминова сөйләгәннәрдән: «Баш режиссер бүлмәсендә киңәшмә бара иде бугай. Мин ишек шакыдым. «Керегез! – диделәр. – Ни йомыш, гүзәл туташ » – диде мыеклы бер абый. «Мин сезгә биюләр өйрәтергә килдем», – дим. Марсель абый, ул үзе булган икән, мыек астыннан гына елмаеп куйды да өстәл тирәсендә утырышкан кешеләргә: «Бу кыз сезне биетәчәк», – диде. Шуннан бирле биетәм инде. Хәер, алар мин килгәнче үк бии башлаганнар иде инде. Ә мин исә театр ишегеннән атлап керүгә үземне өемә кайтып кергән кебек хис иттем. Шул халәт миндә һаман яши».



PRESSA.RU

Балетмейстер сыйфатында Сәлимә Әминова исеме театр афишаларында иң беренче мәртәбә кайсы спектакльдә күренде икән? Хәер, ул биюләрен куйган спектакльләрне санап бетерерлек түгелдер. Алай да арада хәтергә тамга кебек уелып калганнары бар. Аларны театр әһеле генә түгел, тамашачы да хәтерли. Әйтик, «Боз астында дулкын» спектаклендә эскәмия өстендә Илдус Габдрахманов белән биегәннәрен. Әйе, шунда булды бугай шул Сәлимә Әминова исеменең премьерасы. Ул чагында талчыбыктай Сәлимә баш рольдәге Алсу Гайнуллина өчен биегән иде. Шул бию вакытында алар бер-берсенә икесе берьюлы гашыйк булмадылар микән әле?

Сәлимәнең сыгылмалы билен әлеРәк кенә армиядән кайткан яшь артист Илдус учлары шул чагында хәтерләп калгандыр.

Ә минем дөньяма Сәлимә исеме милли мәдәният үзәгенең «Казан» бию ансамбле өчен махсус куелган «Зәңгәр томан» биюенә бәйле рәвештә килеп кергән иде. Ул бию хәзергәчә классика булып кала. Һуштан яздырырлык матур табигать дөньясын кыз сәхнәдә үзе куйган биюләргә алып керде. Шуңа күрә ул куйган биюләрдә романтика белән лирика янәшә, аларда әкият яши. «Акчарлаклар» спектакле өчен куйган тангосын әле һаман гүзәллеккә, мәхәббәткә мәдхия сыман хәтерлибез.

«Эзләдем, бәгърем, сине» спектаклендәге биюләргә Туфан Миңнуллин зур эчтәлек салынуын теләгән иде, әйтелмәгән сүзләр биюләр аша әйтелер дип өметләнгән иде. Спектакльдә Олег Николаев тарафыннан бөек драматургның өметләрен акларлык биюләр куелып, Сәлимә белән Илдус анда икәүләп биеп, авторны бәхетле итә алганнар иде.

Читтән режиссер яки балетмейстер чакыру дигән нәрсә бар инде ул театрда. Читтән килгән режиссер «Минем исемем Кызыл» дигән спектакльдәге биюләрне куяр өчен балетмейстерны гына түгел, биючеләрне дә читтән чакырмакчы булган икән. Әмма Сәлимә Әминованың Камал театрындагы «биючеләрен» биетеп карагач, бу ниятеннән кайткан. «Баскетболист» спектакле (Мансур Гыйлаҗев) Марсель Сәлимҗанов белән бергә куелган соңгы спектакль булганга кадерле. Ул чагында өлкән артистларны биетү бик җиңел булмагандыр. Алай да мәшһүр режиссерның: «Булган бу, Сәлимә!» дигән хөкем карарын ишеткәнче биетте ул Нәҗибә апаларын, Ринат абыйларын. Театрда биек үкчәләре белән шыкшык басып, болан җәнлеге кебек горур, җитез йөреп торган бу кызны сагаеп та, кызыксынып та күзәткән чаклары артта калды өлкәннәрнең. Яшь буын аны иш күреп яратты. Һәм хәзер инде, барысы бергәләп, аның «кубызына бииләр». Хәер...

«Әллә безне биемәгән дисезме...» –

диеп, балет станогы янында ярты-шар көн тир түгүчеләрнең сукранган чаклары да булгандыр. Сәлимәнең күзенә карап әйтүчеләр дә булмаган түгелдер... Мин шулай уйлыйм. Чөнки Камал театры яшьләре шәп бииләр, тамашачы үлеп ярата торган «Шәкертләр биюе» кыз театрга килгәнче үк чыккан иде бит инде. Ә иң тәүге тапкыр тыпырдап бию – чечетка «Акбаш вакыйгасы» (Таҗи Гыйззәт) спектаклендә күренде. Бу вакытка инде Илдус Габдрахманов армиядән кайткан. Ә аңынчы Мәскәүдәге данлы Щепкин исемендәге югары училище дипломын алган. Диплом алганда аны бию дәресләре остазы Виктор Тейдор: «Синдә бик шәп балет биючесе югалган бит, егет», – дип озата. Чыннан да, татар егетләренең биюче даны Мәскәүдә дә таралып өлгерә. Казан да бу җәһәттән нык кайгырта. Театрдан щепкинчыларга ак күлмәкләр, кара лосинылар, балеткалар салынган посылкалар килеп кенә тора. Степ өчен махсус дагалы туфлиләрне алар үзләре, ничек кирәк шулай юнәтәләр. Долларларга! Димәк, чит илдән. Камал театры директоры Шамил Закиров бу ягын кайгырта да кайгырта инде: биесеннәр генә егетләр.

Театрга кайтуга Илдус Габдрахманов, Радик Бариев, Искәндәр Хәйруллин кебек бүген театрның алтын баганалары булган, күз өстендә каштай гаярь егетләр, бергә тупланып, бию номерлары өйрәнәләр, «Гаградагы кышкы кич» фильмында Аркадий Насыровның биегәнен күргәнннән соң, күңелне кытыклап торган «степ» белән ул елларда бик күпләр җенләнделәр, Илдусның бу бию җәһәтеннән кумиры, гомумән дә, американ Фред Астер булган икән. (Мәскәүнең «Иллюзион» кинозалында Фред Астерлы фильмнарга атна буе йөри Илдус. Атна буе Мәскәү урамнары буйлап степ биеп кайта.) «Степ» шаукымы кузгалуга Фәрит Бикчәнтәев 1995 елда Илдус Габдрахманов өчен махсус куйган «Биюче» (Лопе де Вега) спектакле дә зур этәргеч булгандыр, аннары шул ук режиссер труппаның яшьләре белән «Казан егетләре»н, «Тагын Казан егетләре»н (Мансур Гыйлаҗев) куйды. Егетләрнең бию имтиханын күрергә театрның олысы-кечесе җыела торган иде дип сөйлиләр – яшьлек дәрманын күзәтү үзе бер ләззәт бит!



Бию «шәкертләрнең» үзләренә дә ләззәтнең олысын бүләк итә. «Казанның меңьеллыгы алдыннан Парижга бардык, – дип сөйли Илдус. – Шәп кунакханәдәге люкс номерларда тордык. Тәрәзәдән карасаң, каршыда гына Эйфель манарасы! ЮНЕСКО оештырган меңьеллыкны презентацияләү чарасында «Шәкертләр биюе»н биеп кайттык. Әйе, ул бию безне Парижга алып барды. Европа безне болай да Нуриев, Мөхәммәдов аша биюче халык дип таный иде. Шулар исемлегенә менә без дә кушылдык».

Бию, күрәсең, артист шәхесен зурайта, амплуасын киңәйтә торган һөнәр, дөресрәге, сәләттер. Инде менә Сәлимә белән Илдус икәүләп Камал театрында яңа премьера тәкъдим иттеләр. Илгиз Зәйниевнең Тукай әсәренә нигезләнгән «Кәҗә, сарык һәм башкалар» хикәятен режиссер һәм хореограф буларак сәхнәгә куйганнар. Кайсы режиссер, кайсы хореограф – төгәл генә чикләр юк бугай. Хәер, театр җәмәгате аларны күптән инде бербөтен итеп кабул итә.

Өченче тизләнеш

Физикада шундый термин бар: җисем Җир орбитасына чыга алсын өчен ул икенче тизләнешкә ирешергә тиеш. Илдус Габдрахманов Камал театры орбитасында төрле жанрлардагы кырыклап спектакльдә һәм романтик («Ромео һәм Джульетта» – Ромео; «Казан егетләре» – Тукай), һәм лирик «Биюче» – Альдемаро; «Шулай булды шул» – Алмаз), һәм үтә реалистик («Телсез күке» – Севрюгин; «Илгизәр плюс Вера» – Илгизәр), һәм сатирик («Баскетболист» – Фәридун; «Хафалы биюләр – Руфин) рольләрдә уйнап, үзен киң диапазонлы сәхнә артисты итеп танытып өлгерде.

Артистларны, сәләтләренә карап, амплуаларын тәгаенләү бар. Әле генә санап үткән рольләрдәге төрләнеш – һушың китмәле. Сизгер хисле Ромео бар иде бит. Аннары Севрюгин. Бу персонажлар икесе ике котыптан. Артистның җавабы гади. «Севрюгинмы? Миңа дошман чырайларын уйнап карау ошый. Көнбатыш драматургиясенең романтик каһарманнарын уйнаганда сәхнәгә киң читле эшләпә киеп, гитара уйнап чыгу да ошый. (Бу урында бер эпизодны сөйләргә телем кычытып тора. Ромео искә төшкәннән бу. Щепкинга имтихан тотканда егеттән сорап куялар. Янәсе, синең Шекспирның кемлегеннән хәбәрең бармы? Җавап кызык: «Ник белмәскә: композитор!» Сүз «Ромео һәм Джульетта»ның – Илдус Габдрахмановка чын танылу китергән әсәрнең авторы турында бара.) Гомумән, артист һәрчак образга керергә әзер торырга тиеш. Менә бервакыт «Кара чикмән» спектакле барганда бер артистыбыз биектән егылып, өч җирдән кулын сындырды. Спектакльне өзәргә ярамый. Сәхнәгә мин чыктым. Тамашачы сизми дә калды». Әйе, Камал театрында кирәк икән каскадер, кирәк икән акробат була алырлык артистлар күп түгелдер. Әмма бар!

Инде егетебезнең икенче тизләнеш алганына да ун еллап гомер узган икән. Аның 2006 елда Россия экраннарына чыккан «Прорыв» (режиссер В. Лукин) фильмында ефрейтор Каюмовны уйнавын әйтәм. «Сарман буйларын» җырлап сугышка кергән татар малаен хәтерләп калды тамашачы. Шул фильм чыккач, Илдус Габдрахманов, хәтта, Мәскәү вахтерлары да танып ала торган артистка әйләнә.

Сәлимә Әминова да икенче тизләнештә. Балетмейстер сирәк һөнәр ул. Аны Әлмәт тә чакыра, Уфа да, Стәрлетамак театры да... Уфаның «Нур» театрында ун спектакльгә биюләр куйган. Гафури исемендәге башкорт драма театрында өч-дүрт спектакльнең биюләре аныкы. Әнкара театрында «Сүнгән йолдызлар»ны куяр өчен Тинчурин театрының сәнгать җитәкчесе Рәшит Заһидуллин белән бару – бер матур сәхифә. «Ике ай Төркиядә яшәдем. Телне төшенү кыен булмады. Алар шундый музыкаль халык. Европада да билгеле режиссер Леми Белгин да шул театрда эшли иде бит әле». Балетмейстер Сәлимә Әминова өчен махсус спектакль куелу тарихы да бар. «Әйдә барыйк, кызлар карыйк» (Разил Вәлиев пьесасы) – шуның бер мисалы.

Парлы бию

Көмеш туйга әле иртәрәк. Дистә ел буена иңгә-иң куеп иҗат иткәч, аларның барыбер кавышасылары театр әһеле өчен «чишелеше» ачык «спектакль» булып тоела. Теге – «Боз астында дулкын»да эскәмия өстендә биегән көннән алып халык туй көтә. Искиткеч хисле, җилкендергеч иде бит ул бию! Тик алар Илдус белән Сәлимәнең ни өчен загска өч мәртәбә гариза илтеп тә өченчесендә генә язылышып кайтуларын һаман аңлый алмыйлар. Ачам аларга бу серне: гастроль графигы һәр юлы эшне боза да куя. Ә алар: «Безнең өйләнешәсебез бар иде», – дип, театрны маршруттан алдырырга базмыйлар.

Бу гаиләдә хөрмәт бар, наз бар, иптәшлек бар.

Аларның театрдагы иҗади бергәлеге инде язмыш урталыгына әйләнгән. Алар белән тәмам башым катып бетте үземнең дә. Сәлимәнең кесә телефонына шалтыратам – Илдус ала; Илдусныкына шалтыратам – Сәлимә ала. Аптырагач, бер генә номерны калдырдым – барыбер бит. Аш-суны да бергә әзерлиләр икән: «Илдус тәмле пешерә», «Сәлимә тәмлерәк...» дигәннәрен тыңлап та тормадым. Аңладым мин аларны. Илдусның гримеркасындагы көзгеле өстәл астында кочаклашып яткан ике кием тимераякны күрүгә үк яшәү рәвешләрендә дә биюләрендәге кебек гармония барлыгын аңладым.

Баш белән муен мәсьәләсен куерту да урынсыз. Сәлимә чәчәкләргә су сипкәндә Илдус мунча бурый. Икәүләшеп попугай Клара өчен кайгыралар. Бергәләп музыка тыңлыйлар.

Әмма җебегәнлек, төчелек юк. Сәлимә Илдуска беркайчан да исеме белән эндәшми. «Куяным», «Песием» дә дими. Сәлимә өчен Илдусның исеме бер – «Ирем!» Кайда гына, кем янында гына булсалар да. Карагыз әле бу «ирем» сүзендә никадәр ныклык, ышанычлылык, ышану үзе һәм бердәнберлек бар!

Асия ЮНЫСОВА

PRESSA.RU



Юатма

Ренат Харис шигыре
Резеда Ахиярова музыкасы

Бүген көчле яңгыр булыр
сыман –
Тик торганда күздән яшь килә.
Болытларны узып
явармын күк,
Назлы итеп ялгыш дәш кенә.

Бер рәнҗеттең икән –
юатма да!
Болытка бир явып эрергә.
Аяз чакта гына йөрәгемә
Назлы сүзләр балкып керерләр.

Кушымта:

Кырыслыкка тарта бүген
күңел,
Изрәүдән кача горурлык.
Горурлыгын сакламаса кеше,
Язмышында куя борылып.

Камилә
ГЫЙЗЗӘТУЛЛИНА

БЕР ЯВАРМЫН КҮК







Мин әниемне төрлечә күз алдыма китереп карыйм. Менә ул концертында җырлый: «Минем белән бергә бәхетем туган, өлешемә тигән көмешем...» Аның яраткан җыры «Бәхет»! Әнгам Атнабаев шигыренә Алмаз Монасыйпов язган! Инструменталь ансамбленә дә «Бәхет» исемен куйды әни. «Җиңел килгән бәхет – бәхет түгел, эзләп тапкан бәхет кадерле» – җырдагы бу юллар инде әнинең шигаренә әйләнгән иде. Яки менә ул репетициядә. Инде ничәнче тапкыр кабатлый бу җырны: «Бөтен нәрсә сине хәтерләтә, бөтен нәрсә сине уйлата...» Мин үземчә кушылган булам: «Нишләтергә, дуслар, нишләтергә йөрәктәге ачы сагышны?..» Калейдоскоптагы кебек, җырлар әйләнә. Алар – телефонымда, аудиоязмаларда, үзем укыта торган Вафирә Гыйззәтуллина исемендәге 26 нчы музыка мәктәбе укучылары җырларында... «Керфегеңә тамармын мин», «Аккошлар», «Күңелдә ике яз», «Туй җыры», «Минем таныш өянкеләр», «Китмим әле яшьлегемнән»... Күп алар, күп. Соңгы арада, исем-акылым китеп, әнинең хатларын, көндәлекләрен укып утырам. Ул төннәр буе язып утыра иде бит. Үзе язган җырлар күпме!.. Вакыйгалар, кино кадрлары кебек, хәтеремдә ялтырапялтырап кабына. Туган авылы Камайга кайтуларыбыз... Кичә-концертларга баруларыбыз... Ул бик матур киенә иде. Беркайчан да ачык күлмәкләрдән йөрмәде. Чәчләре турыга ачылып, арттан җыеп куелган, түгәрәк алкалары бик тә килешле. Елмайганда бит очлары чокыраеп китә. Шундый чибәр үзе! Кызыл, ак, сары концерт күлмәкләре әле дә бөтен фасоннары белән күз алдымда... Мин бәби табу йортында Камил белән озак яттым, әни көненә икешәр мәртәбә яныма килә иде... Безнең өйдә Сибгат абый Хәким, Заһит ага Хәбибуллин, Фасил абый Әхмәтләр еш була. Җыр, шигърият, әдәбият турында сөйләшүләр, бәхәсләр тынып тормый... Рөстәм абый Яхин белән бер йортта, күрше подъездларда яшибез. Берчак Рөстәм абый әнигә шалтырата: «Вафирә, мине бикләп киткәннәр. Аска төш, нотаны балконнан ыргытам», – ди. «Нигә соң йөрәк шулай ярсулы?» дигән романс иде ул. Рөстәм абыйның соңгы җыры булган... Язмаларда да шул – горур, тәвәккәл, туры сүзле, ачык йөзле, гаделлек өчен җан аткан, кешеләргә гел ярдәм итәргә ашыккан, халкым, милләтем дип өзгәләнгән, гомер буе дөреслек эзләп йөргән, татар җыр-моңына сусаган халык янына концертлар белән чыгып киткән Вафирә Гыйззәтуллина, минем әни ярылып ята. Вафирә исеменең мәгънәсе дә киң күңелле дигәнне аңлата бит! Аңа рәхмәт әйтеп, Болгария, Төркия, Америкалардан хатлар килә. Концертларында елап утырган апаларны күргәнем бар – йөрәкләренә үтәрлек итеп җырлый иде ул.

Һәр җырын тавышы, йөз чалымнары, хәрәкәтләре белән хәтерлим.

Менә «Юатма» җыры. Юк, ул җыр түгел, романс. Шунысы да бар, аны Ренат Харис белән Резеда Ахиярова әни өчен махсус язганнар. Бүгенгедәй күз алдымда: әни зал бүлмәсенең уртасына ук барып басты да, үзен сәхнәдә кебек хис итеп, ярсып-хисләнеп, ниндидер театраль образга кереп, тирән кичереш белән җырлый башлады. Кинәт борылып, кулы белән «тамаша залына», «берәүгә» ишарә ясап: «Бер рәнҗеттең икән – юатма да!» – дип, үпкә сүзләрен әйтте дә тагын талгын ноталарга күчте. Мин, 15 яшьлек кыз, аңа пианинода уйнап утырдым. Әүхәдиев исемендәге музыка училищесында укып йөргән чакларым иде ул. Бу романсны икәүләп ике тавышка да җырлап караганыбыз булды. «Бу – минем җыр! Миңа туры килә!» – дигән иде әни. Ул чакта мин башкачарак кабул иттем: «Әни көзне ярата. Бу җыр да – көзгә. Моңсулык, яңгырлар, күз яшьләре...» Хәзер аны үзем дә еш җырлыйм.

Җыр язылу турында Резеда Ахиярова үзе болай сөйләгән иде:

– Бу җыр 1983 елда язылды. Ренат Харис белән бергә иҗат иткән иң беренче җырыбыз ул. Вафирә Гыйззәтуллинаны күздә тотып, махсус аның өчен яздык. Аның тавыш тембры, сәхнәдә үз-үзен тотышы, башкару манерасы, тирән кичерешләрне оста итеп бирә белүе мине гел сокландыра иде. Минем әле яңа гына җырлар яза башлаган чак. Вафирәне якыннан белмим дә әле. Ләкин минем өчен ул идеалдагы татар хатын-кызы булып тоела. Озын буйлы, матур гәүдәле, зәвыклы итеп киенә, ягымлы... Бүгенгедәй күз алдымда: Ренат абыйның шигырен һәм нота кәгазьләремне күтәреп, филармониягә, Вафирә Гыйззәтуллина янына чыгып йөгердем. Ошатырмы? Ничек кабул итәр? Үзен күргәч, бөтен икеле-микеле уйларым юкка чыкты. Ошатты җырыбызны Вафирә. «Нәкъ минем күңелдәгене ачып салгансыз! Каян белдегез?» – ди. Хәтерлим, кышкы салкын көн иде. Актерлар йортында Ренат Харисның иҗат кичәсе бара. Шунда беренче тапкыр Вафирә Гыйззәтуллина «Юатма»ны җырлады. Мин фортепианода уйныйм, үзем дулкынланам. Җырчының лирик сопраносы бар дөньяны сихерли сыман.

Аннары без романсны радиога барып яздырдык. Вафирә Рөстәм Үтәй җитәкчелегендәге уен кораллары ансамбле белән дә җырлады аны. «Юатма»ны төрле авылларда, шәһәрләрдә яңгыратты. Иҗади дуслык шушы җырдан башланды...

Резеда Ахияровадан соң Ренат Харис фикерен дә ишетәсем килде. Ул әниемне зур шәхес, чорыбызның күренекле эстрада җырчысы дип атады: «Резеда Вафирә тормышындагы берәр вакыйгадан хәбәрдар булгандыр, бәлки? Миңа никтер шулай тоелды. Шул дулкында җыр тексты туды.... Соңыннан Вафирә рәхмәт әйтте. Җаныма туры килә торган җыр язгансыз диде».

...Менә шундый бер истәлек. Бу романс, әлбәттә, сирәгрәк яңгырый. Ләкин ул миңа бик кадерле. Мин аны тыңлаганда, әнием кичергәннәрне, аның язмышындагы борылышларны, күзләреннән яшь китерерлек әчке киеренкелекне, көчле хатын-кыз холкы белән янәшә менә явам, менә түгеләм дип торган мөлдерәмә күңелен тойгандай булам.

Фото: автор архивыннан

PRESSA.RU



Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының ЗАГС идарәсе









Фото: Ксения Богданова

БАТЫРЛЫК ДӘРЕСЕ



Мәдинә АВЗАЛОВА

ЕГЕРМЕ ӨЧ ЯШЕНДӘ АЯКСЫЗ КАЛЫП ТА ГӨРЛӘТЕП ТОРМЫШ АЛЫП БАРГАН БУ ХАНЫМГА БӨТЕН АВЫЛ СОКЛАНА.

Җәйнең соңгы көне... 31 август төне якынлашып килә. 322 хуҗалыклы Адав-Толымбай авылын дер селкетеп торган ындыр табагында да тиздән эш тынар. Игеннәрне урнаштырып бетергәч, халык, дәррәү килеп, урманга юл алыр. Якында – кул сузымында гына бит аларның урманнары. Ике урманы, «Алмакай» дип аталган балыклы күле, җәен чәчәккә күмелгән яшел аланнары бу якларны гаҗәеп итә. Элек бу авылның исеме «Сөеш» дип аталган. Нигә үзгәрткәннәрдер?! Шундый матур исем югыйсә. Адау исемле бер чуаш белән Толымбай исемле бер татар килеп урнашкан да, шуннан инде ул Адав-Толымбайга әйләнгән. Шулай дип сөйлиләр.

Фирдүс тагын тәрәзә янына килде. Урамга күз төшерде. Яңгырлап тора әле. Кара төнгәчә нишләп йөри инде ул ындыр табагында?! «Иртәгә 1 сентябрь. Мәктәпкә барасың бар, аз булса да ял итәр идең...» – дип тә карады хатынына. Юк бит, аның үз сүзе – сүз: «Эшне төгәлләп кайтам!» Озаклады... Ир пошаманга төште. Йокларга дип җыенып йөргәндә, каты итеп ишек шакыдылар. Нәрсә бу? Венера дисәң, алай кыланмас, үзе ачып керер. Ишекне ачып җибәрүгә, ашыгып килүдәнме, ирештерәсе хәбәреннәнме, тыны кысылган авылдашы: «Венераны хастаханәгә алып киттеләр», – дип кенә әйтә алды.

Ул хастаханәгә барып җиткәндә, хатыны операция өстәлендә иде инде. Җентекләп сораштырырга вакыты юк иде аның. Әмма Фирдүс бер нәрсәне яхшы аңлады: Кутдусовлар гаиләсенә зур фаҗига килгән. Авылдашының: «Ток бәргән, аңын җуйган килеш аягын кистергән...» – дип әйткән өзек-өзек сүзләре йөрәгенә үтеп, күңелен әйләндереп ташлады. Түземсезләнеп, хирургның операциядән чыкканын көтте. Ә ул чыкты да: «Хәле авыр», – гына диде дә, кабинетына кереп югалды.

Аңына килгәч, ирне хатыны янына керттеләр. Тездән югары киселгән аягын ак җәймә белән каплап, тын калган хатынына Фирдүс яратып та, кызганып та карады. Шушы мәлдә күңелендә аңа карата булган бөтен җылы-назлы сүзен, яратуын бер генә җөмлә белән әйтеп бирде: «Мин сине беркайчан да ташламам!» Хатын, берни булмагандай, сизелер-сизелмәс елмаеп куйды. Ир барына да әзер иде: төшенкелеккә бирелсә дә, берни кыла алмассың. 23 кенә яшь бит әле аңа! Алма кебек чагы... «Минем өчен борчылма, барысы да әйбәт булыр, яме», – диде ул ирен гаҗәпкә калдырып. Бу минутта ул үзен түгел, ирен юата иде.

«Һәр көнемне куанып каршылыйм»

Туар көннәрнең, сызылып аткан ал таңнарның, хәтта әнә шул бетмәс-төкәнмәс эш-мәшәкатьләрнең кадерен-тәмен олы сынау үткән, яшәү белән үлем арасында тартышкан кеше генә бөтен җаны-тәне белән аңлыйдыр, тормышның, яшәүнең Аллаһы Тәгалә тарафыннан бирелгән зур кыйммәт-хәзинә икәнен төшенәдер. Аның белән сөйләшү шундый уйларга этәрә.

Без – Венера белән Фирдүс Кутдусовлар яшәгән Буа районының Толымбай авылында. Өйләренә аяк басуга ук тәнгә бер рәхәтлек иңә, җанга тынычлык йөгереп үтә. Биредә эчкерсез, чиста-якты күңелле кешеләр яшәвен шуннан гына бел инде син!

– Кайнанам вафатыннан соң әниемнең өенә күчендек. Бу – минем туган нигезем. Фирдүс улларыбыз белән шушы йортны өр-яңадан күтәрде, мунчасын да өй түбәсе астына кертеп салдылар. Кулларыннан килә анысы... Безнең бүлмәдән бүлмәгә кереп, чисталыкка-пөхтәлеккә хәйран калып йөрүебезне күреп, Венера шулай ди. Хәзер авыл өйләре дә шәһәрнекеннән ким түгел шул: газы да кертелгән, суы да... Кирәк-яракка да тилмереп торыш юк: үз кибетләре, менә дигән мәдәният сарае, урта мәктәбе, аның янәшәсендә генә балалар бакчасы. Боларын да ул – гомерен балалар укытуга багышлаган мөхтәрәм, абруйлы укытучы Венера Хәбир кызы Кутдусова әйтә.

Мәктәп хәлләре, укучылары турында ул сәгатьләр буе сөйләргә дә әзер. Тик анысы соңыннан... Күбрәк үзе, гаиләсе турында беләсе килә. Әңгәмәгә керешүгә үк ул безне кисәтеп куя: «Үткәннәргә борылып карарга яратмыйм. Мин иртәгәсе көн белән яшим». Аңлашыла, әлбәттә: тормышының иң авыр, зәһәр елларын искә төшерүе җиңел түгел аңа. Ләкин, «ул вакытлар артта калды», дисә дә, юк юк та, кызганычка каршы, сиздертә шул ул. Протезлы аягы белән көнозын аяк өстендә булу, йөзеннән елмаюны җибәрмичә, гөрләп торган тормыш белән яшәүнең бәһасе күпмегә төшүен ул үзе генә беләдер. Ләкин ул зарланмый. Без аның авызыннан бер мәртәбә дә «аһ» дигән сүз ишетмәдек. «Күзләрем күрә, үз-үземне йөртәм, шөкер, урынга калмаган бит әле», – ди ул үз-үзен тынычландыргандай. Гади генә итеп әйткән шушы сүзләр артында нинди тирән мәгънә ятуына тора-тора төшенәбез.

«Барысын да үзем эшләргә әзер. Янымда гына басып торсын», – ди ире, хатынына яратып карап.

«Таянычым син...»

Тормышта әллә нинди хәлләр була: кемнең ире һәлакәткә очрап урынга кала, кемнең хатыны менә шулай фаҗигагә юлыга. Берәү дә иртәгә сиңа ни киләсен, сине ни көтәсен белми. Иртәгә шуны эшлим, моны эшлим, дип, язмышны көлдермә син. Ул барыбер үзенекен кылыр. Шундый хәлдә беленә инде кемнең кем икәне. Дөресен әйтик, сынау килгәндә, күбрәк ирләр сыгылып төшә, кыенлыктан чыгу юлын урын өстендә яткан хатынын, йә булмаса, гарип баласын ташлап китүдә күрә. «Мине ташлар инде» дигән уй килдеме икән кайчан да бер Венераның башына?! Үзе ул: «Юк», – ди. Ай-һай, шулаймы икән? Ирләргә ышанма, Иделгә таянма, дип тикмәгә генә әйтмиләрдер инде. Ничек булса, булгандыр, әмма ул иренең вәгъдәсенә

PRESSA.RU

ышана. Чөнки белә: Фирдүс ул күп сөйли торганнардан да, кеше артында гайбәт сатып йөри торганнардан да түгел. Ул – аның бердәнбере. Ул – аның яшьли, мәктәп елларыннан ук яратып йөргән сөеклесе. Ничек инде хәзер генә, аның ярдәменә шундый-шундый кирәк чагында гына ул аны калдырып китсен?!

– Мин аңа үземә ышангандай ышанам, – ди Венера. – Ул – чын ир-егет! Ул – минем терәгем, таянычым. Ул минем – ике аягым, ике кулым. Ул тәрәзә өлгеләренә кадәр элә, идәннәргә кадәр юа. Үзе – Мәдәният сарае директоры, үзе – җырчы, алмаган дипломы калмады инде. Яраталар үзен, әйеме, Фирдүс?! Ире аңа күзләрен тутырып бер карап куя да, елмаеп җибәрә. «Нәрсәсе бар аның...» – ди ул бу темага сөйләшүне тизрәк туктатырга теләп. – Без аның белән биш ел йөрдек, – дип дәвам итә сүзен ханым. – Яшь арабыз шактый – 12 ел. Ул миңа тәкъдим ясаганда: «Әйдә, тизрәк өйләнешик инде, картаям бит», – дип көлдерде. Кияүгә 19 яшемдә чыктым. Казан педагогика институтының татар теле һәм әдәбияты факультетында укып йөргән, укытучы булам, дип хыялланган чагым иде. Читтән торып укуга күчтем. Ярата идем. Ялындырып тормадым, шундук кияүгә чыгарга риза булдым. Аның әйбәт кеше икәнен күңелем тойгандыр. Бергә тормыш корып җибәрүгебезгә ничәмәничә еллар үтте, ныгытып ачуланышкан, үпкәләшеп, дәшмичә йөргән чакларны хәтерләмим дә. Аңа аз гына каршы әйтә башладыңмы, гадәте – урамга чыгып китә дә, бераз йөреп, тынычланып керә. Кычкырганын, каты сүз әйткәнен ишеткәнем юк.

Ул, сөйләмим дисә дә, аягын кистергәннән соң, айдан артык хастаханәдә ятуы, аннан ире белән Казанга – протез ясатырга баруы, аннан, бер ел дигәндә, эшкә чыгуы, аннан тагын – шул аягы белән икенче мәртәбә операциягә ятуы турында сөйләп ала.

Аның турында: «Йөзеннән елмаю китми. Ул шундый көчле кеше», – дип сөйлиләр. Яшь аралаш елмаюның ни икәнен белсәләр икән...

«Тормышны шундый ярата ул...»

– Әйе, протез ясатырга икәү бардык, – дип, сүзне элдереп алып китә Фирдүс. – Безнең кебекләр күп иде анда: Кайсы стенага барып янтайган, кайсы эскәмиядә чыраен сытып утыра. Атмосфера шундый авыр... карап торган кешегә... газап инде. Ә минем хатынны күрсәгез! Йөзе кояш сыман балкый, кәефе шәп, үзе бертуктаусыз әле берсе, әле икенчесе белән гәп куертып ала. Әйтерсең, боларның берсе дә аңа кагылмый. «Нишлисең, – дим, – ник тиле сыман гел елмаеп, май чәчәге сыман балкып утырасың?» Ул әйткәнемә бик гаҗәпләнде шул чагында. Шундый ул, бирешми, төшенкелеккә бирелми, хәсрәткә чумып утырмый. Бөтен җирдә ул булырга, бөтен эштә бары ул катнашырга тиеш! Югыйсә ансыз дөнья җимерелә. Үзе оештырган «Сәйяр» драма түгәрәгенә, «Сердәш» фольклор ансамбленә йөри. Концертлар алып бара. «Башка кеше беткәнмени?» – дим. «Юк, үзем алып барам!» Үзе шундый комплекссыз булгач, башкалар да аңа карата шундый. Минемчә, аның бер аягының юклыгын искә алучы кеше юк та хәзер.

Венера Кутдусова Адав-Толымбай авылында онытылып барган йолаларга канат куючы да. Ул карга боткалары, «май уны» дип аталган бәйрәмнәр яңадан тормышка кайта, халык күңеленә керә бара. Элек, авыл кешеләре сөйләвенчә, Зөя буенда өч алан булган. Шуның берсендә – чуашлар, икенчесендә – татарлар, өченчесендә балачага ял иткән, күңел ачкан. Бу бәйрәм майның уннарында үткәрелә торган булган. Шуңа «май уны» дип аталган да. «Мондый урманнар, мондый күлләр беркайда да юк, гөмбә, җиләк җыярга, балык тотарга безгә килегез!» – ди Венера ханым. Ә үзенең күзләреннән бөтен җиһанны кочып алырдай нур агыла.

– Гөмбә дә җыя, җиләккә дә йөри, – дип өстисе итә ире, хатынын мактап. Гәрчә шундый хәлдә моны ничек эшләргә мөмкин булуын күз алдына да китерә алмасак та, без дә аны мактап куябыз. Менә бит ничек! Инвалидларга уңайлыклар тудыру турында сөйләгән арада, инвалид бу мөмкинлекләрне үзе таба, тормышка үзе җайлаша. Теләк белән ихтыяр көче генә булсын. Венера ханым безнең белән килешә. «Шулай, – ди ул, – бераз уйланып торгач, – бөгелгәнне тагын да бөгәргә әзер торучылар күп шул. Мин үзем көн саен иртәгәсе көн өчен план корам. Шуны гамәлгә ашырмыйча туктамыйм, Тешләсәм, ычкындырмыйм, кыскасы.

– Йә, тагын кемне, нәрсәне тешләргә җыенасыз? – дибез, көлеп җибәреп.

– Иртәгә тернәкләндерүнең индивидуаль программасын алырга барам. Ансыз миңа протез бирмиләр.

– Безнең протезлар инде, Ходаем. Аяклар авыртадыр?

– Юк-юк, – ди ул, үзен кызганганны өнәп бетермичә, – шулай булып торса, мең рәхмәт...

Хак әйтәләр: ханым үзен кызганганны да, кимсеткәнне дә яратмый. Бәлкем, шуңадыр да ул икенче балага узгач, төшертү турында башына да китереп карамый. «Табам булгач, табам». Һәм таба да. Тагын малай алып кайта ул. Илгиз дип исем кушалар. Кече уллары тора-бара әниләренең уң кулына әверелә. Әле 3 нче сыйныфта гына укый торган бәләкәй малай «ике аяклы аты» – велосипедына атланып көн саен сөт ташый. Малайны телевизор белән бүләклиләр. «Әле дә саклыйбыз, чыгарып ыргытырга кул бармый», – ди әнисе. каршыбызда эшләп торган зур экранга күрсәтеп. Олы уллары Илдус та, Илгиз дә – Казанда. Илдусның инде үзенең ике улы Эмиль белән Камил үсеп килә. Ә Илгиз – реклама фирмасында. Әти-әнисе алар өчен куанып бетә алмый: «Тәртиплеләр, авылга бик еш кайталар, безгә булышалар», – ди Венера ханым, горурланып. Ә без аңа карап горурланабыз: бар бит дөньяда көчле, батыр хатыннар!

– Тормышны ярата ул! – дип дәвам итә ире Фирдүс. – Хәсрәт-борчуларсыз дөнья бармый. Ул берәүне дә

читләтеп үтми. Хатыным шундый бәлагә тарыгач, кайберәүләр: «Гарип белән нужарма, аерыл», – диделәр. Мин әйттем аның ише хәсрәт-киңәшчеләргә: «Шундый чакта ташлап китсәм, мин беркайчан да бәхетле була алмам», – дидем. Бүген үземне бәхетле саныйм. Барысын да үзем эшләргә әзер, янымда гына басып торсын! Бакчадагы эшләр дә – минеке, тавык-чебешләр, каз-үрдәкләр карау да... Берсенә дә авырсынмыйм. Тик янымда гына булсын. Шулай ди дә: «Күктән йолдыз чүпләп бүләк итмә / Ялтырый да, оча кичләрен / Таң атканда янар соңгы йолдыз / Син дә сүнсәң, мин соң нишләрем?» – дип, күкрәктән чыккан йомшак тавыш белән җырлап җибәрә. – Аның белән рәхәт миңа, – ди Фирдүс җырлавыннан туктап. – Ул мине дә яшәргә өйрәтә.

«Тешләсәм, өзмичә туктамыйм» дигәннән... Венера ханым үзе белән булган бер кызыклы вакыйганы искә төшереп ала. Моңа инде күп вакытлар узган. Бүген аларның өйләре өр-яңа булып, әллә кайдан балкып утыра. Ә аңарчы... ремонт башланган көннәрдә ярдәм сорап, ул кайларга гына мөрәҗәгать итми. «Акчалата сорама, әйберләтә сора», дип киңәш итә акыллы башлар. Шуннан ханым ком, такта, кирпеч, гравий кирәк, дип, өч төзелеш учреждениесенең бусагасын таптый башлый. Ә аңа вәгъдә бирәләр дә, кайтарып җибәрәләр. Шуннан ул нишли, дисезме? Төзү материалларына китүче КамАЗларның номерларын язып ала да, Тәтеш юлына чыгып баса. Юлда күренгән бер машинаны, материал алуга бирелгән кәгазен күрсәтеп, өйләренә таба бора. «Яртысы – өйгә, яртысы – юл төзү идарәсенә», – дип көлә хәзер ул вакытларны искә төшереп Венера ханым. Заманында Венера машина да йөрткән әле. Инвалид буларак, аңа машинаны социаль яклау бүлеге алып биргән. «Искерде инде, йөреп булмый», – дип офтана ул.

Укучылар өчен үрнәк ул

– Мәктәпкә ничек йөрисез? Шактый ерак күренә бит, – дибез.

– Әйдәгез, мәктәпне күрсәтәм, – ди ул безгә, – һәм шундук кызу-кызу җыена башлый. Аның артыннан көчкә өлгерәбез.

Мәктәп белән өй арасы шактый ерак булып чыкты. Машина белән йөргәндә әле бер хәл. Ә менә протезлы аягың белән җәяү йөри башласаңмы?

– Кайчак Фирдүс абый, ә кайчак үзем дә машина белән алып кайтып куям, – дип сүзгә кушыла ике туган энесенең хатыны, мәктәптә тәрбия эшләре буенча завуч Диләрә Шәрипова. – Ә кайвакыт җәяүләп китә.

«Көчле кеше ул! Яхшы белгеч тә, – ди мәктәп директоры Фирдүс Җаббаров Венера ханымны күргүгә елмаеп җибәреп. – Бер сүз белән әйткәндә, ул – безнең өчен батырлык үрнәге».

Венераның әнисе Флера апа әйтмешли, «кечкенәдән бер чиләк бәрәңге күтәрәсе урынга, ике чиләк бәрәңге күтәреп үскәнгәме», ул сынатмый, үзе әйтмешли, гел алга карап яшәвен дәвам итә. Венера Хәбир кызы Кутдусованың укучыларына биргән дәресләре гади дәрес кенә түгел, тормыш дәресләре – батырлык дәресләре ул.

СОЦИАЛЬ ӨЛКӘДӘ ҮЗГӘРЕШЛӘР

Быелның 1 гыйнварыннан инвалидларны тернәкләндерү өчен кирәкле техник әйберләр белән тәэмин итү, санаторий-курортларга юллама бирү һәм анда бару-кайту чыгымнарын түләү гамәлләре Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгыннан Социаль иминият фондына күчерелә. Калган барлык социаль гарантияләр элеккечә үк Социаль яклау министрлыгы карамагында кала. Җаваплы ведомство үзгәрсә дә, инвалидларны тернәкләндерү өчен кирәкле техник әйберләр белән тәэмин итү тәртибе, аларны алу өчен тапшырыла торган документлар җыелмасы үзгәрми, фәкать халыкны кабул итү адреслары гына үзгәрә дә, телефон номерлары гына үзгәрә.

Фондка Социаль яклау министрлыгыннан 80 000 гариза күчкән. Хәзер фонд тернәкләнү өчен мөһим булган техник җиһазларга, санаторий-курорт дәвасына мохтаҗ гражданнарның тулы исемлеген булдыру, андый гражданнардан гаризалар кабул итү белән мәшгуль. Инвалидларны тернәкләндерү өчен кирәкле техник әйберләргә, санаторий-курорт дәвасына мохтаҗ кешеләр үзләренең бу исемлектә тору-тормауларын Социаль иминият фондына шалтыратып белешә ала.

Санаторий-курорт дәвасына мохтаҗ булып та, үз чиратын көтеп ала алмаучыларның саны ел саен арта. Бүгенге көндә 50 меңләп кеше санаторийда дәвалану өчен үз чиратын көтә. Бу максаттан 2016 елда 132 миллион сум акча бүлеп бирелгән. Бу исә санаторийларда быел 7 мең кеше генә сәламәтлеген ныгыта ала дигән сүз.

Урын өстендә ятып авыручылар өчен кирәкле махсус урын-җир җәймәләре, подгузниклар, бәвел һәм тәрәт җыйгычларга килгәндә, узган ел алынмый калынган әйберләр быелгысына өстәп бирелмәячәк. Әгәр дә кеше аларны үз акчасына сатып алып, чеклары сакланган булса, ул чыгымнар, иң соңгы чек бәясеннән чыгып компенсацияләнә. Әгәр дә инде сез чыгымнарыгызны компенсацияләүне сорап 2015 елда гариза язган булсагыз, хәзер тагын бер гариза яза аласыз. Ул очракта компенсация күләме 10-15% ка зуррак булачак. Бу бәяләрнең гел үсеп торуы белән бәйле. Хәзергә фонд 2016 елның беренче яртыеллыгы өчен подгузниклар, бәвел һәм тәрәт җыйгычлар сатып алу белән мәшгуль. Бу әйберләр инвалидларга март урталарында килеп ирешергә тиеш.



Мөрәҗәгать итү өчен адресларын, телефоннарын сайтыбызда таба аласыз. Анда инвалидларны тернәкләндерү өчен кирәкле техник җиһазлар һәм җайланмаларның федераль исемлеге дә бар.

PRESSA.RU

16+

УРМАЙЛАР — БЕР ГАЛӘМНӘН!



Фәрит ГЫЙБАТДИНОВ, Чуашстан Республикасы татарларының милли-мәдәни мохтарияте рәисе, Комсомол районы сәнгать мәктәбе директоры. Өйләнгән; гаилә стажы — 32 ел; өч бала атасы.

Ир-ат һәм хатын-кыз. Бер үк галәмгә без бит очраклы гына эләкмәгән... Шулай булгач, нигә соң бер-беребезне күп вакыт аңламыйбыз? Гамәлләребезне, теге яки бу адымыбызны, әйткән сүзләребезне... Үзара тартылуны «җиңеп», арага каршылыклар керә дә куя...
Ә ир-атлар үзләре бу хакта ни уйлый икән? Сүзне аларга бирик.

1 Иң элек хатын-кызда нәрсәгә игътибар итәсез: киеменә, буй-сынына, күзләренә, чәченә...

— Үзеңә якын кешене ниндидер бер эчке тоемлау белән сизәсең бугай. Шул кешегә күзең төшкән минуттан аның чәче дә, исе дә, күзләренең төсе дә, холкы, кыланмышлары, үз-үзен тотышы, атлау-йөрүләре, гәүдә-кыяфәте — барысы да сиңа ошый башлый. Уйларыңны биләп ала.

2 Хатын-кызның кайсы сыйфатларын гафу итәргә була?

— Шәхсән мин үзем кешеләрне, бигрәк тә хатын-кызларны, ни кылуларына карамастан (хәтта үземне нык рәнҗеткән булсалар да), гафу итәргә тырышам. Холкым шундый — берәүгә дә озак ачуланып йөри алмыйм, тиз кичерәм. Әйткәнемчә, хатын-кызларны — бигрәк тә.

3 Хатын-кызлар икегә бүленә: ир-атны илһамландыручы алиһәләр һәм өйдә аның өчен комфорт тудыручылар...

— Кем бүлгән хатын-кызны икегә?! Нинди генә булмасын, хатын-кыз иң элек — ана ул. Ананың, ягъни хатын-кызның төп эше, вазыйфасы бөтен гаиләгә, тормыш иптәшенә, балаларына алиһә булу. Ә инде ир-атны илһамландыручы алиһә ролен генә үтәү — анысы кәсепкә керә. Хатын-кызга табигатьтән килгән сынау — азгынлык чире бу.

4 Хатыныгызга ничек тәкъдим ясаганны хәтерлисезме?

— Безнең якларда өйләнергә тәкъдим ясап тормыйлар. Гадәттә, Урмайда егетләр кызны урлап кына кайта. «Ишеттегезме, Абдул Фәрите тенә үләнгән», — дип сүз тарала аннан икенче көнне... Мин 22 яшемдә өйләндем, тормыш иптәшем Вагыйзәгә ул вакытта нибары 18 яшь иде. Хәзер кызлар унсигездә бала гына сыман әле, ә ул чакта 18-19 яшендә кияүгә чыгар өчен вакытның нәкъ үзе иде. Мин өйләнергә теләгәндә Вагыйзәгә күз салучылар тагын бар иде. Өч-дүрт кандидат! Вагыйзә бездән ерак тормый, мин аны карап үстердем дисәм дә була. Гаиләләребез дә дуслар, әти-әниләр күрше булып, бер-беренә гел яхшы мөнәсәбәттә яшәде. Җаен туры китереп, берничә тапкыр Вагыйзә белән сөйләштем дә тәвәккәлләдем... Ул көнне клубта һинд киносы күрсәттеләр. Без, дус егетләр белән җыелып, күзем төшкән кызымның кинодан чыкканын көтеп тордык. Калганы бик тиз булды: бездә егетләр үз эшләрен белә! Мәдәният йортыннан илле метр читкә атлауга, Вагыйзәне, ике канатыннан тотып, минем нигезгә җилтерәтеп алып кайтып та куйдык. Әллә ни ризасызлыгын белдертмәде анысы, үзе үк чаптырып кайтты. Икенче көнне бертуган апам аның әтиләренә (минем бабайларга була инде): «Кызыгыз бездә», — дип әйтергә китте. Анда инде хәбәрдарлар: иртән үк белен-коймаклар пешкән, әйтергә килүчене кадерләп каршы алганнар, яхшы хәбәр китергән өчен бүләккә йон яулык бүләк иткәннәр... Димәк, ике як та риза, туй йолаларын башласаң да була.

Икенче көнне әниләр кыз өенә барып килешеп кайттылар. Аннан соң гына яшь кияү булып бабайларга хатыным белән мин киттем. Бер айдан соң туй ясадык. Туй бетүгә Казанга — мәдәният институтына сессиягә киттем...

5 Хатыннары ирләреннән күбрәк мал тапкан гаиләләр бар. Ир кеше бу очракта үзен ничек тотарга тиеш?

— Безнең икебезгә дә күпләп мал табу бәхете тимәде. Үзем гомер буе бюджет сферасында эшләдем, соңгы егерме елда тормыш иптәшем дә — мәдәният өлкәсендә. «Аягыбызны юрганыбызга күрә сузабыз»: Аллага шөкер, дип, гомер кичерәбез, эшләп тапкан малыбызны бәрәкәт белән тотып, мул итеп көн итәргә тырышабыз. Безнең Урмай кебек авылда акчасыз яшәп булмый. Чуашстанның татар авылларында гореф-гадәтләр әле дә бөтен нечкәлекләре белән саклана: туйлар, бәби туйлары, дини бәйрәмнәрне кесәң калын булмаса үткәреп кара?! Башка-

лардан ким итмичә, калышмыйча. Әйе, кешечә яшим дисәң, бездә күбрәк дәртләнергә туры килә: бигрәк тә йорт-җир корганда, төзелеш эшләре башлаганда.

Күпләп мал тапкан хатыннар Урмайда да бар барын, әмма мин аларның ирләрен бөтенләй мескен хәлдә димәс идем. Кайсыбер сорауларда хатын-кызлар өстенлек итсә дә... Ирләренә шул хәл ошый икән, әйдә, яши бирсеннәр.

6 Гашыйк булуын хатын-кыз үзе белдерүгә ничек карыйсыз?

– Мондый очракта үзеңне башкалар урынына куеп карау кирәк... Ходай адәм балаларын төрлечә яраткан. Үзенең гашыйк икәнен уңга-сулга белгертеп йөрү кемгәдер берни тормый. Ә кайсыбер ирләр гашыйк булганнарын сөйгәннәренә гомердә дә башлап әйтә алмый. Нишләп шундыйларга хатын-кызлар үзләре булышмаска тиеш, ди?

7 Хатын-кызларны ир-атларда иң беренче чиратта нәрсә җәлеп итә дип саныйсыз?

– Сүз дә юк, хатын-кызлар матур, яшь, чибәр, шул ук вакытта бай егетләрне яраталардыр. Гаилә кору өчен, беренче чиратта, ышанычлы, өметле, таянырдай ир-атларны сайлыйлардыр. Авыл кешесе, киләчәген күз алдына китерергә теләсә, күзе, күңеле төшкән ярының нәселенә игътибар итә: «чиләгенә күрә капкачы»н туры китерергә тырыша. Ә мәхәббәт... Ул башта әле булмаска да мөмкин, әмма соңрак бу хис, һичшиксез, ике арада кабыначак.

8 Хатын-кызларның үзегезнең кайсы якларыгызга игътибар итүне көтәсез?

– Минем гомерем халык алдында үтте. Шуларның утыз биш елы – мәдәният өлкәсендә. Сәнгать мәктәбен җитәкли башлавыма егерме сигез ел. Чуашстан Республикасы татарларының милли хәрәкәте оешмасы лидеры булуыма да егерме елдан артык. Игътибар җитәрлек! Олы апалар, тыңдаучыларым, яшүсмер кызлар, туташлар... Аларның һәркайсыннан үземнең дәрәҗәмә күрә уңай игътибар тоям һәм һәрчак бу хөрмәтнең кадерен белергә тырышам.

9 Ир-атны артык чибәр һәм көчле хатын-кызлар куркыта.

– Артык чибәрлек хатын-кыз өчен Ходайдан зур сынау ул. Кызганыч, бөтен гүзәлләр дә бу сынауны тиешенчә үтә алмый. Чибәрлек эталоны һәр ир өчен бертөсле була алмый. Ирләр нишләп чибәр һәм көчле хатын-кыздан курыксын? Беренчедән, һәр ир өчен үз хатыны – иң чибәре. Икенчедән, көчле хатыннар тормыш итәр, авырлыкларны бергә җиңәр өчен менә дигән хәзинә... Минем әни 26 яшендә әтидән өч бала белән калган. Апама – биш яшь, миңа – өч, ә сеңлем, әти мәрхүм булгач, өч айдан соң гына туа. Уйлап карагыз, көчле булмаса, йорт-җир төзеп, һәммәбезне укытып кеше итә алыр идеме әни? Мин аның өчен әле дә бала гына: һаман тәрбияли, бөтен кылган гамәлләребезне күзәтеп, белеп, киңәшен биреп тора. Алар хатыным белән бер авыздан, әниле-кызлы шикелле яши.

10 Ир-ат белән хатын-кыз икесе ике галәмнән икәне билгеле инде. Кайчакларда аларның бер-берсен аңламаулары шуннан килеп чыга да. Хатын-кызның нигәнәкъ менә шулай эшләгәнен, үзегез аңламаган берәр очракны искә төшерегез әле.

– Урмайда яшәүче ир-атлар һәм хатын-кызлар бер галәмнәндер. Безнең хатыннар бит үскәндә, гаиләдә күргәнен кабатлый, әти-әниләреннән үрнәк ала. Алар өчен ир – зур канат (фәрештә канаты сыман!), иргә ышаналар, иргә сыеналар... Без дә «ирне ир итүче – хатын-кыз» икәнен яхшы беләбез. Бәлки шуңадыр, авылыбызда гаиләләр тотрыклы.

11 Хаклы икәнегезне яхшы беләсез, әмма хатыныгызның үз туксаны – туксан, хаклык аның ягында дип саный...

– Кызык сорау! Әлеге сорау бигрәк тә яшь чагында, яшь кияү-килен вакытта килеп чыга. Авылда кайнана статусы – үзенә, киленнеке – үзенә: моны һәммәсе дә белә. Ике арада буыннан-буынга күчеп килүче язылмаган законнар бар. Менә яшь килен үзенең хокукларын барлый башлый, ә алар күп вакыт теге язылмаган кануннарга туры килми. Ә мин йортта бердәнбер ир бала, язылмаган закон буенча нигездән чыгып китә алмыйм. Тәкъдирем шул: туган нигеземдә олы буын, ягъни әни белән бергә һәм аның законы буенча яшәргә тиешмен. Яшь хатынны замана мөмкинлекләре кызыктыра, аның аерым яшисе яки әкертен генә дилбегәне үз кулына аласы килә... Менә монда инде ананы – ана, хатынны хатын итеп үз урына куя белергә кирәк. Ир өчен җиңел мәсьәлә түгел бу. Әмма аның чишелешен һәр ир үзенчә таба. Аллага шөкер, безнеке дә ансат кына чишелде.

12 Шундый очракны күзаллыйк әле: арып-талып эштән кайтып керәсез, ә өйдә ашарга пешмәгән. Хатыныгыз, мин арыдым, дип, диванда кырын ятып тора.

– Бу сорау, минемчә, дөрес түгел. Мондый хәл, гомумән, була алмый! Бигрәк тә мишәр хатын-кызлары арасында. Без авылда яшибез, авыл хатыннары, бигрәк тә бездәге кебек кайнана белән бергә гомер иткән хатыннар, «арыдым», дип, ничек диванда ятып торсын инде?! Болай мин үзем дә кайсыбер ризыкларны пешерә беләм анысы. Өйләнешкәч, берничә төрле пылау пешерергә, итле ризыклар әзерләргә хатынымны үзем өйрәткән идем.

13 Сер түгел, берәр җиргә җыена башласак, без, хатын-кызлар, соңга калучан...

– Авыл хатыннары көзге янында сәгатьләр буе боргаланмый!

14 Хатын-кызлар еш кына... бүләк сайлауда ялгыша: ир-атка ошамастай бүләк бирә.

– Гомерем юлда үтте. Балаларыма, хатыныма шуңа күрә бүләкне күбрәк мин алып кайттым. Әле менә соңгы бүләгем турында. Казаннан Вагыйзәгә көмеш татар алкасы алган идем. Кая гына барса да, шуның белән мактана. Борынгы стильдә эшләнгән татар алкасы бөтенесенә ошый, һәммәсе: «Кайдан алдың?» – дип сорый. Минем дәрәҗә тагын үсеп китә инде...



Тулысынча сайтыбыздан укыгыз:
www.syuyumbike.ru

PRESSA.RU



БИШЕНЧЕ КЫЗ

КЕШЕ КҮҢЕЛЕ КАРА УРМАН. АНДА НИНДИ СЕРЛӘР ЯШЕРЕНГӘНЕН ҺӘР КЕШЕ ҮЗЕ ГЕНӘ БЕЛӘ.

Асия
СӘГЫЙТОВА

Кайбер серләрнең, дәүләт серләре кебек, «25 елдан соң», яки «50 елдан соң» дигән вакыт чикләве дә юк. Бер көн җитә дә сер келәләре чылтырап ачыла.

Кар-бураннар туздырып, туй атлары килә. Кәләш – күз явын алырлык чибәр: кара күзле, кара кашлы, ак шәленнән бөселеп чыккан бөдрә чәчләре иңенә сибелгән, бит очлары алсуланган. Абау, күз генә тимәсен! Кияү – зифа озын буйлы, зәңгәр күзле, ак маңгайлы. Кулында гармун. Абау, күз генә тимәсен!

Авыл урамнарын кыңгырау чыңына, гармун моңына күмеп, урамнар иңләп килә торган туй чаналары артыннан әлеге: «Күз тимәсен!»не әле күпләр үз алдына кабатлагандыр. Әнә, борылышта автобустан төшеп калган солдат та – отпускага кайтып килә торгандыр инде – бәләкәй чемоданын карлы юлга куеп, атлар артыннан карап калды: бу бәхетлеләр кемнәр икән?! Бу туй атлары кемнең өенә бәхет илтә икән? Чү! Андый бөдрә толымнар бу авылда аның

Ландышында гына иде бит! Әллә... Ландыш! Ә бит ул менә Ландыш, дип кайтып килә. Унбиш яшьтән яратышкан мәхәббәтен! «Кыр почтасы» аңа хатларны шул кыздан ташыды лабаса. Харис та казармада төнге каравыл тору сәгатьләрен Бөдрә чәченә хатлар язып кыскарта иде. Түш кесәсендә әле дә кыз чиккән кулъяулык ята. Вәгъдә бүләге.

Солдатны кәләш тә күреп тә, танып та өлгергән. Апасының иңенә сыгылып төшеп үксеп елый: «Апа! Харис кайтып килә бит! Апа, Харис кайткан бит!» – «Җитте сиңа! Бүгеннән син Гараф хатыны. Бүгеннән бернинди Харис юк синең өчен. Авылда кызлар бетмәгән. Харис үзенә кыз табар! Яшеңне сөрт. Елмай. Әнә, капкалар ачылган, бала-чага җыелган – конфетларыңны чәч!»

Ул арада апа кеше җиңги-җиңгәчәйләргә, кодагыйкодачаларга сеңлесенең урынсыз да, вакытсыз да күз яшьләрен аңлата: «И-и, кияүгә чыкканда еламаган кыз бармыни инде ул! Яшьлеге белән хушлаша! Ела, сеңлем, ела! Киләчәккә калмасын!»

Ландыш белән Гараф матур гына яшәп киттеләр. Тик менә Гараф хатынының туй көнне елавын күңеленә салып куйган икән. Солдат тарихын белгән булгандыр инде ул, белми буламы соң – авыл бит. Ләкин Ландыш иренә үзе җөй белгертмәде. Хәер, очрашканда елмаешып исәнләшәләр иде. Моның ние бар инде – Ландыш белән Харис сыйныфташлар да иде бит әле. Әйе, Ландыш үрнәк хатын, яхшы килен булырга тырышып, хәтта хезмәтендә дә абруй казанып яшәргә тырышты. Гаиләдә бер-бер артлы үзләре кебек матур кызлар туа торды.

Гарафның күрше урам хатынына иярәшкәнен белеп алганда аларның дүрт кызлары бар иде инде. Шуңынчы белмәве үзе бер тамаша булгандыр инде бистә халкы өчен. Зур шәһәрләрдә генә ул кемнең юлы туры, кемнеке кыек икәнен тикшереп тору гадәте юк. Ландыш үзе, әнисе әйтмешли, төшкән җирендә таш булыр өчен чыккан иде кияүгә. Шуңа күрә узган бер баласына гомер бирүне тиеш дип тапты. Гомерлеккә дип кавышкан парлар гына бала үрчетүдән курыкмый. Ни эшләп үз өйләреннән кыеклаган, арт урамга таба сузылган сукмакка моңарчы игътибар иткәне булмады икән Ландышның? Гараф Фәнирәләр өенә таба салып, такырайтып бетергән сукмак булган икән ләбаса ул!

Иренең сулга сукмак салуын тәгаен белеп алган көнне Ландышның дөньясы убылып төште. Бер генә уй күңеленнән сызылып үтте – аның бу оятын Харис та ишеткәндер! Әй, бөтен авыл белән Ландыштан көлә торганнардыр инде... Укытучы башы белән ирен тыя алмаган, диләрдер. Югыйсә уңганлыгы бар, абруе бар, киенә дә белә, чирле түгел – ни җитми бу ирләргә?

Әйе, авыл белә иде. Тик бер кеше дә Ландыштан көлми, гаепләми, хәтта, мескенгә санап, аны кызганмый да иде. Юк, югала торган хатын түгел ул Ландыш. Кызлары да бер дигән. Ә менә Гараф, ике арада буталып йөреп, бик ялгыша. Чөнки ул барып борын төрткән хатын авыл күзендә дәрәҗәле түгел иде. Гараф үзе бар дөньяга: «Мин авылда яңача яши торган беренче ир булам», – дип ярып салды да мәгъшукасы белән никах укытты.

Бу вакыйгадан соң озак та үтмәстән Ландыш та үзенең бишенче баласына йөккә узганын белеп алды. Мәгъшукага бу хәл, мөгаен, ошамагандыр. Ул, яшь хатын сыйфатында, иренә таләп куйгандыр: «Син әле минем янга йөргән килеш тә хатыныңны кочаклыйсыңмы? – дип чәпчегәндер. – Арагызны өз! Миңа бөтенләйгә күчен!» – дигәндер. Нигә шулай гына итмәде икән Гараф? Юк, күчмәде шул. Иргә авыл алдында көлкегә каласы килмәгәнгә күрә сабырлыгын җуймаган хатынын сынау кызык идеме, әллә хатыннарның кайсын сайларга белми йөдәдеме – монысы билгесез. Гараф ике арада йөреп торуыннан үзе үк кызык таба башлады. Ул һәр кичне хатыны пешергәнне ашап-эчеп, хатыны юып үтүкләгәнне киеп, ясанып мәгъшукасы янына төнгелеккә чыгып китәргә гадәтләнде. Ә бер кичне Ландыш аңа бишенчегә йөкле икәнен әйтте. Ире киенә башлаган җиреннән тукталыр, чишенер, янына килеп утырыр. «Ялгыштым мин, хатын. Болай буталып йөреп ялгыштым. Туктатам мин бу кичке биләмне», – дип әйтер дип көткән иде. Ә ул киемен кире элгечкә элмәде, ишек тоткасыннан кулын алмады, хатынына фәкать усал гына итеп дәште: «Ул баланы алдыр син. Алайса бездән кеше көләр!»

Харис исемен Ландыш бүтән беркайчан да телгә алмады. Онытты микән – монысы билгесез.

– Кеше миннән түгел, синнән көләр. Ходай биргән баладан баш тартыр хәлем юк. Бәлки, бәхетем, рәхәтем шул баладан булыр. Ә син моннан ары минем янга ятмассың! – булды җавап. – Әмма кеше көлдермәбез. Туганнарың да белмәс. Безнең кызлар үсә. Аларның ят нигезгә, агай-эне арасына килен булып төшәселәре бар. Ә синең белән минем түр башында кыз ата-анасы булып янәшә утырасыбыз бар. Шуларны уйла син хәзердән. Мин балаларның күңел бирнәсен киметергә теләмим. Тик менә сине тәнемә кагылдырмам. Бел шуны.

Ландыш сүзендә торды. Шул көннән аларның урынҗире икесенеке ике якка җәелде. Бу хакта дөньяга сер чыкмады. Әмма эш урыннары бергә иде шул. Кеше алдында үрнәк гаилә сыман яшәү хатынга авыр иде. Иренең исә мыегы да селкенмәде, җае чыккан саен, кичләтеп кенә яшь хатын янына бару гадәтен ташламады. Ә нәрсә! Никахланган бит алар! Мөселманнарда булган йола.

Бишенче кыз, чыннан да, бәхете белән туган булып чыкты. Беренчедән, көндәше бишенче кызын имезгән көннәрдә үзе бала күрмәгән көндәш хатын авылдан чыгып китте. (Хатынын кочаклап ята икән бит җир бит!) Икенчедән, тууын бер дә теләмәгән төпчек кызын Гараф башка кызларыннан да артык ярата булып чыкты. Шаян, сөйкемле кызыкай әллә ничек үзен

Фото интернеттан алынды

PRESSA.RU

яраттыра белә иде. Гаиләдәге низаглардан хәбәре булмаганга күрәме, әтисенә аеруча нык сырпалана, назлана. Җитмәсә, әтисендәге күптөрле сәләтләрнең барысы да фәкать төпчек кызда гына кабатлана. «Кемгә охшап матур булган бу кыз?» – дисәләр, «Әтиемә охшап!» – дип, чатнап тора. «Кемгә охшап шулай моңлы тавышлы бу бала?» – дигән сорауны биреп тә тормыйлар. Болай да аңлашыла лабаса: гармунчы Гарафка охшап!

Бервакыт мәгъшукасының авылга кайткан хәбәрен ишетеп, иске сукмагын яңартып, чыгып китәргә җыенганда, төпчек кызы яңгыравыклы тавыш белән:

Утырмагыз урындыкка,
Гармунчылар утырсын, –

дип, җырлый-җырлый, әтисенә урындык китереп куйгач, сүзсез-нисез генә кире чишенде дә, кызы әзерләгән урындыкка утырып, гармунын уйнап җибәрде: «Әйдә, кызым, икәү җырлап карыйк әле, бәлки, бездән бик матур дуэт килеп чыгар. Тавышың шәп синең, сандугачым. Сине «Сандугач сайрар илем» дигән конкурска уздырырга кирәк. Әй, Ландыш, әнисе, син белеш әле, ул бәйгенең шартлары ничегрәк икән?»

Гаиләнең сер сандыгынданиләр барын белмәгән туган-тумача бу гаиләнең бәхетенә тагын бер кат сокланды.

Хатынының горурлык диварын җимерә алмаган Гараф өй салырга кереште. Имеш, ул анда яшь хатыны белән яшәячәк. Тик бу юлы да төпчек кыз атаның ниятен чәлпәрәмә китерде: «Әти безгә зур йорт сала. Анда минем үземнең аерым бүлмәм булачак», – дип ярып салды ул җыелган кунаклар алдында.

Иркә кызының хыялын җимерергә Гараф бу юлы да базмады.

Кыйбласын саташтырган ата кеше күңеленә бишенче кыз тапкан ачкыч, олы кызның бәхетенә дә юл ачты. Анисының туенда ана белән ата янәшә утырдылар. Аларның әле тагын дүрт кызның дүрт туенда әнә шулай янәшә утырасылары бар. Янәшә яшәп бетерәселәре! Авыл кешеләре Гарафның «егетлеген» онытырлык, Ландышның сабырлыгын кызларына үрнәк итеп сөйләрлек итеп. Аннары кызларын тиң иткән кияүләр каршында җаваплылык дигән нәрсә дә бар бит әле.

Бишенче кыз аларга тагын бер сюрприз әзерләгән булып чыкты. Музыка училищесының соңгы курсында укыганда ул бер шәп егетне ияртеп кайтты. Егет кызның кулын сорарга кайткан икән. Ә егетнең төс-кыяфәте нәкъ әтисенеке – Харисныкы! Шулай итеп, Ландышның югалган мәхәббәте туачак оныклар сыйфатында аңа кабат әйләнеп кайтты. Ә менә Харис үзе исән түгел иде инде.

Мәхәббәт һәм хыянәт...

Айсылу НӘГЫЙМОВА, психология фәннәре кандидаты, социология фәннәре докторы:

Ландыш бер үк вакытта күптөрле каршылыклы хисләр уята – ул һичшиксез соклануга лаек, шул ук вакытта аның Хариска карата булган хыянәте бераз күңелне дә кайтара. Чыннан да, гаеплеме ул: иренең хыянәте аңа кайчандыр үзе ясаган ялгышка, хыянәткә җәза булып кайтканмы?

Кеше үз гомерендә берничә тапкыр мәхәббәт, гыйшык хисләре кичерә. Бу хисләр тирәнлеге, кеше язмышындагы роле белән бер-берсеннән, әлбәттә, аерыла. Шул ук вакытта беренче мәхәббәт үзенә күрә хисләр мәктәбе булып тора, кешенең киләчәк тормышына зур йогынты ясый. Ә хисләр... матур бер истәлек булып күңелдә саклана...

Ландышның да Хариска карата булган хисе, әнә шул беренче мәхәббәт булып, йөрәкләрдә матур хатирә итеп саклар өчен генә туган дип уйлыйм. Чөнки хатынның аннан соң булган бөтен тормышы аның чын мәхәббәтенең нәкъ менә ире Гараф булганын күрсәтә. Мондый авыр ситуациягә эләккән һәркем яхшы белә – хыянәтне аңлау авыр, кичерү мөмкин түгел... Шулай да әлеге сынауга дучар булган байтак парлар гаилә учагын сүндерми саклап кала ала. Һәм монда мәхәббәтнең чын, тирән, олы хиснең роле бик зур дип әйтер идем. Сабырлык, сер бирергә теләмәү яки балалар хакына дип кенә түзү, гадәттә озын гомерле булмый. Иртәме-соңмы сабырлык сына, балалар үсә һәм чишелеш, гадәттә, бер, ул – аерылу. Ләкин бу очракта гаилә сакланып калган. Монда Ландышка көч бирерлек бары тик бер генә чыганак бар – ул аның зур мәхәббәте. Бишенче баласына узуы да, аны табарга ният итүе дә, кеше арасында горурлыгын саклап, сер бирми яшәп ятуы да – барысы да нәкъ менә шул турыда сөйли.

Сөйгәненең хыянәтен кичергән, бүгенге көндә шушындый үк утларда янучыларга: «Карагыз, нинди матур мисал! Ландыштан үрнәк алыгыз, сер бирмәгез, гаиләгезне, мәхәббәтегезне саклап калыгыз!» – дип, бертөрле генә киңәш биреп буламы соң? Әлбәттә, юк, чөнки һәр очрак ул үзенчәлекле.

Көндәш белән яр бүлешергә дучар булган ханымнарга шуны әйтер идем – гаиләне саклап калу бик мөһим, ләкин ул үзмаксат булырга тиеш түгел.

■ Хыянәткә дучар булган кешенең үз-үзенә карата булган бәясе төшүчән: әлеге хәл бөтен кешегә билгеле, һәркем аннан көлә сыман тоела. Бу алай түгел. Партнерыгызның хыянәте сезгә куелган начар тамга була алмый, җәмгыятьтә тоткан урыныгыз да бу фактка карап бәяләнми.

■ Гаиләне саклап калу өчен көрәшне үзегезнең тормышны бераз үзгәртеп җибәрүдән башлагыз: моңа кадәр планлаштырып та кул җитмәгән теләкләрегезне чынга ашырыгыз, үзегезнең тышкы кыяфәтегезне, кием-салымыгызны кайгыртыгыз. Гомумән, аз булса да үзегез өчен яшәргә тырышыгыз!

■ Иң мөһиме: үз эчегезгә бикләнмәгез, дуслар, туганнар белән аралашып, балалар белән мөнәсәбәтләрегезне саклап, йөрәк җылысы алыгыз. Бу сезгә бик тә кирәк!



ӘСХӘДУЛЛИНА Алсу

Казан дәүләт университеты, филология факультеты (1990)

Кияүдә, кызы бар

Карьера:
«Татарстан–Яңа гасыр» каналының иртәнге тапшырулар дирекциясенең чыгарылыш мөхәррире

Тормыш шигаре: Үткәннәрне кире кайтару мөмкин түгел, киләчәк иртәгә генә булачак – бүгенге көн белән яшә. Һәр мизгелгә сөен!

https://www.facebook.com/suyumbike.zhurnaly

Исән генә булсыннар!

Әтием Фәһим белән әнием Әлфинур Апас районының Чирмешән авылында яши. Берсенә – 79, икенчесенә 78 яшь. Олыгаялар... Гомер узган саен, әти белән әнинең үзенә никадәр кадерле, кирәк икәнен аңлыйсың. Аларга гел ярдәм итәсе, сөендерәсе, нәрсәнедер күрсәтәсе, сөйлисе, тыңлыйсы килә... Туган нигезгә һәр кайту бәйрәм кебек. Әни элеккеге кебек камыр ризыклары пешереп каршы ала алмый инде. Кайткан саен аларга мин нидер пешерәм хәзер. Шуңа ихластан сөенгәннәре!


Менә кемнән үрнәк алырга!

Безгә кайдан гына шалтыратмый даими тамашачыларыбыз?! Финляндиядән Фарук абый һәр тапшыруга үзенең фикерен җиткерә, киңәш-тәкъдимнәрен ишеттерә. Үзбәкстаннан Дания апа да шулай. Казакъстаннан даими элемтәдә торучылар бар. Якыннарына котлау ишеттерергә теләгәндә, безнекеләр кебек: «Мин татарча не могу! Скажу по-русски. Үзегез берәр нәрсә язарсыз», – дими читтәгеләр. Тырышып-тырышып татарча сөйләшәләр, Татарстанда булган һәр вакыйгадан хәбәрдарлар. Туган телне, гореф-гадәтләрне, көй-моңнарыбызны алар кадерли белә!

Күтәбез!

Ниһаять, режиссер Джеймс Кэмерон без яратып караган «Аватар»ның дәвамын быел апрель аенда Яңа Зеландиядә төшерә башлаячакларын хәбәр итте. Хәтерләсәгез, бу фильм экранга 2009 елны чыккан иде. Прокаттан иң күп табыш китергән фильм булып тарихка кереп калды ул. 2,8 миллиард доллар! «Аватар» берьюлы тугыз номинациядә «Оскар»га тәкъдим ителде һәм өч номинациядә җиңү яулады.

сөендерде










сөендерде







сөендерде



көендерде

көендерде

көендерде

Язмышмы, ялгышмы?

Бик күпләрнеке кебек бу көннәрдә минем дә йөрәгем җырчы Василә Фәттахова өчен өзелә... Аның безгә – «Манзара» тапшыруына да килгәне булды. «Кайнатам белән кайнанама «әти-әни» дип әйтә алам. Бүгенге бәхетем гел шулай түгәрәк булсын иде», – дип сөйләгән сүзләре колагымда әле дә яңгырап тора... Әти-әни язмышларының балаларда кабатлануы, гомерләрнең шулай вакытсыз өзелүе тетрәндерә. Табибларның аңа ярдәм итә алмавына йөрәк ышанып бетми. Медицина шундый көчле заманда! Ходай биргән сулар сулышы кыска булдымы икәнни?!

Киткәннәр инде кайтмый...

Көн тудымы яңа хәбәр. Берсеннән-берсе яманрак алар һәм күбесе балалар белән бәйле. Лениногорскида берьюлы биш бала янгында һәлак булды. Камчаткада сигез яшьлек өч бала мәктәптән кайтышлый кайнар сулы траншеяга төшеп – пешеп үлде. Кызганыч, бу исемлек көн саен яңара, озыная... Ә бит мондый фаҗигаләр күп вакыт кемнеңдер җавапсызлыгы аркасында килеп чыга. Гамьсезлеге, битарафлыгы аркасында. Кайдадыр гаеплеләрне табып, аларга җәза да бирәләр, тик аннан зыян күрүчеләргә ни мәгънә?!

Бу дөнья кая бара?!

Бельгиянең Көнчыгыш Фландрия провинциясе губернаторы җирле радио аша халыкка мөрәҗәгать итеп, аларны мигрантларга ярдәм итмәскә, ризык, акча, кием-салым бирмәскә чакырган. Югыйсә безнең ил аша Бөекбританиягә юл тотучы качаклар Бельгиядә төпләнеп калачаклар, дигән ул. Имеш, мондый проблемалар сезгә дә, безгә дә кирәкми. Шулай инде, ачның хәлен тук кайдан белсен... Ярый әле, җитәкченең бу сүзен хуплаучылар бөтенләй диярлек табылмаган.

PRESSA.RU

Ир-егетләргә бүләк сайлау илләдә авыр инде. Бәйрәм җитә башласа, нәрсә бүләк итәргә дип, баш ватабыз. Бу юлы, үзара уйлаштык та, бик матур башлык белән шарф бәйләп карарга булдык. Башлыгы да, шарфы да кирәк әйберләр.






Мастер-классны Ания ГАТАУЛЛИНА үткәрә.

ҖЫЛЫ БҮЛӘК

Кирәк:

- 100 г/250 м булган ярымйон бәйләм җебе;
  2,5 һәм 3,5 лы бәйләм энәләре.

Без биргән сызымда шарф бәйләү үрнәге күрсәтелгән. Башлык та шушы үрнәк белән бәйләнә. Шарфтан аермалы буларак, башлык дүрт өлештән (раппорт) тора. Бер раппортта 24 күз: ул бер үрем һәм бер ромб дигән сүз. Башлык әйләнәләп бәйләнгәч, җөп рәтләрдә уңнар – уң, суллар сул белән бәйләнә (ромб уртасындагы «энҗе» бизәктән тыш).



3 уң күз ярдәмче энәгә күчерелеп, бәйләмнең арткы ягына чыгарыла, чираттагы 3 күз уң белән бәйләнә, аннары ярдәмче энәдәге күзләр кабат төп энәгә күчерелеп, алар да уң белән бәйләнә.

3 уң күз ярдәмче энәгә күчерелеп, бәйләмнең алгы ягына чыгарыла, чираттагы 3 күз уң белән бәйләнә, аннары ярдәмче энәдәге күзләр кабат төп энәгә күчерелеп, уң белән бәйләнә.

сул күз уң күз

1 сул күз ярдәмче энәгә күчерелеп, бәйләмнең арткы ягына чыгарыла, чираттагы 3 күз уң белән бәйләнә, аннары ярдәмче энәдәге күз сул белән бәйләнә.

3 уң күз ярдәмче энәгә күчерелеп, бәйләмнең алгы ягына чыгарыла, чираттагы 1 сул күз уң белән бәйләнә, ярдәмче энәдәге күзләр төп энәгә күчерелеп, уң белән бәйләнә.

Башлык:

■ Энәгә 96 күз җыеп, 12 рәт 2 уң, 2 сул күздән торган кереш бәйлибез.

■ 13 нче рәтне бәйләгәндә 3,5 лы энәгә күчәбез.

■ 13-14 нче рәтләр: 6 уң, 6 сул, 6 уң, 6 сул белән бәйләп чыгыла.

■ 15 нче рәт үрнәккә карап бәйләнә: 6 уң күзнең беренче 3 күзен ярдәмче энәгә алып, 3 күзне уң белән бәйлибез. Ярдәмче энәдәге күзләрне кабат төп энәгә күчереп, аларны да уң белән бәйләп алабыз. Аннары 6 күз сул белән бәйләнә. 3 уң күзне ярдәмче энәгә күчерәбез, 3 күзне уң белән бәйлибез, ярдәмче энәдәге күзләрне төп энәгә күчереп, уң белән бәйлибез, 6 сул күз бәйләнә. Бу – бер раппорт үрнәге. Калган раппортларда да нәкъ шушылай кабатлыйбыз.

■ 16 нчы һәм башка җөп рәтләрдә уңны – уң, сулны сул белән бәйләп чыгабыз.

■ 21 нче рәт 15 нче рәттәге сыман бәйләнә.

■ 23 нче рәттән ромбны бәйли башлыйбыз: үремнән соң килгән 6 сул күзнең бишесен сул белән бәйлибез, 1 сул күзне ярдәмче энәгә күчереп, бәйләмнең арткы ягына чыгарабыз, 3 уң күзне уң белән бәйлибез, ярдәмче энәдәге күзне сул белән бәйлибез, 3 уң күзне ярдәмче энәгә күчереп, бәйләмнең алгы ягына чыгарабыз, чираттагы күзне уң белән бәйләп алабыз. Ярдәмче энәдәге күзләр уң белән бәйләнә, калган 5 сул күз сул белән бәйләнә. Калган раппортларда да шушы үрнәк кабатлана.

■ 24 нче рәт: ромбның уртасындагы күзләрдән тыш, уңнарны уң белән, сулларны сул белән бәйләп, рәтне чыгабыз. Ромбның уртасы «энҗе» бизәк белән бәйләнә: уң күзне сул белән, сул күзне уң белән бәйлибез.

■ 25 нче рәт: үремнең 3 уң күзен ярдәмче энәгә күчереп, күзләрне алыштырып бәйлибез, чираттагы 5 сул күзнең дүртесен сул белән бәйләгәч, 1 күзне ярдәмче энәгә күчереп, бәйләмнең арткы ягына чыгарып торабыз. 3 күзне уң белән бәйлибез, ярдәмче энәдәге күзне сул белән бәйләп алабыз, ромб уртасындагы күзләр «энҗе» бизәк белән бәйләнә, 3 уң күзне ярдәмче энәгә күчереп, бәйләмнең алдына чыгарабыз, 1 сул күзне уң итеп алабыз, ярдәмче энәдәге күзәнәкләрне бәйлибез. Чираттагы 4 сул күз сул белән бәйләнә.

■ Ромбның уртасындагы күзләр саны 8 булганчы шушы рәвешле бәйлибез. Аннан соң 3 рәт күзләрне күчерми генә бәйләнә, фәкать ромб уртасындагы күзләрне генә уңны – сулга, сулны уңга чиратлаштырабыз.

Ромбны очлау

■ үремнән соңгы 2 сул күзне бәйләгәч, 3 уң күзне ярдәмче энәгә күчереп, бәйләмнең алгы ягына чыгарып торабыз, ромб эчендәге 1 күзне сул белән бәйләп алабыз, аннары ярдәмче энәдәгеләрне уң белән бәйлибез. Ромб уртасындагы күзләрне «энҗе» бизәк белән бәйлибез, Ромб кырыендагы 3 уң күзгә җиткәнче, 1 күзне ярдәмче энәгә күчереп, бәйләмнең арткы ягына чыгарабыз, 3 уң күзне бәйлибез, ярдәмче энәдәге күзне төп энәгә күчереп, сул белән бәйлибез.

■ 33-39 нчы рәтләрдә ромб уртасындагы күзәнәкләрне киметеп, ромбны очлыйбыз.

■ 49 нчы рәттән икенче ромб бәйләнә башлый. Аны төгәлләгәч, башлыктагы күзләр санын киметәбез: үремнәр кырыендагы сул күзләрне икене бергә бәйләп алабыз. Һәр рәт саен бәйләм 8 күзгә кими. Ахырдан бәйләмдә 40 күз генә кала. Энәдә калган күзләрне җыеп, тегеп куябыз.

Шарф

■ ул 40 күздән бәйләнгән. Беренче 10 рәт уң белән бәйләнә (шәл уртасы кебек). Шарфны төгәлләгәндә дә 10 рәт уң белән бәйләп төгәллибез.

■ 11 нче рәт: 5 күз уң, аннары схемада күрсәтелгән үрнәк, 5 уң күз.

■ Шарфның озынлыгы 120 см чамасы.

Бүләк «күбәләк»



Мастер-классны Энҗе ЗӘКИЕВА үткәрә.

Япь-яшь кенә булса да, Энҗенең инде үз тегү мәктәбе бар. Киемсалымны үзенә-үзе тегеп кияргә теләгән туташ-ханымнарны кисүтегү осталыгына өйрәтә ул. Казан уртасында зур гына офис арендалап, үз бизнесын булдырган бу тәвәккәл ханым бүген безгә кече яшьтәге ир балалар өчен муенга тага торган «күбәләк» тегәргә өйрәтер. Аны тегүнең бер авырлыгы да юк, хәтта тегә белмәүчеләр дә башкарып чыга ала.

Кирәк:

• буе – 40 см, иңе 20 см булган тукыма. Ул бик калын булмасын.
• ыргаклы каптырма;
• тегү җебе.

Эш барышы:

■ тукыманы үтүкләп, ике турыпочмаклык кисәбез. Аның берсе – 20х14 см, икенчесе – 7х5 см.

■ Зур турыпочмаклыкны озын буйга өч кат бөклибез. Тукыма чите урта сызыкка 0,5 см чамасы килеп җитми калсын. Үтүк белән бастырабыз. 5,5 см киңлегендәге тасма килеп чыга.

■ Аның кыл уртасын табып, ике читен шул сызыкка туры китереп бөклибез.

■ Энәгә җеп саплап, «күбәләк»нең кыл уртасыннан җөй салабыз, җеп очын тартып, җөйне җыерабыз.

■ Кечкенә турыпочмаклыктан «күбәләк»нең уртадагы атламасын ясыйбыз. «Күбәләк»не шуның белән уратып, ике читен күренми торган җөй белән тегеп тоташтырабыз.

■ Артып калган тукымадан бау тегәбез. Бауның озынлыгы баланың муен әйләнәсенә тигез, киңлеге – 5 см. Аны сул ягыннан буйга урталай бөкләп, машина белән җөй салабыз. Җөй тукыма читеннән 0,5 см эчтәрәк салына. Уң ягына әйләндерү өчен бер башын текми калдырабыз.

■ Бауны уң ягына әйләндерәбез. Ачык калган башын атлама астына кертеп, кул белән типчибез.

■ Каптырманың ыргагын – бау очына, элмәгән атламага тегеп куябыз.



Мастер-классның тулы варианты – сайтыбызда.

PRESSA.RU

БӘЙРӘМГӘ ГӨЛТАН САЛАТЫ һӘМ...

Мастер-классны Татарстанның халык артисты, Татар дәүләт җыр һәм бию ансамбленең данлыклы биючесе Ләйсән ХӘМИТОВА үткәрә. Ул әзерләгән ашның да, салатның да тарихы бик кызык. Салат рецептын ул Төркиядә яшәүче милләттәшебез Гөлтан Ураллыдан өйрәнеп алган. Ашны исә ансамблънең баш балетмейстеры Раилә Гариповадан өйрәнгән. Беренче карашка гүзара бер дә ярашмый торган тавык ите белән сөттән әзерләнсә дә, бик тәмле килеп чыга бу аш. Салат турында инде әйтсәң дә юк, бер авыз иткән кеше, рецептын сорамый калмый икән.





Кирәк:

- Пешкән тавык түше;
- 5 йомырка;
- 5 аш кашыгы майонез;
- 300 г маринадлаган гөмбә;
- ярты баш суган;
- 1 зур учма укроп;
- 2 кыяр.

бизәү өчен:

- 5 бөдәнә йомыркасы;
- 1 кызыл борыч;
- петрушка.













Фото: Ксения Богданова

Эш барышы:

■ Тавык түшен ваклап турыйбыз.
■ Суганны турап, әчелеге бетсен өчен 5 минут кайнар суда тотабыз.
■ Йомырканы эре угычтан уып, майонез белән катнаштырабыз.
■ Кыярны – вак шакмаклап, укропны ваклап турыйбыз.
■ Зур сай тәлинкәнең төбенә тавык итен салып, йомыркалы майонезның өчтән бер өлешен ит өстенә ягабыз.
■ Суганның суын агызып, кыяр белән катнаштырабыз һәм йомыркалы майонез өстенә түшибез.
■ Кыяр өстенә мул итеп укроп сибеп, өстенә йомыркалы майонез ягабыз.
■ Чираттагы рәткә суы сөзелгән гөмбә салына. Аның өстенә йомыркалы майонез ягабыз.
■ Салат өстен ярым боҗралап туралган кыяр, кызыл борыч һәм урталайга бүленгән бүдәнә йомыркалары белән бизибез.

Осетин ашы.

Кирәк:

(дүрт кешелек гаилә өчен)

- 1 тавык;
- 3 бәрәңге;
- 4 кап йомшак сыр (берсе 50 г).

Каймак тәме килеп торганы белән аш тәмлерәк була;

- 2 зур учма петрушка;
- 1 л сөт;
- 3 тырнак сарымсак;
- төменчә тоз.

Эш барышы:

■ тавыктан шулпа кайнатабыз. Суны тавык күмелер-күмелмәс итеп кенә салырга кирәк. Тавык пешкәч, шулпадан алып суытабыз. Түшен шунда ук салат өчен алып куябыз, калган итен сөягеннән аерып, вак шакмаклап турыйбыз. Ашка сөяге кермәскә тиеш.
■ Шулпага сөт өстәп, кайнатып чыгарабыз. Аннары вакланган тавык итен салабыз, ваклап туралган бәрәңге өстибез, вак угычтан уылган сарымсак кушабыз.









■ Бәрәңге пешкәч, эре угычтан уылган сыр салабыз. Без каймак тәме килгән сыр таба алмадык, шуңа күрә каймак тәмен көчәйтү өчен 100 г сөт өсте куштык. Сөт өстен кушмаска да була.
■ Шулпа кайнап чыгып, сыр эреп беткәч, ваклап туралган петрушка кушабыз. Шулпаны бер-ике тапкыр «сикертеп» алгач, ашыбыз әзер.

PRESSA.RU



■ Яңа ай туган көн үсемлекләр өчен авыр көн. Ай тулган көннәрдә чәчү, утырту кебек эшләр белән шөгыльләнмәскә кирәк.

■ Ай тулган көннәрдә үсемлекләрнең яшәү көче сабакларга ыргыла. Үсемлекләрне күчереп утырту, чүп үләннәрен утау, үсемлекләрнең төпләрен йомшарту, ашлама кертү өчен яхшы вакыт. Бу көннәрдә җыйган орлыклар киләсе елга яхшы уңыш бирер.

■ Үсүче айда орлыклар чәчәләр, уҗымнарны күчереп утырталар.

Бу көннәрдә үсемлекләрнең яшәү суты яфрак, сабакларга күчә. Аш-суда яфрак, сабак, җимешләре кулланыла торган үсемлекләрне шушы көннәрдә утыртып калырга кирәк.

■ Кимүче айда үсемлекләрнең үсеше акрыная, шунлыктан күчереп утырту кебек эшләрне туктатып торалар. Ә менә кишер, чөгендер кебек, аш-суда тамыры кулланыла торган үсемлекләрне кимүче айда утыртсаң, уңышы яхшы була.

ЯЗНЫҢ КӨНЕ ЕЛ ТУЙДЫРА

ҮСЕМЛЕКЛӘР	ФЕВРАЛЬ	МАРТ	АПРЕЛЬ	МАЙ	ИЮНЬ
Ай фазалары	8 яңа ай; 22 тулы ай; 9-21 үсүче ай; 1-7; 23-29 кимүче ай	9 яңа ай; 23-24 тулы ай; 10-22 үсүче ай; 1-8; 24-31 кимүче ай	7 яңа ай; 22 тулы ай; 8-21 үсүче ай; 1-6, 23-30 кимүче ай	6 яңа ай; 22 тулы ай; 7-21 үсүче ай; 1-5, 24-31 кимүче ай	5 яңа ай; 20 тулы ай; 6-19 үсүче ай; 1-4, 21-29 кимүче ай
Баллы борыч, томат, баклажан	13-15; 17-20, 23, 26	12-14, 16-18;	12-14	16-24	6-7, 10-17
Башлы суган, сарымсак	2-5, 27-29	28-30	1, 22-28	1-3, 19-24, 29-31	2-4
Бәрәңге	5-7, 27-29	30-31	19-22, 24-28	1-3 (тиз өлгерешле), 19-21, 24-26	2-4, 20-22
Борчак, фасоль		14-18, 25-28	8-12, 22-24	9-12, 16-21	6-7, 13-17
Кабак, ташкабак	17-20	11-14, 16-18, 23-25	8-10, 12-14, 22-24	5-7, 9-12,	6-7
Кәбестә	5, 10	11-18, 25-28	8-9, 12-14	16-19	6-7, 10-17
Кишер, чөгендер, тамыр сельдерей һәм тамыр петрушка	2-6, 25-29	1-5, 28-31	1 (кичке алтынчы ятрыдан соң), 27-28	1-3, 24-26	2-4
Кыяк өчен суган, порей суганы, петрушка, укроп, рәйхан	1-2, 10-14, 17-20	1, 12-18	8-14, 19-22	8-12, 19-21	6-7, 13-17
Кыяр, кавын, карбыз	17-20	16-18, 25-28	8-10, 12-14	9-12, 16-21	6-7, 13-17
Редис, ачы торма, дайкон	1-5, 27-29	11-14, 30-31	1 (кичке алтынчы ятрыдан соң), 24-26, 28-29	1 (кичке алтынчы ятрыдан соң), 2-3, 24-29	2-3, 15-17
Чәчәкләр	12-15, 25-17	12, 13, 15-18, 20-23	12-14, 17-19	14-16	6-7, 10-17
Бүлмә гөлләрен күчереп утырту	13-15, 22-25	20-23	17-19	9-12, 16-19	10-13, 15-18
Уҗымнарны күчереп утырту	13, 14, 15, 22-24	16-18, 20-23	12-14	9-12, 19-21	6-7, 10-15
Бакчада агач-куакларны кисү		3-5, 25-31	1, 2	3-5, 31	

**КУЧКАР.** Эшләгән эшләрегезнең нәтиҗәсен күрерсез. Ләкин моның өчен шактый тырышырга туры килер. Көтелмәгән хәлләргә дә әзер торыгыз. Эштәгеләр белән сүзгә килүегез ихтимал. Яңалыктан курыкмаучы кешеләргә март ае уңыш вәгъдә итә.

**ҮГЕЗБОЗАУ.** Ыгы-зыгылы, мәшәкатьле ай булырга охшаган. Ачу килгән, теңкәгез корыган чаклар аз булмас. Яңалыкларга бай ай. Иҗади кешеләргә уңыш елмаячак. Мөмкинлек чыкса, ял итеп алырга тырышыгыз.

**ИГЕЗӘКЛӘР.** Күңелле вакыйгалар, куанычлы хәлләр көтелә. Яңа эшкә керешсәгез, уңышлы тәгәлләнер. Шулай да артык җитди, зур игътибар сорый торган эшләргә алынудан тыелыгыз. Дәрманыгыз ташып торса да, озакка бармас.

**КЫСЛА.** Тыныч ай. Эшләрегез җай гына барыр. Яңа эшләргә алынмый торыгыз, мәшәкатеннән ничек котылырга белмәссез. Дусларыгыз янында сүзләрегезне уйлап әйтегез, уйламый әйтелгән сүз аркасында араларыгыз бозылуы ихтимал.

**АРЫСЛАН.** Эшләрегез муеннан һәм аларның һәрберсе галәмәт зур тырышлык таләп итә. Ай ахырына таба тәмам йончысагыз да, әллә ни зур нәтиҗәләргә ирешүегез икеле. «Кәҗәсе түгел, мәзәге кызык», дип йөрүчеләр генә үзләреннән канәгать калыр.

**СӨМБЕЛӘ.** Яңа эшләр һәм... яңа хаталар ае булырга охшаган. Шулай да яңалыклардан курыкмагыз. Тирә-юньдәгеләрнең игътибары гел сездә булыр. Чыгышлар ясау, кемгәдер мөрәҗәгать итү, ярдәм сорау өчен кулай вакыт – гозерегез үтәлми калмас.

**БИЗМӘН.** Үзегезне күрсәтү өчен яхшы гына форсат чыгып тора. Иҗади сәләтегез ачылыр. Алдан күрүчәнлегегез аркасында күп кенә күңелсезлекләрдән котылып кала алырсыз. Акылыгызны, гаделлегегезне бәяли торган сүзләр ишетерсез.

**ЧАЯН.** Үсеш юлының яңа чорына керәсез. Айны зур эш белән башлап җибәрерсез. Ул көчегезне шактый суырачак. Күңелегез гел яңалыкка, тормышыгызга үзгәрешләр кертергә омтылачак. Авырлыклар алдында каушап калмасагыз, теләкләргә ирешү ихтималы бик зур.

**УКЧЫ.** Яңа теләктәшләр табарсыз. Алдыгызда зур мөмкинлекләр ачылыр. Тирә-юньдәгеләрнең сезне дөрес аңламаулары ихтимал, нәрсәдер эшләргә җыенасыз икән, кат-кат уйлагыз.

**КӘҖӘМӨГЕЗ.** Четерекле мәсьәләләрне хәл итәргә туры килер. Өстәвенә, болар барысы да ашыгуны таләп итәчәк. Бу исә барысын да уйлап эш итәргә яраткан Кәҗәмөгезләрнең фикерен чуалтачак. Үзегез бик ышанган кешенең сүзләренә колак салыгыз.

**СУКОЯР.** Зур үзгәрешләр белән бәйле ай көтелә. Яңа вазгыятькә күнегү җиңел булмас. Тирә-юньдәгеләр сездән гамәл көтә, әмма сез әле яңа адым ясарга әзер түгел кебек. Ышанычлы кешедән киңәш сорарга тайчанмагыз, бу айда хата җибәрү ихтималы зур.

**БАЛЫК.** Мәшәкатькә бай булса да, уңышлы ай. Ай башында көчегез бетеп киткән сыман күренсә дә, ай урталарына таба дилбегә кабат сезнең кулда булыр. Яңа мөмкинлекләрдән авыз ачып калмагыз.

февраль дә кабынган йолдызлар

Татарстан



Шәхсәнәм Әсфәндиярова (8.02.1926–27.09.1996) – **ТАССРның халык, РСФСРның атказанган артисты.**
Үзбәкстанда туып-үсә. 1939–1941 елларда Ташкент хореография училищесында укый. 1949 елда ГИТИСны тәмамлый. 1950 елдан Татар академия театрында. Чын-чынлап ышандырып уйный белүче актриса. Артислар аны, яратып, үзара Шаха дип йөрткәннәр. Чынлап та, аңардан затлылык, шаһлык бөркелә сыман. Бик чибәр дә була ул. Замандашлары әйтүенчә, Шиллерның «Мәкер һәм мәхәббәт» әсәрендә аның Луизасына сокланмаган кеше булмаган. Ч. Айтматовның «Гүзәлем Әсәл» спектаклендә Хәдичә роле өчен 1967 елда Г. Тукай исемендәге дәүләт премиясе белән бүләкләнә. Озак еллар яшь артистлар тәрбияләү белән шөгыльләнә. Бердәнбер кызы Җәмилә дә артист һөнәрен сайлаган.

Россия



Агния Барто (12.02.1906–1.04.1981) – **балалар шагыйрәсе.**
Чын исеме Гетель. Урта мәктәптә укыганда, балет мәктәбенә дә йөри. Аннан, хореография училищесын тәмамлап, бер ел балет труппасында эшли. Беренче ире шагыйрь Павел Бартога кияүгә чыккач, үзе дә шигырьләр яза башлый. Сугыш вакытында Свердловскида яши, токарь һөнәрен үзләштерә. Премияләрен танклар төзү өчен биреп бара. Сугыштан соң, кабат Мәскәүгә кайта. Беренче шигырь җыентыгы – «Стихи детям» 1949 елда басыла. 1970 елда «За цветами в зимний лес» китабы басылып чыга. 1964–1973 елларда «Маяк» радиодулкынында «Найти человека» тапшыруын алып бара. Ленин премиясе һәм икенче дәрәҗәдәге Сталин премиясе лауреаты.

Чит илләр



Анна Герман (14.02.1936–25.08.1982) – **дөньякүләм танылган җырчы**.
Үзбәкстанда туа. Милләте буенча – алман. Башлангыч белемне Кыргызстанда ала, аннары укуын Казакъстанның Җамбыл (хәзерге Тараз) шәһәрендә дәвам итә. 1946 елда, әнисе кабат кияүгә чыккач, алар Польшага китәләр. Вроцлав университетының геология факультетында укый. 1960 елда студентлар кичәсендә катнашып, Италия хөкүмәтенең стипендиясенә лаек була. Лирик-колоратур сопрано тавышлы кызны актер-режиссер Жевуша Юлиан Квишка үз труппасына чакыра. 1963 елда Сопотта узган III Халыкара җыр фестивалендә катнашып, дөньяга таныла. 1972 елда инженер Збигнев Тухольскийга кияүгә чыга.

PRESSA.RU





АЙ НУРЫНА ТӨРЕП

Анатолий Пашин – бик үзенчәлекле талантлы рәссам. Ул дөньяны бөтенләй башкача күрә! Эшләрендәге тональлекне сабый бала сулышына тиңләргә мөмкиндер: Казанның меңьеллыгына, А. С. Пушкинга багышланган монотипияләр, «Шәрык чибәре» сериясе, «Инь-Янь», «Фәрештә» картиналарындагы гаҗәеп хатын-кыз образлары, «Клеопатра», «Чыңгызхан», «Петр I», «Екатерина II» портретлары... Әйе, рәссамның иҗаты киңкырлы! Акрил һәм пастель буяулар, каурый каләм, бай төсләр гаммасын бик оста тоемлап, җанына сыйган галәмне башкалар белән бүлешә. Кечкенә генә бер сызык йә нокта, нәни генә бер тап-төс шундук башка кәеф өсти. Сәнгать белгече Розалина Шаһиева Россия Рәссамнар берлеге әгъзасы Анатолий Пашинның «Йосыф-Зөләйха» поэмасы сериясенә ясалган эшләрен менә ничек тасвирлый: «Иллюстрацияләре алтын белән чигелгән татар милли бизәкләрен һәм татар китап бизәү сәнгатенең гүзәл үрнәкләрен хәтерләтә, нәфис зәвыгы белән сокландыра, алтынсу йөгертелгән саргылт-яшел төсләр, сихерләп, әсәрнең эчке психологиясен тулырак ачарга булыша. «Ай йөзле мәхәббәт»тәге Зөләйхасы шәрык гүзәлләренә, Сөембикә ханбикәгә тиң. «Ай нурына төренгән» Йосыф ак атында Мисырның пирамидалар үзәнен кичә... Гарәп чүлләрендәге ком таулары фоны, челтәрләп эшләнгән бизәкләре белән тәмам хозурлап, Мисыр сәнгатенә ишарәли... Йосыф белән Зөләйханың күрешүен сурәтләгән биттә фәрештәләр аларга мәхәббәт нуры җибәрә... Күктә милли орнамент формасындагы әкияти болытлар йөзә... Илаһи динамика, түгәрәк сызыклар, Болгарның чәчәк ату чорын хәтерләткән оҗмах бакчалары... Кол Галинең йөз чалымнары шәйләнә, азан авазлары, шәрык көйләре ишетелгәндәй була...


Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе Анатолий Пашин үзен һәм үзеннән элгәргеләрне дә узып, шәрык шигъриятенә йөз тоткан хәлдә, илһамланып, чын фэнтези-криптограмма – киләчәккә хат юллый...»


Чистайда туган егет Казанда театраль декорация бүлегендә, Харьковта дизайн һәм сәнгать академиясендә укый, Калугада – рәссам, Чаллыда рәссам-проектлаучы булып эшли. Рәссамның иҗат биографиясе 1974 елдан, яшьләр һәм республика күргәзмәләрендә үзен танытудан башлана. Шул вакыттан 2010 елга кадәр ул 30 дан артык шәхси күргәзмәсе белән Мәскәү, Казан, Киев, Самара, Чаллы, Чистай, Алабуга, Түбән Кама сәнгать сөючеләре күңелен яулый. Бөтенсоюз, Бөтенроссия, халыкара конкурсларда катнаша. Ун еллап инде Алтайга барып, анда яшәүче халыкның тормышын, мәдәниятен өйрәнә, бездәге төрки халыклар белән уртаклыклар эзли. Алтай һәм Памир рухы бөркелгән пейзажлардан яктылык агыла. Ә туган якның Кама аръягы табигате йә Зөя утравы күренешләре исә күзләрне иркәли. «Иртәнге сыек томан» картинасындагы ак, сары, яшел, зәңгәрсу, алсу-шәмәхә төсләр, Пашин фантазиясе белән өртелеп, үтәкүренмәле пәрдә артыннан ачыла.


А. Пашин педагог та әле. Аның шәхси балалар сәнгать студиясе «Сирин» бар! Укучылары Япониядә, Франциядә, Һиндстанда узган халыкара күргәзмәләрдән җиңүчеләр булып кайта.

Ул – кабатланма шәхес, фәлсәфи рәссам. Пар алма ясап – Адәм белән Һаваны, көймәләр төшереп – ир белән хатынны ача алган. Шундый картинасы да бар: төп персонажлар – Ышаныч, Өмет, Мәхәббәт.

Эльмира ЗАКИРОВА









АНАТОЛИЙ ПАШИН

PRESSA.RU

1 февральдән Татарстан буенча
2016 елның II яртыеллык өчен «Татмедиа»
басмаларына алдан язылу башланды



ИГЪТИБАР!
«Сөембикә» журналының индексы үзгәрде

«Почта России»ның «Подписные издания»
(ПАП) рәсми каталогы буенча
ЖУРНАЛЫБЫЗНЫҢ ЯҢА ИНДЕКСЫ П2204



ЭЛЕКЕГЕ БӘЯДӘН ЯЗЫЛЫРГА АШЫГЫГЫЗ!

Татарстаннан читтә яшәүчеләр
әлегә «Роспечать» каталогындагы элеккеге
индекс буенча языла алалар: 73002



Журналыбызга он-лайн режимда :
http://podpiska.pochta.ru сайтында (регистрация узып)
яки безнең сайтыбызның он-лайн язылу бүлегендә дә
язылырга мөмкин

Электрон версиягә язылган очракта, яңа санны компьютерда, планшетларда, барлык мобиль җайланмаларда PDF форматта укырга була. iPad һәм iPhone кулланучылар «Сөембикә» журналының электрон версиясен App Storeдагы «Pressa.ru» киоскына кереп, хатын-кызлар өчен журналлар арасыннан таба ала. Электрон версиягә язылу турында тулырак мәгълүматны «Сөембикә» журналының сайтында «Язылу» бүлегендә табып була (www.syuyumbike.ru).

16+